Мәдәни җомга

www.madanizhomga.ru

1995 елның июленнән башлап чыга

Татарстанда язылу индексы – П2355.

№ 17 (1382) 6 май 2022 ел

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:

madani_zhomga madanizhomga madani_zhomga

6

Менделеев шәһәрендәге бер мәктәптә Котдус Габдрахманов түгәрәгенә йөргән алты егет Советлар Союзы Герое исеменә лаек була.

12

Сынчы Артур Давыдов Ватан сугышына сигез улын озаткан Фатыйха Әхмәдиевага багышлап һәйкәл куярга тели.

14

Кырымдагы партизан хәрәкәте советлар чорында дистәләрчә еллар тарихчылар өчен тыелган темаларның берсе булып калды.

Күкләребез һәрчак имин булсын, Бөек Җиңү таңындагыча!

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

- Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов «Хәтер бакчасы» халыкара акциясе кысаларында «Казан-2» тимер юл вокзалы янындагы скверда агач утыртты.

- Татарстан Премьер-министры урынбасары, Милли Шура рәисе Васил Шәйхразиев Луганск Халык Республикасына эш сәфәре белән китте.

- Түбән Кама театрында үткән «Театрда шигърият» кичәсендә Татарстанның халык рәссамы Әхсән Фәтхетдиновны искә алдылар.

- Буа шәһәре мәктәбендә Татарстанның халык шагыйре Ренат Харис исемендәге "Киләчәге бар милләт без, шәхесләргә бай милләт без" дигән конференция үткәрелде.

- Yummy Music лейблы татар мөһаҗирләре турындагы «Туңган як» дип исемләнгән документаль фильм чыгарды.

- Анкара университеты Тел һәм тарих-география факультетында Чирмешән районы Бәркәтә авылы егете, дөньякүләм танылган тарих галиме Әкъдәс Нигъмәт Курат исемендәге аудитория ачылды.

- М.Акмулла исемендәге Башкорт дәүләт педагогика университетының татар кафедрасының 30 еллыгына багышлап, «Татар филологиясен өйрәнү һәм укытуның актуаль проблемалары» Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе узды.

- «Казан» гаилә үзәге янында ачык һавада кино күрсәтү сезоны ачылды.

- «Алтын каләм» Республика балалар, яшүсмерләр һәм яшьләр матбугаты фестиваленә гаризалар кабул ителә башлады.

ӘЙТКӘН СҮЗ – АТКАН УК

Илдар ГАБДРАФЫЙКОВ, этнолог:

“Татар теле белән башкорт теленең 90 процент лексикасы бер. Аермалар бик аз. Халыкларны берләштерү турында уйларга, эшләргә кирәк, ә монда ничек аеру, бутау, булмаган җирдә проблема уйлап табу белән шөгыльләнәләр. Бу – уйлап чыгарып проблема ясау. Башкорт – башкорт телен белсен, татар татар телен белсен. Алар телләрен белсен өчен шартлар тудырырга кирәк”.

СЫНАМЫШЛАР

6 майда яңгыр яуса, терлек-туар өчен уңышлы ел көтелә, әмма карабодай уңмаячак; кичен һәм төнлә аяз булса, җәй коры килә, игеннәр уңа; кырау төшсә, тагын кырык тапкыр кырау төшәр, дип фаразлана; чөгендер һәм кишер чәчәргә була ● 11 майда төн йолдызлы һәм җылы булса, игеннәр уңа.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **3 сәгать 49 минутта** чыкты, һәм ул **19 сәгать 31 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **15 сәгать 42 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **28 минутка озынаячак** һәм киләсе җомгада, ягъни **13 майда 16 сәгать 10 минут** тәшкил итәчәк.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

6 май – композитор, Татарстан һәм Россиянең халык артисты, Россиянең дәүләт премиясе лауреаты, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Рәшит Фәһим улы Кәлимуллинга 65 яшь (1957).

7 май – тарих фәннәре докторы, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе Рәмзи Кәлимович Вәлиевка 85 яшь (1937).

9 май – пианист, педагог, профессор, Татарстан һәм Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе Әлфия Вафа кызы Бурнашеваның тууына 80 ел (1942–2021);

– шагыйрь Әхәт (Габделәхәт) Габделхәй улы Хәбибуллинга 70 яшь (1952).

11 май – эстрада җырчысы, Татарстанның халык артисты Рөстәм Раиф улы Закировка 55 яшь (1967).

12 май – монументаль сәнгать рәссамы, сәнгать фәннәре кандидаты, профессор, Үзбәкстанның һәм Татарстанның халык рәссамы Чыңгыз Габдрахман улы Әхмәровның тууына 110 ел (1912–1995).

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Майның магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Андый көннәрне исегезгә төшерәбез: 7, 9 май.**

* * *

Гадәттә, яңа айдан айның беренче чирегенә кадәр **(30 апрель - 9 май)** организм кысылуга бара. Мондый көннәрдә үз-үзеңә физик йөкләмә бирү файдалы.

Шунысын да онытмагыз: **30 апрельдән 17 майга кадәр** талак, ашказаны асты бизе һәм ашказаны актив булучан. Шушы вакыт аралыгында аларны ныгыту һәм дәвалау уңай нәтиҗәләргә китерә.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1443 ЕЛ

Бүген шәүвәл аеның 5 нче көне

КӨН КАДАГЫНА

Исем өчен генә ачылган төркемнәр дә күп

Апрель азагында «Сәйдәш» мәдәният үзәгендә Казан балалар бакчалары хезмәткәрләрен татар телен өйрәтүдә заманча алымнар белән таныштырдылар. Бу татар телле тәрбиячеләр өчен оештырылган шәһәркүләм семинарлар циклының өченчесе иде. Казан мэриясе әлеге семинарларны Татарстан Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе ярдәме белән тормышка ашырган.

Һәр семинарга дүрт йөзләп тәрбияче чакырылган булган. Беренчесен ошатып, калганнарын да күрергә теләк белдерүчеләр барлыкка килеп, соңгыларына бишәр йөз кеше җыелган. Семинарлар сәгать ярым дәвам иткән. Һәрберсендә алты-җиде белгеч үзенең нәтиҗәле тәҗрибәсе белән уртаклашкан. Чаралар саф татар телендә барган.

Казанда барлыгы 325 балалар бакчасы бар дип карасак, һәр бакчадан якынча дүрт хезмәткәр татар телен өйрәтүдә заманча алымнар белән танышкан, дип исәпли алабыз.

Ни кызганыч, «Татар гаиләсендә туган бала бакчага киткәч, туган телендә аралашудан туктый» дигән фикерне еш ишетергә туры килә. Әлеге күренеш сәбәбен Казан мәгариф идарәсенең милли мәгариф бүлегендә баш белгеч булып эшләүче Рәйхана Баһавиева болай аңлата:

– Андый күренеш юк дип әйтеп булмый. Татар бакчаларына электрон чират аша башка милләт балалары да керә. Күп очракта татар гаиләләреннән килгән балалар да туган телен белми. Балалар татар телен аңламагач, кайбер тәрбиячеләр рус телендә аралашуга күчә, ләкин бу бик зур хата. Әгәр тәрбияче татар телендә генә сөйләшсә, бөтен бала да телне өйрәнә. Күп нәрсә тәрбиянеңең милли җанлы булуыннан тора. Әгәр бакча мөдире татар төркеменә милли җанлы тәрбияче куйса, анда татар мохите булдыруны таләп итсә, уңай нәтиҗә була. Әшне ярты көн русча гына, ярты көн татарча гына оештыручы тәрбиячеләр дә бар. Аларның да уңай нәтиҗәсе күренә.

Татар төркемнәрендә эшләүче тәрбиячеләр белән очрашкан саен: «Балалар белән күбрәк туган телдә аралашыгыз, милли мохит булдырыгыз. Даими бертөрле сөйләп торсагыз, бала аны тиз сеңдерә», - дип аңлатабыз. Безнең яктан методик ярдәм көчле. Бүгенге көндә бакча мөдирләренең милли төркемнәрдә туган телгә игътибарны арттыруы кирәк. Без килгәндә, татар төркемнәрендә эшләүче тәрбиячеләрнең бөтенесе дә балалар белән татарча сөйләшкән була, ә без киткәч, русчага күчәргә мөмкин. Мөдир бит һәрвакыт алар янында, вәзгыятьне көн саен күзәтеп тора. Шуңа күрә бу мәсьәләдә аның роле бик зур.

Казанда балаларга татар телен яхшы өйрәтүче бакчалар, төркемнәр аз түгел. Кызыксынсагыз, күрсәтә алабыз. Башка милләт балаларының да бакчада татар телен шактый камил өйрәнгән мисаллар бар. Аеруча нәтиҗәле эшләүчеләр рәтенә мин Совет районының 67 нче, 261 нче, 415 нче, 112 нче, 119 нчы бакчаларын, Идел буе районының 247 нче бакчасын, Вахитов районының 273 нче бакчасын, Яңа Савин районының 405 нче бакчасын, Авиатөзелеш районының 348 нче бакчасын, Мәскәү районының 126 нчы, 294 нче бакчаларын, Киров районының 134 нче һәм 321 нче бакчаларын кертер идем.



Авиатөзелеш районының 299 нчы бакчасында татар теле дәресләре алып баручы тәрбияче Рузалия Ханова:

– Совет заманында татар теленә бернинди игътибар да, методик ярдәмлекләр дә, әсбаплар да юк иде. Хәзер татар телен кызыклы итеп укыту өчен мөмкинлекләр бик күп. Безнең бакчада бер татар төркеме бар. Андагы балалар татарча сөйләшә белми дип әйтмәс идем. Мәсәлән, бәйрәмнәрдә сабыйлар белән рәхәтләнеп татар әкиятләрен сәхнәләштерәбез.

Авиатөзелеш районының 152 нче бакчасы тәрбиячесе Алсинә Бикбулатова:

– Татар теле тәрбиячесе вазифасына күчкәнче, мин татар төркемендә төп тәрбияче булып эшләдем. Үзем милли җанлы кеше булгач, балалар белән гел татарча гына сөйләшәм. Бераздан алар барыбер телне аңлый башлый. Башыннан азагына кадәр үзем алып барган бер төркемдәге бөтен бала татар телендә аралашырга өйрәнеп, мәктәпкә китте. Бер хатирә истән чыкмый. Рус милләтеннән бер малай бакчада отып алган татар сүзләрен әбисенә өйрәтә торган булган. Әбисе яңа сүзләрне дәфтәр битенә язып барган. Бервакыт ул боларның дөресләгән тикшертергә миңа алып килде. Мин шаккаткан идем.

Минем фикеремчә, бала татарчаны әйбәт белсен өчен, ата-ана да аның белән татарча сөйләшергә тиеш, тәрбияче дә телгә кызыксындырып эшләргә тиеш. Ике якның берсе читек булса, эшнең нәтиҗәсе югары булмый.

Вахитов районының 273 нче балалар бакчасы тәрбиячесе Алсу Әшрәпова мнемотехника ярдәмендә татар телен кызыклы һәм нәтиҗәле өйрәтү ысуллары куллана. Совет районының 261 нче балалар бакчасы тәрбиячесе Әдилә Шәйдуллина үзе үк татарча яңа уеннар, кулдан ясаган кызыклы уенчыклар уйлап тапкан икән. Яңа Савин районының 346 нчы балалар бакчасы тәрбиячесе Гөлинә Хәсәнова рәсемнәр буенча хикәя төзү, баланың иҗади сәләтен арттыру алымнарын кулланып эш итә. «Бала-Сити» бакчасының татар теле укытучылары Алинә Хәлиуллина белән Ләйсән Вәлиева балаларны әкият геройлары роленә кертеп, татарча өйрәтү ысулын ачып сала.

Семинар ахырында Казан шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Гүзәл Сәгыйтова сүз алды.

– Без быел тәрбиячеләр өчен өч семинар үткәрдек. Бу уку елында монысы соңгысы булды. Сентябрьдән без, бәлки, җитәкчеләр өчен ясарбыз. Семинар бик кызык, чөнки үземнең дә дүрт яшьлек кызым бар. Бүгенге вәзгыятьтә туган телне саклау авыр. Без, ата-аналар, эштән арып кайтабыз да, баланың кулына берәр гаджет тоттырабыз. Бала тәрбиясе бакчага гына тапшырыла кебек.

Мин бакчаларда күп йөрим. Татар телен әйбәт өйрәтүче бакчалар шактый күп. Бигрәк тә татар бакчаларында туган телне өйрәтү әйбәт куелган. Гомуми бакчаларда телгә игътибар җитеп бетми. Кайберләрендә исем өчен генә ачылган татар төркемнәре бар. Сентябрьдән аларны контрольгә алырга кирәк. Әгәр бакча мөдире чын татар төркеме булдырырга теләсә, ул аны эшли.

Казанда да татар теленә игътибарны арттырмыйча булмый. Нәтиҗәсе тизрәк күренсен.

Рифат КАЮМОВ.

intertat.tatar

Фото: obrazovanie.kzn.ru

Мәҗидегән
вакыйгалар
хәбәрләр
яңалыклар

ЫШАНЫЧЛЫ ТАЯНЫЧ

Билгесезлек шартларында зур эшләргә алынганда, адәми затка нииндидер икеләнү, тәшвишле хисләр кичерү хас. Җәмгыяви эшләрдә андый хәл үзен аеруча нык сиздерә. Чөнки психологик киртәне үтеп, уеңдагыны тәвәккәлләү өчен, ниятләреңнең гаделлеге вә хаклыгына ышанычың зур, ә аларны гамәлгә ашыруда таянычың ышанычлы булуы лязем. Әлбәттә, күп нәрсә кешенең шәхси сыйфатларыннан һәм әзерлегеннән дә тора. Тәкъва халык андый чакта үзенең ниятләгәненә, гадәттә, Аллага тапшырып тәвәккәлли. Язманы мондый пассаждан башлавым юкка гына түгел, чөнки ил-көндә бүген гадәтигә әйләнеп бара торган тетрәндергеч хәлләр һәм билгесезлек фонында охшаш халәтне күпләр кичерә. Ә милләт алдында торган зур эшләр җәһәтеннән андый тойгы вә кичерешләр бәгъзеләр өчен инде җитди проблемага да әйләнә. Нәкъ менә шул чакта кирәк тә инде бәндәләргә ниндидер булса ышанычлы таяныч. Ә аны ничек табарга? Бактың исә, ул һәрчак безнең белән. Мөэминнәр өчен мондый эшләрдә төп таяныч, әлбәттә инде – Аллаһның ихтыяры вә кодрәте. Ә татарны Рабббыбыз тәкъдири миссиясенә гасырлар дәвамында әзерләгән: аек акыл, тәкъвалык һәм асыл сыйфатлар биргән, тарих сынаулары һәм каршылыклар аша, хәзерге хәленә китереп җиткергән. Хәтта бүгенге фаҗигале чынбарлык та, Аның ихтыяры белән, тәкъдири сынау юлында милләт өчен таяныч булып тора. Чөнки, хактан да, бүгенге глобаль кризистан чыгуның Аллаһ кануннары буенча яшәүгә кучүдән башка юлы юк.

Хәлбуки, кешелекне илаһи яшәеш юлына кайтаруда Хак Тәгалә татарга тәкъдири миссия йөкләп кенә калмый, ә үз киләчәген өметле итүдә аңа тарихи шанс та бирә. Димәк, милләттәшләребездән җаваплылыкны бөтен тулылыгы белән тою, зур оешканлык һәм эш-гамәлләрне иҗтиһат юлына күчерү таләп ителә. Хактыр ки, милләтара мөнәсәбәтләрне бары тик тигез хокуклылык шартларында гына уңай хәл итеп була. Әмма илдә хәлләр тиздән тагы да кискенләшергә мөмкин. Ул чакта инде зур кыенлыклар татар-рус мөнәсәбәтләрен метасәяси максатларга җайлау юлында да килеп чыгарга мөмкин. Ә мондый эштә ниндидер инструкцияләр юк һәм алар була да алмый. Шуның белән бергә, кайбер методик тәкъдимнәр анда һич кенә дә артык түгел кебек. Әйтик, катып калган «шовинист»ларны үзгәртергә омтылу вакытны бушка уздыру гына булыр иде. Шуңа эшне күбрәк аек акыллы кешеләр белән алып бару зарур. Тарихи үткәнебезне вә милли тәрбиядәге үзенчәлекләрне истә тотсак, оппонентлар белән тирән бәхәскә керү дә тискәре нәтиҗәгә генә китерергә мөмкин. Шуңа аңлашуларны сорауларга җавап рәвешендә үткәрү отышлы. Ә сорауларның мондыйрак форматта булуы мәслихәт: Урталык җирләрендә әүвәл ирекле төстә ислам кабул ителүе, соңрак исә көчләп христианлык та кертелүенең максаты нинди? Тарихта иң күп канкоешлар ни өчен Россиягә туры килә? Дөньяның иң зур һәм табигый ресурсларга иң бай илендә халыклар ни өчен гасырлар дәвамында хәерчелектә яши? (һ.б.). Аңлашыла ки, гакыллы кеше аларга нигезле җавап эзли һәм метасәяси яктан отыры үзе дә теләктәш була. Ә андыйларның туплануы инде уртак эштә таяныч булып та үсеп җитә.

Әлбәттә, күп нәрсә бүген татарның үзоешу таланты һәм ихтыяр көче белән билгеләнә. Бу тулысы белән милләтнең киләчәгенә дә кагыла. Чөнки татарның киләчәге үзенә йөкләнгән миссияне уңышлы үтәгәндә генә өметле була ала. Ә бит, зурдан алганда, аннан бүген көч җитмәслек гамәлләр таләп ителми. Бүгенге хакыйкать аның өчен аңлаешлы һәм гади: илаһият кануннары буенча яши башла, башкалар өчен үрнәк бул, яшь буынны үз рухында тәрбиялә, үз тирәңдә һәм виртуаль киңлекләрдә теләктәшләреңне вә фикердәшләреңне арттыр. Моның белән син бернинди законнарны да бозмыйсың, үзеңне һәм башкаларны нинди дә булса куркыныч астына куймыйсың, киресенчә, җәмгыятькә игелек вә изгелек кенә китерәсең. Монда инде уңышсызлыклар да кемнедер гаепләргә кирәк булмый: бар нәрсә үзеңнән һәм фәкать үзеңнән генә тора. Иң мөһиме – син моны Аллаһ ризалыгы һәм газиз милләтеңнең киләчәген ышанычлы итү өчен эшлисең, шул рәвешле, милләтләр вә диннәр арасында гармонияле мөнәсәбәтләр урнаштыруга һәм Җирдә яшәешне цивилизацион күптөрлелек берлеге итеп үзгәртүгә үз өлешеңне кертәсең. Хәерле сәгатьтә, Аллага тапшырып, алга, милләттәшем!

Фоат УРАЗАЙ.

Яңа мәчеттә тәүге намаз

Ураза бәйрәме көнендә, Казан шәһәре Залесный бистәсендә яңа иман йорты – XX йөз күренекле мөселман дин эшлеклесе Әхмәтзәки хәзрәт Сафиуллин исемен йөрткән мәчет ачылды. Башкалабызның Киров һәм Мәскәү районнары мөхтәсибәтендә 16 нчы мәчет ул.

Әхмәтзәки хәзрәт исемендәге мәчет үз эченә күп гасырлык татар-мөселман архитектурасы традицияләрен сеңдергән. Федераль салым хезмәтенең Татарстан буенча идарәсе җитәкчесе Марат Сафиуллинның бабасы Әхмәтзәки хәзрәт 1970-1990 елларда Казанның Мәрҗани мәчете имамы булган.

Мәчет төзелеше 2018 елда башлана. Гыйбадәт залы 500 кешегә исәпләнгән мәчет комплексына мәдрәсә, имам йорты, дини хезмәтләр күрсәтү бинасы, ислам әдәбияты һәм мәгърифәте йорты, хуҗалык бинасы кергән. Мәчет янәшәсендә корбан чалу урыны, хәләл азык-төлек кибете булдыру күздә тотыла, шулай ук мәетләр озату хезмәте каралган. Заман таләпләре искә алынып, гыйбадәтханә янында 70 ләп машиналык парковка булдырылган.

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов гает намазын шушы яңа мәчеттә укыды. Тантаналы вәгазьне һәм намазны Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте рәисе Камил Сәмигуллин үткәрде.

Кунаклар сокланырлык киемнәр

«Казан Кирмәне» музей-тыюлыгында Изольда Сахарова җитәкчелегендә «Мисс Татарстан» бәйгесендә катнашкан модельләр XIX гасырдагы һәм заманчалаштырылган татар милли киемнәрен туристларга күрсәтте.

«25 ел дәвамында без Татарстанның төрле чараларында күрсәтә торган коллекцияләр булдырдык. Матурлык бәйгесендә катнашкан кызларыбыз сәхнәгә татар милли киемнәрен киеп чыга, аэропортта һәм мөселман кинофестивалендә кунакларны каршы ала. Аерым подиум мәйданчыгын оештырырга, тамашаның даими булуын телим. Музей экспозицияләренә бу заманча концепт кертәчәк», — диде модельер Изольда Сахарова.

Оештыручылар әйтүенчә, алга таба бу урынны туристларны җәлеп итү үзәкләренең берсе буларак кулланырга планлаштыралар, чөнки биредә борынгы костюмнар экспозициясе дә, аларның заманча стилизациясе дә урнашачак, яңа алым белән тегелгән милли киемнәрне сатып алырга мөмкин булачак. Башкала халкы һәм кунаклары өчен көненә икеөч тапкыр костюмнарны тәкъдим итү подиумын оештырырга телиләр.

И.Сахарова XIX гасыр костюмнарының яңадан торгызылганлыгын әйтте. «Сез борынгы ефәк, итальян винтаж тукымасын, коллекционерлардан сатып алынган тарихи татар бизәнү әйберләрен күрә аласыз», – диде ул. «Бер костюмны элекке замандагы кебек итеп хәзерләү өчен йөз мең сум кирәк булырга мөмкин. Мәсәлән, коллекционерлар базарында шул заман бер брошкасы 5 мең сум тора. 200 ел элек булган татар муенсасы 50 мең сумга төшәргә мөмкин. Мондый костюмнарны ясау өчен, Бөек Ватан сугышы чорында Россиягә кергән Кытай ефәген файдаланалар. Бу костюмнар сатылмый, әмма тарихны бүгенге көндә дә күрергә мөмкин», – диде Сахарова.

Күпчелек костюмнарның авторы – Солтан Салиев. «Бу – XIX гасырның алтын коллекциясе, безнең мәдәни интеллигенция нәкъ менә шундый костюмнарда йөргән. Хәзер аларны кию бик актуаль икәнен, моның безнеке, татарныкы булуын исбатларга телибез», – ди Салиев. Подиумда модельер Руслан Габовның ир-атларның милли-тарихи костюмнары коллекциясе дә күрсәтелде.

Зилә МӨБӘРӘКШИНА.
Рамил ГАЛИ фотосы.

Хисле Тукай тамашасы

«Черек күл» паркында Г.Кариев театры артистлары «100 Тукай» шигъри-хореографик перформансын куйды. Казан мэриясе ярдәме белән оештырылган чара Габдулла Тукайның тууына 136 ел тулуга багышланды.

Русча «Многоликий Тукай» дип исемләнгән перформансны Г.Кариев театры актеры Эльдар Гатауллин сәхнәләштерде, хореографы – Елена Музеева. Тамашага әзерлек ике атна дәвамында барган. Перформанс артистларның үзләре әзерләгән композицияләреннән тупланган.

«Балачактан Тукайның шигырьләрен сөйләп үстем. Минем өчен Тукай милли каһарман ул. Бөек шагыйребез турында мәгълүмат күп. Шуңа да бу перформансны ничек итеп оештырырга икәнлеге турында күп уйландык. Үзем дә артистларга «Сезнең өчен Тукай кем ул? Аңа үзегез нинди сорау бирер идегез?» дип мөрәҗәгать иттем», – диде Эльдар Гатауллин.

Перформанста Тукай шигырьләре һәм актерлар үзләре язган текстлар яңгырады. Чара дәвамында артистлар биредә шагыйрьнең иҗаты, тормыш юлы аларның күңелендә нинди хисләр тудыруы турында сөйләде, Тукайга хат та язды. Тукай фотографияләре, шигырьләре сурәтләнгән кублар чараның декорацияләре буларак хезмәт итте.

Татарстаннан читтә яшәүчеләр игътибарына

*2022 елның икенче яртыеллыгына **«Мәдәни җомга»** газетасына Татарстаннан читтәге өлкә-республикаларда да – Башкортстан, Оренбург, Ульяновск, Төмәндә һәм башка төбәкләрдә язылып була. Газетабыз электрон каталогка кертелгән **(язылу индексы – П8254).** Игътибар! **«Мәдәни җомга»** газетасын почта бүлекчәләрендә электрон каталогтан эзләтегез.*

1 нче биттә – Җиңү көне бәйрәменнән бер мизгел. Фото: pxhere.com

Татарстанлылар Алтай китап бәйрәмендә

Апрельнең соңгы көннәрендә Таулы Алтайда «Книжный Горный Алтай» («Китаплы Таулы Алтай») I Бөтенроссия китап күргәзмә-ярминкәсе узды. Россия китап басучылары ассоциациясе ярдәмендә үткәрелгән күргәзмә-ярминкә М.Чевалков исемендәге Милли китапханә бинасында узган. Билгеле ки, Россиянең Мәскәү, Рыбинск, Киров, Якутск, Кызыл, Абакан, Омск кебек шәһәрләреннән 30 дан артык нәшрияты катнашкан китап бәйрәме төбәк өчен зур вакыйгага әверелгән. Бу күргәзмә-ярминкәдә Татарстан китап нәшрияты да үз басмаларын тәкъдим итте. Нәшриятның баш редактор урынбасары Венера Шәмсетдинова хәбәр иткәнчә, татарстанлылар балалар өчен басмаларны, тарихи әдәбият, татар әдәбияты классикларының һәм бүгенге көндә иҗат итүче авторларның китапларын алып барган. Күргәзмәнең

беренче көнендә казанлылар стенды янында Алтай Республикасы башлыгы Олег Хорохордин кунак булган. Аны Татарстан китап нәшрияты генераль директоры Илдар Сәгъдәтшин нәшрият тарихы, нәшер ителүче китаплар белән таныштырган. Алар шулай ук нәшриятларның хезмәттәшлек мөмкинлеге турында фикер дә алышкан. О.Хорохордин, үз чиратында, тәкъдим ителгән китапларны уңай бәяләп, Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов кебек үк, төрки дөньяның килеп чыгышы Алтайда башлана, дигән фикердә торуын белдергән. Күргәзмә-ярминкә кысаларында яңа китаплар тәкъдим ителгән, Россия китап басучылары ассоциациясенең «түгәрәк өстәл» утырышы, наширләр, язучы һәм китап сатучылар өчен осталык дәресләре узган.

Сөембикә КАШАПОВА.

Галим рухына Коръән

Истанбулда күренекле татар-төрек галиме, тарих һәм сәясәт белгече Надир Дәүләтне искә алдылар.

Вафатына бер ел тулган көнне кабере янында мәрхүмнең рухына Коръән аятьләре укылды. Истанбулның Зинҗирликую мәчетеннән махсус килгән имам догаларын Надир Дәүләтнең әти-энисе Гайниҗамал – Әхтәм Дәүләт һәм апасы Рәшидә Бури рухларына да багышлады.

Кабер янында искә алу чарасын мәрхүмнең тормыш иптәше Берил Дәүләт оештырган. Анда Надир Дәүләтнең соңгы ассистентларының берсе – галимә Ләйсән Шаһин да катнашты.

«Кара диңгез буендагы дачабызның бакчасында Надир бәрхет чәчәкләре үстерде. Түтәлләрен диңгездән җыеп кайткан ак ташлар белән бизәргә ярата иде. Мин дә каберен аныңча бизәдем. Рамазан ае булу сәбәпле, халык җыймаска булдым. Кабере башында тыйнак кына укылган догалар да Надирымның рухына барып ирешер, дигән өметтә калам», – диде мәрхүмнең хатыны Берил Дәүләт.

Кабер янында Надир Дәүләтнең Казанда яшәүче бертуган сеңлесе Фәридә Дәүләткилденең бер көн элек кенә язган хатирәсе дә укылды. «Язмышның ачы җиле аркасында абыем Надир белән бергә үсү насыйп булмады. Аның белән танышканда миңа – 44, абыема 46 яшь иде. Ләкин бертуган абыем барлыгын кечкенәдән үк белеп үстем. Гомер буе шундый дәрәҗәле абыем булуы белән горурландым. Танышкан көннән башлап соңгы көненә кадәр ул минем терәгем, яклаучым булды. Ул безне дөньяга китергән һәм Казанда җирләнгән әниебезнең, Кызыл Ярда вафат булган әтиебезнең кабер ташларын яңартуга да зур игътибар бирде, иң кирәкле вакытта, иң кыен чакта абыемның җылысын тоеп яшәдем. Бүген исә үземне тома ятим хис итәм. Күңелем аның юклыгын кабул итә алмый», – дип искә алган ул абыйсын.

Берил Дәүләт язган һәм татарчага тәрҗемә ителгән биографик китап якын көннәрдә Татарстанда нәшер ителәчәк.

Татар-төрек галиме Надир Дәүләтнең вафатына бер ел тулу уңаеннан Төркиянең Мимар Синан исемендәге нәфис сәнгать университеты искә алу җыены үткәрде. Аны Ататөрек принциплары һәм инкыйлаб тарихы тикшеренү үзәге мөдире, галим Исмәгыйль Түркоглу оештырды.

Рушания АЛТАЙ.

Татар телен сайт аша өйрән

Татарстан мөселманнарының Диния нәзарәте татар телен өйрәнү өчен «Без - татарлар» дип аталган онлайн-платформа ачып җибәрде. Ул Диния нәзарәтенең «Хозур» нәшрият йорты тарафыннан эшләнде. Платформа 2018-2021 елларда республикабыз мәчетләрендә уңышлы оештырылган курсларның программасы һәм аларда кулланылган «Татар теле. Башлап өйрәнүчеләр өчен» уку әсбабы нигезендә эшләнгән. Beztatarlar.ru платформасын эшләүдә Россия ислам институты, КФУ укытучылары катнашкан. Онлайн ресурс сөйләм телен өйрәнү, баету, аралашу күнекмәләрен үстерүгә юнәлдерелгән.

Әлеге платформа Диния нәзарәтенең соңгы ике елда «Хозур» нәшрияты тарафыннан тормышка ашырылган икенче белем бирү проекты булып тора. Моңа кадәр эшләтеп җибәрелгән Medrese.tatar татар онлайн-мәдрәсәсендә бөтен дөньядан 50 меңгә якын кеше ислам нигезләрен үзләштерә. «Без -татарлар» платформасының түләүсез онлайн-дәресләреннән файдалану өчен, электрон почта яки социаль челтәрләрдәге сәхифә ярдәмендә теркәлү узарга кирәк. Теркәлгәннән соң, кулланучы 5 төп бүлеккә тупланган 49 дәресне (фонетика һәм грамматика нигезләре, әңгәмә әдәпләре, гаилә һәм йорт, ислам этикасы һәм дини бәйрәмнәр буенча темалар) бушлай үзләштерә алачак. Дәресләрне үзенә уңайлы вакытта һәм уңайлы форматта: видео, аудио яки текст рәвешендә сайлап алу мөмкинлеге бар. Һәр бүлек тәмамлану белән укучыларга узган материал буенча тест узарга тәкъдим ителә.

Эльмира СИРАҖИ.

Логотип расланды



Россия Федерациясе Вице-премьеры Марат Хөснуллин Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулуга багышланган чаралар өчен логотипны һәм брендбукны раслады. Документта логотипның параметрлары һәм аның тасвирламасы язылган. Брендбукта шрифтлар һәм башка график элементларның үрнәкләре күрсәтелгән. Алар бәйрәм атрибутларына куелу өчен кулланылачак.

Ак мәчет янә читкә тибәрелә

Казанның Яңа татар бистәсендә урнашкан Ак мәчеткә куркыныч яный. Бу хакта Татарстан мәдәни мирас объектларын саклау комитеты хәбәр итә.

Мәчеткә зыянны юл төзүчеләр китергән дип санала. Эшчеләр мәчет бинасы буенда торган бетон киртәләрне салдырып, аны гыйбадәтханә диварына терәтеп куйган.

«Бу болай да авария хәлендә булган объектка көч килүне арттырган. Комитетның хезмәткәрләре тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәсендә кирпеч диварда ярыклар барлыкка килүе ачыкланган. Моннан тыш, мәчет биләмәсендә төзелеш чүп-чары җыелып барган», диелә комитет хәбәрендә.

Ак мәчет – 1801-1805 елларда төзелә. Бина урта гасыр болгар, татар халык архитектурасы, классицизм архитектурасы элементлары кулланып салынган. Ул Кызыл Татарстан урамында урнашкан.

Совет хакимияте 1929 елда мәчетне яба. 1930 елда мәчет манарасы сүтеп алына. Заманында монда мәктәп, аннан мех берләшмәсенең цехлары була.

Өч ел элек бер төркем татар яшьләре Казанның Яңа бистәсендә урнашкан ташландык хәлдәге Ак мәчеткә җәмәгатьчелек игътибарын җәлеп итү максатыннан ифтар оештырган иде.

● BP энергетика компаниясе белгечләре исәпләп чыгаруынча, хәзер дөньяда барлыгы 1383,2 миллиард баррель нефть ятмасы бар. 2010 елдагы кадәр күләмдә чыгарылса, нефть тагын 46 елга җитәчәк. Россиядә дөньядагы нефть ятмаларының 5,6 проценты (77,4 миллиард баррель) тупланган, бу – якынча 20 елга җитәрлек запас.

● Дөньядагы газ ятмалары исә 187,1 триллион кубометр тәшкил итә, 2010 елдагы кадәр күләмдә чыгарылган очракта, запас 59 елга җитәргә тиеш. Россиядә планетадагы газ ятмаларының 23,9 проценты (44,8 триллион кубометр) урнашкан, ул тагын 75 елга җитәчәк.

● Иң күп нефть ятмалары Согъд Гарәбстаны, Венесуэла, Иран, Гыйрак, Кувәйт, Берләшкән Гарәп Әмирлекләрендә, иң күп газ ятмалары Россия, Иран, Катарда урнашкан.

Әлбәдәндә Герой яшәгән

Моннан 12 ел элек Советлар Союзы Герое, Брест крепостеның соңгы саклаучысы Петр Гавриловның туган авылында – Питрәч районындагы Әлбәдәндә каһарманның тууына 110 ел тулу уңаеннан аның истәлекләрен саклый торган музей булдырылды.

Петр Гаврилов керәшен татарлары яшәгән хәзерге Питрәч районының Әлбәдән авылында 1900 елда ярым җир йортта яшәүче гаиләдә икенче бала булып дөньяга килә. Ул туарга ике ай кала, аның әтисе бу дөньядан үтә. Музейда сакланган чиркәү метрикә кенәгәсенең беренче юлында ук малайның туу вакыты теркәлгән. Авылда барысының да өй түбәләре саламнан, ә аларныкы кызыл балчыктан була. Музейда Питрәч коррекция мәктәбе укучылары эшләгән өй макеты аны шактый тулы күз алдына китереп бастыра. Петр әнисе һәм тумыштан чукрак һәм телсез абыйсы белән яши. Еш авырган әниләре балаларны туендыру өчен кешеләрдә көнлекче булып эшләп, кер юып тормыш алып бара. Күршеләр хатирәсе буенча балалар әледән-әле якын-тирә авылларда хәер сорашып та йөргән.

П.Гаврилов 4 ел, ике чакрым ераклыктагы күрше авылга йөреп, Чиркәү мәктәбендә укыган. Аннары әнисенә тормыш алып барырга булышу өчен алпавытка ялланып эшләгән, сату итәргә базарга да барган. Аннан калада завод булуын, анда эшләгән өчен күп акча бирүләре турында ишетеп кайткан һәм шунда китәргә дип карар кылган. Әмма бу вакытта аңа 14 яшь кенә була, шәһәргә бару өчен документ кирәк. Аңа писарьнең күпмедер акча бәрабәренә документ язып бирәчәген әйткәннәр. Ул писарьга түләү өчен бер сум акчаны ел буе җыйган. Ниһаять писарь, үсмергә 15 яшь дип, документ язып биргән.

Петр җәяүләп Казанга чыгып китә. Казанда булышчысыз, таянычсыз үсмергә башта бик авыр була. Ул беренче вакытларда ишек алды себерүче, аннары пекарняда йөк төяүче булып эшли, соңрак дары заводына урнаша. Гражданнар сугышы башлангач, егет үз теләге белән Кызыл Армия сафларына языла. Шушы вакыттан П.Гавриловның хәрби карьерасы башлана. Егеткә хәрби булу ошый, ул Кызыл командирлар курсын да тәмамлый, аны Краснодарга җибәрәләр, 22 нче укчы дивизиягә билгелиләр. Егет анда Екатерина Григорьевнага өйләнә, әмма аларның үз балалары булмый, соңрак уллыкка Николай исемле малайны алалар. Петр укуын дәвам итәргә тели һәм Мәскәүдә кичке мәктәптә урта белем ала, инглиз телен дә өйрәнә, Фрунзе исемендәге хәрби академияне дә уңышлы тәмамлый. Яшь майорны гаиләсе белән Брест крепостена җибәрәләр. Музейда бу вакыйганы Брест крепостеның коррекция мәктәбе коллективы эшләгән Тихвинская капкасы макеты искә төшерә.

Нығытмада 8000 тирәсе кеше булган. Алар – хәрбиләр һәм гади халык.

Бөек Ватан сугышы башланганда, Петр Гавриловка 41 яшь була. Ул - Гражданнар, совет-фин бәрелешләрендә катнашкан, Владикавказга барып җиткән, Кубаньны азат иткән тәҗрибәле офицер. Әлбәттә, П.Гаврилов сугыш башланган очракта, тирә-ягы су белән әйләндереп алынган нығытмадан бер капка аша барысын да эвакуацияли алмаячакларын аңлаган һәм бу хакта кисәткән. "Без божрада калачакбыз", – дигән. Әмма аңа ышанмыйлар, солдатлар арасында "смута" тудырган өчен партиядән чыгарырга телиләр, 27 июньгә утырыш та билгеләнгән була.

22 июньдә Бөек Ватан сугышы башлана. Коточкыч мәхшәр тулы көннәрнең башы. Диверсантлар тарафыннан элемтә өзелә, корал җитми. Беренче биш тәүлек иң катлаулы көннәр була. П.Гаврилов бу хәлдә, крепостьны саклауны үз кулына алып, халык арасындагы паникага чик куярга тырыша.

Төрле кыенлыкларга карамастан, дошманның беренче һөҗүмнәренә каршы торалар. Гитлерчылар моны көтмәгән була. Алар су үткәргечләрне җимерә, крепость сусыз кала. Моннан тыш крепость эчендәге сулыклар агулана, атышлардан күп солдатлар һәлак була, яраланучылар да хәтсез. Кешеләр дошманга штык, сәнәкләр, кирпечләр белән каршы тора. Гаврилов бишенче көнне, хатын-кызларны һәм балаларны саклап кала алмаячакларын аңлагач, әсир булып төшәргә күндерә, бәлки исән калырсыз, ди. Сугышның беренче көннәрендә яралыларны әсир итеп алмаганнар, Брест крепосте сакчылары каршында ук атып үтергәннәр. Гаврилов җитәкчелегендә Көнчыгыш форт оборонасы 30 көн дәвам итә. Дошман хәтта башта – 600 килограммлы, аннары 1,8 тонналы авиабомбалар куллана. Аларның шартлавыннан җир тетри. Экспозициягә, бу вакыйгаларны, Брест крепостеннан алып кайткан көйгән кирпечләр һәм җир, фляга, револьвер, крепость манзарасы күренеше искә төшерә. Крепость турындагы сирәк китаплар, брошюралар да – кадерле ядкәрләрдән.

Шартлаулардан нығытмада булганнарның барысы да, Гаврилов та контузия алган. Сугыштан соң ул уң аякка аксаклаган, начар ишеткән, гомеренең соңгы елларында таяк белән йөргән. Оборонаның 30 нчы көнендә нығытмада алар берничә кеше генә калган. Майор үзенең соңгы приказын биргән. Үзе исә тимер юл буйлап үзебезнекеләр янына чыгармын, дип уйлаган. Әмма Гаврилов атлар тотыла торган конюшняга эләккән, анда хайваннар ашый торган комбиазык белән тукланып җан асраган, төннәрен каналга төшеп су эчкән. Хайван ризыгыннан алтынчы көнне аның эче авырта башлаган. Тирес өемен казып качып ятканда аңын югалтып алган, вакыт исәбен белештермәгән. Обход ясап йөргән

немецлар Гавриловның ыңгырашуын ишетеп туктап калган. Немец солдатлары башта, совет солдатлары күптер дип уйлап, конюшняга керергә курыккан, үзләренә ярдәм алып килгәннәр. Гаврилов кычкырып немецча сөйләшкән тавышлардан аңына килгән һәм ике автоматчыны күргән. Бу куркыныч хәл аңа күпмедер көч биргән. Гаврилов аяк тавышларын ишеткәч, пистолетыннан һәм төрле тарафка соңгы гранаталарын аткан. Шулай итеп, ул ярым аңсыз хәлдә әсирлеккә эләгә. Ялгызы крепостьны саклаган хәрбине карарга хәтта немец генералы килүе дә мәгълүм. Аның батырлыгына ихтирам йөзеннән ул Гавриловны госпитальгә җибәрергә кушкан. Аны дәвалаган госпиталь табибе әсирнең кыяфәтенә карарга куркыныч булуын сөйли. Яралы майорның хәрби киеме теткәләнеп беткән, йөзе дары корымы һәм тузан белән капланган, сакал-мыегы нык җиткән була, үзе исә тире белән тарттырылган сөяктән генә тора. Әсирнең хәтта азык та йотарлык хәле дә булмый. Табибләр аны башта ясалма тукландыра. Майор хакында аны әсирлеккә алган немец солдатлары лагерь табибләренә көчкә генә җан асраган бу кешене бер сәгать элек кенә нығытма казематларының берсендә табуын, ялгызы сугыш ачканлыгын, берничә гитлерчыны үтерүен һәм яралавын сөйлиләр.

Майор үзенең әсирлеккә эләккәнен өченче көнне генә аңлый. Әсирләр арасыннан булган табибләр тоткынны тиф белән чирли, дип әйткән, ә немецлар андый баракка керергә курыккан. Аның турында беркадәр вакыт онытып та торганнар. Гаврилов әкренләп йөри башлагач, аны лагерь кухнясына эшкә урнаштырганнар. Сорау алу вакытында Гаврилов фамилиясен яшергән, үзен лейтенант Галкин, дип атаган. Майор икәнен белсәләр, аны да, мөгаен, Маутхаузен концлагеренда үтерелгән Д.Карбышев язмышы көткән булыр иде. 1942 елда концлагерьда Гаврилов генерал Д.Карбышев белән дә таныша. Гавриловны төрле концлагерьларга күчереп йөрткәннән соң Хаммельсбургка совет офицерлары концлагерена китерәләр.

Кызыл Армиянең фашистларны җиңүе генә әсирләргә ирек алып килә. Фильтрация лагерендагы тикшерү Гавриловның тулысынча гаепсез икәнлеген күрсәтә. Ул барлык сорау алуларны уза, "Сез нигә исән калдыгыз?" – дигән сорау аңа аеруча еш бирелә. Барлык тикшерүләрдән соң аның званиесен кайтаралар, әмма партия билетын бирмиләр. Гавриловны Себергә япон хәрби әсирләрен сакларга җибәргәннәр. Майор 1945 елда Әлбәдәнгә кайта. Ул вакытта әнисе дә исән булган әле. Гаврилов әнисе белән җир өйдә яшәгән. Әмма авылда аны ватанын саткан кеше итеп исәпләгәннәр. Әлбәдәндә бер ел яшәү дәверендә аңа хәтта атны да ышанып тапшырмаганнар, үгез җигеп эшләргә кушканнар. Ул көтү дә көткән, көз көне бәрәңге дә чүпләгән. Аны төрлечә мыскыллаганнар, өстенә бәрәңгеләр атканнар. Гаврилов Краснодарга китә. Биредә ул икенче тапкыр (хатыны- Мария Краснова) өйләнә, төрле эшләрдә эшли, пенсиясе кечкенә була. Әмма гаиләне туендырырга яшелчә бакчасы булышкан.

Петр Гаврилов ел саен 22 июньдә Брестка бара торган була. Бервакыт аның янына бер хатын-кыз килә, аны белүен, хатыны Екатерина Григорьевнаның исән икәнлеген, 1952 елда аның параличлануын, торып йөри алмавын, хәзер Брестта инвалидлар йортында яшәвен әйтә. Гаврилов беренче хатыны янына интернатка китә һәм аны Краснодарга алып кайта. Юл буе бу хәлне икенче хатыны ничек кабул итәр, дип борчыла. Әмма Мария Краснова Екатеринаны бертуганы кебек кабул иткән, аны кашыктан ашаткан, шулай да авыруы көчле хатын озак яшәмәгән. Аңардан Гаврилов тәрбиягә алган улының да исән икәнлеген белгән. Бүгенге көндә оныклары, оныкчыклары бар, алар Краснодарда яши.

Герой соңгы елларына кадәр бик актив иҗтимагый эш алып бара, мәктәпләрдә балалар, Совет Армиясе солдатлары белән очраша. Гаврилов биш ел саен Әлбәдәнгә кайтып йөри. Ул 1979 елда Краснодарда вафат була. Аның җәсәден Брестка алып килеп гарнизон зиратында җирлиләр.

Музейда Гавриловның хәрби формасы, фуражкасы, сәгате, документлары, фоторәсемнәре саклана. Мирасханәдәге иң кадерле ядкәр исә – Гавриловка Советлар Союзы Герое исеме бирелү турындагы таныклык. Петр Гаврилов керәшен татары булгач, экспозициянең бер өлеше керәшен мәдәниятенә һәм йолаларына багышланган.

Әлбәдәндә П.Гаврилов исемен мәңгеләштерү дәвам итә. Биредә мемориаль музей комплексын төзергә ниятлиләр. Анда XX гасырның ярлы гаиләсе яшәгән җир йортны да торгызачаклар, Геройның бюстын куя да планлаштырыла. Комплекска авыл янындагы тирәлек тә керә. Окоплар казылган бу урында хәзер «Әлбәдән» хәрби уен фестивале үткәрүне гадәт иткәннәр.

Сөембикә КАШАПОВА.
Автор фотолары.

М.Фомин.

В.Бурмистров.

В.Белоусов.

В.Пискунов.

П.Сафронов.

М.Суднишников.

Бер мәктәптән – алты герой

Менделеев шәһәрендәге бер мәктәп Алты Советлар Союзы Герое тәрбияләп үстергән. Уку йорты 1936 елда ачылган. Ул чакта бу торак пункт Бондюг бистәсе дип йөртелгән.

Советлар Союзы Геройларының дүртесе туган якларына исән-имин кайткан. Кызганыч, икесе – Михаил Фомин һәм Вилен Бурмистров яу кырында ятып калган.

М.Фомин урта мәктәпне 1941 елда тәмамлый. Сугыш башлануга бер-ике көн кала аттестат ала. Сугышка китәргә теләп, хәрби комиссариатка гариза илтә. Әле яшь дип аны фронтка җибәрмиләр. Михаил химия заводына аппаратчы булып урнаша. Бераздан аны яңгыннан саклану бүлегенә күчерәләр.

Күрәсең, физик әзерлеге яхшы булгандыр, 1942 елның гыйнварында аны армиягә алалар. Артиллерист итеп билгелиләр. Беренче чыныгуны Фомин Сталинград сугышында үтә. Аннары аларның дивизиясе Курскига җибәрелә. 1943 елның 5 июлендә биредә немецларның куәтле һөҗүмнәре башлана. Поныри станциясенә фашистларның йөзләрчә танклары тупланган була.

Фомин хезмәт иткән батарея һөҗүмне өч көн дәвамында кире кайтарып тора. Совет гаскәрләре позициясен дошман самолетлары туктаусыз бомбага тота. Миша яралана, әмма позициясеннән китми. Снаряд кыйпылчыгы орудия командирын үтергәч, Михаил Фомин җитәкчелекне үз кулына ала. 1943 елның 7 июлендә сержант Фомин дошманның 5 уртача һәм 2 авыр танкын, танкка каршы орудиесен, ике пулеметын, ротадан артык солдатын юк итә, 12 атакасын кире кайтара. Миша үзе дә яралана. Аны госпитальгә салалар. Әмма үлемнән коткарып кала алмыйлар. 20 яшь туларга ике ай кала, ул бакыйлыкка күчә.

Мәктәпнең икенче катында, Фомин белән янәшәдәге класста Бурмистров укыган. Аның әтисе Иван гражданнар сугышында катнашкан, Кама буенда Совет хакимиятен урнаштырган, Колчакка каршы сугышып йөргән. Шуңа күрә аның – улына Владимир Ильич Ленин дигән исемне кыскартып Вилен дип кушуы гаҗәп түгел. Вилен Бурмистров та фронтка омтыла. Сугыш башланганда, аңа бары уналты яшь кенә булганга, Виленны фронтка җибәрмиләр. Солдат шинелен ул бары 1943 елның гыйнварында гына кия.

Гвардия мотоукчылар бригадасының Бурмистров хезмәт иткән батальоны сентябрьдә беренчеләрдән булып Днепрны кичә. Алар «Днепр валы»н штурмлый. Яхшы коралландырылган бетон валны берәү дә ала алмаячак дип саный немецлар. Батальон фашистларның 209,7 биеклегендәге терәк пунктларын ала. Биредән әйләнә-тирә уч төбендәгедәй ачык күренә.

Вилен немецлар траншеясына беренче булып бәреп керә. Гранаталары һәм автомат уты белән дошманның тулы бер взводын туздырып ташлый. Дошман да туктаусыз һөҗүм итә. Отделениегә көн дәвамында гына да немецларның унбер атакасын кире кагарга туры килә. Нәтиҗәдә старшина Бурмистров һәм аның дүрт солдаты гына исән кала. Хәрби припаслар бетә, немец коралларын кулланырга туры килә.

Вилен безнекеләрнең ярдәмгә килүен көтеп өлгерә алмый. Немец снайперы пулясы аның гомерен өзә. Старшина Бурмистров гвардиячеләре оборонада нык тора. Командир шәхси үрнәге белән сугышчыларын хәрби бурычны үтәүгә туплый. «Немец фашистлары белән тигезсез сугышта улыгыз батырларча һәлак булды», - дип яза әти-әнисенә батальон командиры.

«Биредә көннәр җылы – тузан, кояш. Гомумән, мин биредә салкын көннәр күрмәдем. Февральдә үк инде кар юк иде. Монда күргәннәрне бер кәгазь битенә генә сыйдырып булмый. Моның өчен зур калын китап язарга кирәк. Очрашкач барысын да сөйләрмен. Хәзергә җитеп торыр. Безнекеннән дә матуррак ил юк ул. Кайда гына булмадым, безнең ил иң матуры», – дип яза 1945 елның апрелендә Германия чигеннән Михаил Суднишников классташы Анна Ешуговага.

Суднишников Ленинградта зенит артиллериясе һәм разведка училищесын тәмамлаган. Ул җитәкчелек иткән артиллерия батальоны дошманны һич көтелмәгән операцияләре белән таң калдырган. 1944 елның җәендә төнлә Суднишников батальоны немецлар позициясен камап ала. Ә иртән аңа ут яудыра. Тәртипсез рәвештә атлагаланган немецлар качып котыла. Моңарчы берәү дә дошман оборонасын атна дәвамында да өзә алмаган. Суднишников батальоны бу сугышта бер кешесен дә югалтмаган. Сугыштан соң Михаил армия хезмәтен дәвам итә. Аннары ул Мәскәүгә кайта. Фәнни-тикшеренү институтында эшли, озак кына хәрби академиядә укыта.

Очучы Василий Пискунов Берлинга аз гына барып җитми. Советлар Союзы Герое исеме бирелгәндә, аның батырлыгы турындагы мәгълүматлар биш кәгазь битен тутыра. 6 Ил-2 самолетыннан торган Пискунов җитәкчелегендәге төркем дошманга каршы бер көн эчендә генә дә 150 һөҗүм оештыра. Дошманның 12 үзйөрешле машинасын, 10 минометын, хәрби җиһазлар тутырылган 4 складын, ике батареясын, 250 гә якын солдатын һәм офицерын юк итә. Фашистларның 27 самолетын бәреп төшереп, Пискунов шәхси рекорд куя.

Аның өчен сугыш 1944 елда тәмамлана. Пискуновларның 42 штурмовик һәм истребительдән торган төркеменә дошманның Никополь янындагы елга күчешен юк итү бурычы куела. Аларны немецларның утыз самолеты һәм зениткаларның тоташ уты каршы ала. Елга күчеше тиз арада, беренче һөҗүмдә үк юк ителә. Василий самолетында 186 тишек барлыкка килә. Очучы аны шассиларен ачмыйча гына җиргә утырта. Авыр яралары белән госпитальдә яткач, очучыны хезмәткә яраксыз дип табалар. Сугыштан соң запастагы капитан Әстерханда яши.

Ә менә Петр Сафронов Бондюгка кайта. Үзе укыган мәктәптә балаларга физкультура укыта. Советлар Союзы Герое исемен ул да, Вилен Бурмистров кебек үк Днепр янында күрсәткән батырлыклары өчен ала.

1943 елның 28 сентябрь иртәсе составында Петр да булган тугыз десантчыдан гыйбарәт төркем дошманның көчле уты астында көймә белән Днепрны кичеп чыга. Яхшы коралланган дошманны тармар итеп, алар елга буендагы кечкенә генә урынга ныгып тоталар. Немецлар һөҗүмен туктаусыз кире кагып, алар позицияләрен көн дәвамында саклап калалар.

Командир үлгәннән соң, яраланган Сафронов аның вазифаларын үзенә ала. Өстәмә көчләр килгәнче, көрәшне дәвам итә. Елганы беренче булып кичкән тугыз кешелек төркемнән сугышчыларның бары бишесе генә исән кала. Ә безнең солдатлар саклаган елга чите кишәрлегендә 150 гә якын немец мәете табыла.

Днепр буенда Бондюгтан тагын бер егет – Василий Белоусов сугыша. Понтон взводы командиры була. 1943 елның 25 сентябрендә аңа тавыш-тынсыз гына сугышчыларны, аларның йөкләрен елганың уңъяк ярына чыгару, плацдармны кулда тоту бурычы куела. Караңгы төшкәч, взвод паромда кузгала. Елга уртасына җитүгә, аларны пулемет утлары яңгыры каршылый. Понтон да зыян күрә. Сугышчыларга тишекне каплау бурычы куела. Ә взвод командиры Белоусов палубага пулеметын урнаштырып, дошманның ут нокталарына атарга керешә. Төн дәвамында атышлар зонасыннан чыгып, понтон взводы югалтуларсыз гына гаскәрне, техниканы, хәрби кирәк-яракларны яр буена алып чыга. 16 тәүлектә Белоусов взводы елга аша 2470 солдат һәм офицерны, 15 орудиене, 1575 ящик хәрби кирәк-яракларны һәм башка хәрби мөлкәтне чыгара. Сугыштан соң Белоусов, Советлар Союзы Герое буларак туган ягына кайта.

Шунысы игътибарга лаек: Бондюг геройларының алтысы да сугышка кадәр җирле ОСОАВИАХИМ түгәрәгендә шөгыльләнә. Түгәрәккә Котдус Габдрахманов җитәкчелек итә. «Мөгаен, инструкторның карашлары егетләргә йогынты ясамый калмагандыр», – ди мәктәп музее хезмәткәре Ирина Тронина.

Музей хезмәткәрләре Габдрахмановның гаиләсе турында да мәгълүмат туплый алган. Котдусның туганнары Л.Я.Карпов исемендәге химия заводында эшләгән. Бабасы сәүдәгәр Ушковта ук хезмәт иткән. Габдрахманов финнар белән сугышта да булган. Бондюгка кече политрук дәрәҗәсе алып кайта. Химия заводында үз инициативасы белән Оборонага, авиациягә һәм химия төзелешенә теләктәшлек җәмгыяте оештыра. Үзе аның рәисе һәм инструкторы була.

Җәмгыятьтә шөгыльләнүчеләр хәрби эш нигезләре белән таныша, коралларны өйрәнә, техника йөртүне үзләштерә, ГТО нормалары тапшыра. Курсантларга телефончы, телеграфчы, радист, моторист, парашютчы, очучы, санитар һөнәрләре бирелә.

Сугыш башлануга, Котдусны беренчеләрдән булып фронтка җибәрәләр. Гвардия өлкән лейтенанты Габдрахманов рота командиры була. Ул берничә тапкыр яралана, әмма кабат фронтка кайта. 1944 елның февралендә Александр Матросов батырлыгын кабатлап һәлак була. Граната ыргытып, пулеметны да сафтан чыгара. Әмма К.Габдрахманов батырлыгы бүләккә тәкъдим ителми. «Аның да батырлыгы герой исемнәре алган укучыларыныкына тиң», – ди Ирина Тронина.

Шулай да якташлары бу бөек шәхеснең хезмәтләрен онытмый. Менделеев шәһәре аллеясында үзе тәрбияләп үстергән алты Советлар Союзы Геройлары белән янәшәгә аның да бюсты куела. Остаз бүген дә шәкертләре белән бергә, алар арасында.

Әгъзам ФӘЙЗРАХМАНОВ.

Әлфия СИТДЫЙКОВА

Чаларган карт дәвер шавын тыңлый...

АГЫП БАРАМ ВАКЫТ ДӘРЬЯСЫНДА

(Сонетлар бәйләме)

1

Үткәннәргә кайтып барышым,
Каен яфрак коя юлыма,
Суык җилләр капты тыныма,
Тойдым исраф вакыт агышын.

Көз куены инде җылытмас,
Кояш сүрән, сукыр ут кебек.
Зәгыйфьләнгән күздән бөркелеп,
Коендырып якты нур чыкмас.

Көзгә ялгыз керү кыен соң,
Күшеккән җан кемгә сыенсын?
Мин төренәм мамык шәлемә.

Җилгә бирдем шәлнең чуклысын,
Йөзгә бәрде уклы сыкысын.
Кемнәр керә кеше хәленә?

2

Балачакның шаян тавышын
Ишетәм мин бары төшемдә.
Яшим саклап алма төшен дә,
Бишек җырын, моңнар агышын.

Юа җыям, җыям кузгалак,
Бәхет-шатлык тәмен юксынып.
Хәтеремә яшим буйсынып.
Күпләр йөргән яннан узгалап.

Таныдымы садә күңелем,
Кем якын һәм кем дус түгелен.
Аердымы күзләр күргәнен?

Ничә тапкыр ятка түгелдем,
Сынмас өчен талдай бөгелдем,
Язмыш кире алгач биргәнен.

3

Яшьлегемне саг(ы)нам көз җиткәч.
Алсу иде аткан таңнарым.
Белә идем тансык яр барын.
Йөрәк тибешемне ишеткәч,

Килде миңа балкып, елмаеп.
Туй күлмәген алып бүләккә,
Һәм керде дә кайнар йөрәккә,
Китте… калдым ялгыз моңаеп.

Тик бер генә тапкыр яраттым.
Авыртканын сынган канатның,
Яраланган кошлар беләдер.

Парлы булыр өчен җан аттым,
Канатымны ничә канаттым.
Ялгызлык ул – бикле келәдер.

4

Гомер елгасының ярында
Кайтуыңны көттем өзелеп.
Еллар үтте коштай тезелеп,
Суга салдым йөрәк зарын да.

Җилләр килеп какты тәрәзгә,
Ачылмады күңел ишегем.
Мин бит бары сиңа иш идем.
Бал корты бал җыя кәрәзгә.

Сабырлыкны җыйдым йөрәккә.
Җан әйләнде күптән көйрәккә.
Син кайтмадың кире әйләнеп.

Сыенганым булды тирәккә,
Тешне кысып түздем кирәктә.
Җил йөрәкләр йөрде бәйләнеп.

5

Сабыр савытларын ямадым.
Яңарттым да һәрбер мизгелне,
Ычкындырмый кулдан тезгенне,
Хәтер җебен кат-кат ялгадым.

Җиңел түгел гомер корабын
Дулкыннардан бару аралап,
Җилкәннәрне куйгач арканлап.
Чәчләремне җилдә тарадым.

Җил канаты алып киткәндер,
Бәлки, сиңа, сиңа илткәндер,
Чәчкәемнең хет бер бөртеген.

Тәрәзәңә синең чирткәндер,
Маңгаеннан сөеп үпкәндер,
Кызлар кебек сирпеп керфеген.

6

Гомер йомгаклары сүтелә.
Вакыт елгасының ярында,
Колак салып еллар зарына,
Пыяладай күңел кителә.

Офык читен һаман күзлимен,
Сагыш тулы еллар арада,
Булган агы, булган кара да.
Күңел белән сине эзлимен.

Юксынганнар таба чарасын,
Йөзеп үтә ярлар арасын,
Соңга калмый, әгәр яратса.

Соңга калсаң, ниләр эшләрсең? –
Терсәгеңне, бәлки, тешләрсең,
Чал башыңа язмыш таш атса.

7

Еллар чоңгылыннан баш калкыт,
Күр әле син көзге урманны!
Ул бит безнең сөю урамы,
Яулык болгый безне ул танып.

Үзгәрмәдек микән әллә без,
Юкса, инде чәчне бәс сарган,
Өн яңгырый үткән гасырдан:
«Гаепле ич бары үзегез».

Адашканбыз еллар чатында,
Онытканбыз сөю хакында,
Кавышырга инде хәзер соң.

Каерылган канат очында
Хыял гына бары очына.
Каткан инде, каткан кавырсын.

8

Мөмкин түгел Вакыт елгасын
Кире бору чишмә башына.
Абынганда чуерташына,
Убылганын җирнең тоясың.

Сарыф иткән гомер ком кебек,
Җитез булгач очкан коштан да,
Агып бетә икән учтан да.
Акыл булсын башта иң элек.

Күпләр аны соңлап төшенә,
Биреләдер сирәк кешегә,
Яшь чакта ук аңлау сәләте.

Кем бәхетне күрә төшендә,
Җавап тота гөнаһ өчен дә,
Суккач соңгы минут-сәгате.

9

Һәркем туа җирдә яшәргә
Күңелләргә якты эз салып.
Калмас өчен сүнеп, югалып,
Яшен булып ялтлап яшьнәргә.

Биеклеккә омтыл, сыгылма,
Көн тумый ул җиргә иртәсез,
Барыр юлың булсын киртәсез.
Абынсаң да, нык бул, егылма!

Егылсаң да, шундук торып бас!
Учак як та, аннан казан ас.
Соклансыннар күреп үзеңне.

Бәхет баскан чаклар була аз.
Көен җуйган чакта моңлы саз,
Капламасын болыт йөзеңне!

10

Көч тап һәрчак басып калырлык,
Ваз кичмә бер әйткән сүзеңнән,
Ул сүз синең җаннан өзелгән.
Үз-үзеңне җиңү – батырлык.

Вакыт куяр беркөн бәясен
Хаклаучыга сөю кадерен,
Бер күрсәтер көтү әҗерен.
Тәкъдир тартып карар җәясен.

Ис-акылы китәр тормышның,
Ныклыгына җаны корычның.
Төзәткәнгә яшьлек ялгышын.

Бәхет кошы канат кагар да,
Хис кабыныр тагын арада,
Диңгез юар барлык сагышын.

11

Ни күрсәтер безгә киләчәк?
Таң сызылып, кояш калкумы,
Йолдыз булып күктә балкумы,
Әче әрем, әллә гөлчәчәк?

Барысы да язмыш кулында.
Озын булсын гомер агышы.
Ак юл теләп, аккош тавышы
Озата барсын тормыш юлында.

Ардым диеп туктап калмасаң,
Маяк булып балкып яналсаң,
Бүләген дә беркөн бирәчәк.

Күзең ачып көнгә багалсаң,
Йолдызларга карап юл алсаң,
Матур, якты булыр күрәчәк.

12

Вакыт дәрьясында аккошлар,
Канатлары коча дулкынны.
Канат җәйгән күңел мең кыллы,
Канатлыга көчле алкышлар.

Җаксын дулкын вакыт ярына,
Йөрәк аша үтсен кагышы,
Таратсын ул барлык сагышны.
Ялгызлыктан җаннар арынса,

Балкыр күктә бәхет кояшы,
Ярда ятып калыр ком ташы,
Һәм юылыр еллар юшкыны.

Алда биек таулар кыясы,
Исемнәрне килә уясы,
Кагыла җанга горур кош тыны.

МОҢНАР ЧЫҢЛЫЙ ҖАНДА

1

Кара төс тә кайчак җанга якын,
Ул да бизәк-чигеш аклыкка.
Тормыш та бит түгел гел саф алтын,
Ак-карадан тора хаклыкта.

Табигатьтә төсләр алышына,
Яз артыннан килә ямьле җәй.
Торна моңы! Гомер агышына
Ак карлардан кышка җәймә җәй!

Назлап сыйпый кулым балаларның
Сумаладай кара чәчләрен.
Җилләр сөртеп ала болытларның
Түгелергә торган яшьләрен.

Искәртә лә чал чәчләрнең төсе, –
Көтә алда гомеремнең көзе.

2

Моңнар чыңлый җанда, моңнар
чыңлый...
Гомер агып бара тын гына.
Күпме сагыш минут тынында.
Чаларган карт дәвер шавын тыңлый.

Яшьлек белән картлык очрашкан мәл,
Дулкын белән дулкын кушылган,
Югалттым, дип, язган һушыннан.
Узган гомеркәйләр бигрәк җәл.

Их, кайтасы иде тик бер көнгә...
Шундый уйлар килеп башына,
Утырган да тауның ташына,
Кул болгый казлар очкан төркемгә.

Сагыш тулы гомер агышлары,
Шулай барлый кеше язмышларны.

3

Табышлар да булган, ялгышлар да,
Гомер аты алга чапканда.
Кадер булганмы соң тапканда,
Төрелгәнме җаны каргышларга?!

Хаталардан хали булган кемнәр?
Бер тырмага баса тик җүләр.
Ялгышканнар әҗер-хак түләр,
Яктырганда чем караңгы төннәр.

Кояш, әгәр кызганмаса нурын,
Җылы табар салкын көздә дә.
Сары сагыш үзәк өзсә дә,
Шатлык белән сузар соңгы җырын.

Зая яшәлмәгән дияр гомер,
Әҗәл күзләренә карап көлер.

СТАЛИННЫҢ

(Дәвамы. Башы 16 нчы санда).

Октябрь аенда фронт штабы бик җентекләп Ростов оборона операциясен әзерләү эшләренә керешә, шуңа ярашлы рәвештә, 12–13 октябрь көннәрендә гаскәрләрне яңадан төркемнәргә аеру тәгәлләнә. Шунысы мөһим: ноябрь урталарында дошман көчләре Ростов каласына якынайган бер мәлдә, Көньяк фронт штабында, Антонов җитәкчелегендә совет гаскәрләренең контрудары планлаштырыла. Оператив идарә остасының бу юнәлештәге эшчәнлеге С.К.Тимошенко һәм Генштаб тарафыннан югары бәяләнә һәм бу 17 ноябрьдә Ростов һөҗүм операциясен башлауга юл ача. Әүвәл фронт карамагындагы 9 нчы, 18 нче һәм 37 нче армияләр Клейстның 1 нче танк армиясе тылына һөҗүм ясый. Бераздан, көньяк юнәлештән 56 нчы армия көчләре дә яуга керә. Нәтиҗәдә, 21 ноябрьдә дошман тарафыннан басып алынган Ростов каласы бер атна үтүгә азат ителә. 2 декабрьгә совет гаскәрләре алман частьларын Миус елгасының икенче ярына бәреп чыгара. Әлеге Кызыл Армиянең иң беренче уңышлы операциясе турында, Алексей Иннокентьевич тарафыннан язылган мәкалә, ниндидер сәбәпләр белән, басылмыйча кала. Гәрчә, ирешкән уңышлары өчен ул үзе 13 декабрьдә Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнә, ә тагын ике атнадан иңнәренә генерал-лейтенант погоннары тага.

1942 ел башында Антонов үз штабы белән Барвенково-Лозовой операциясен әзерли. Совет гаскәрләренең Харьков каласыннан көньяк-көнчыгышта башланган һәм 18–31 гыйнвар көннәрен эченә алган һөҗүмнәре шулай ук уңышлы тәмамлана. Гомумән алганда, Кызыл Армиянең 1941 елның ахырыннан алып 1942 елның беренче айларына кадәр оештырылган һәм гаять дәрәҗәдә нәтиҗәле, уңышлы тәмамланган һөҗүмнәре бөтен халык күңелендә, шул исәптән ил җитәкчелегендә сугышның тиздән тәмамланасына өмет уята. Аеруча Мәскәү янында дошманның җиңелүгә дучар булуы Иосиф Сталинны яңа уңышларга илһамландыра һәм ул барлык юнәлешләрдә һөҗүмгә күчәргә карар кыла. 1942 елның 1 маенда Югары Башкомандующий Сталин Боерыгындагы: «Бөтен Кызыл Армиягә 1942 елда алман-фашист гаскәрләрен тулысынча тар-мар итү һәм совет җирләрен гитлерчы кабахәтләрдән азат итү бурычы куям», – дигән юллар шуңа мисал. Харьков тирәсендә башланган сугыш хәрәкәтләре нәкъ менә шул һөҗүмнәрнең берсе була да инде. Аны гамәлгә куюның төп максаты – дошманның «Көньяк» төркеменә керүче армияләрен бүлгәләү һәм аларны Азов диңгезенә кысрыклап, тулысынча тар-мар итү. 12 майда Брянск, Көньяк-Көнбатыш һәм Көньяк фронт гаскәрләре катнашында Харьков стратегик һөҗүм операциясе башлана. Ул орыш «Харьков өчен икенче сугыш» һәм «Харьков катастрофасы» исемнәре белән дә хәрби тарих битләрендә теркәлеп калган. Фәкать Брянск фронты составында биш армия, ике танк корпусы, тугыз аерым танк бригадасы, Көньяк-Көнбатыш фронт составында дүрт армия, биш танк корпусы, унөч аерым танк бригадасы тупланууын ассызыклау мөһим. Май аенда башланып киткән сугышларда Харьков юнәлешендәге өч фронтта барлыгы 640 мең яугир һәм 1200 танк катнаша. Вермахт ягыннан генерал-фельдмаршал Мориц фон Бок җитәкчелегендә генерал-полковник Эвальд фон Клейстның 1 нче танк армиясе белән танк гаскәрләре генералы Фридрих Паулюсның – 6 нчы һәм генерал-полковник Герман Готның 17 нче армияләре каршы тора.

Баштагы мәлләрдә бары да яхшы бара. Әмма 17 май көнне Клейстның 1 нче танк армиясе көтмәгәндә зур тизлектә удар ясый һәм безнең һөҗүм итүче гаскәрләрнең тылына чыга. Беренче көнне үк аның танк армадасы Көньяк фронт составындагы 9 нчы армиянең оборонасын өзә һәм совет гаскәрләренең чигенү юлын каплый. Сталин, яңа гына Генштаб башлыгы вазифасына керешкән Василевскийның, безнең гаскәрләрнең һөҗүмнәрен туктатуны сораган ике үтенечен кире кага. Нәтиҗәдә 23 майга 6 нчы, 9 нчы һәм 57 нче армияләрнең күпчелек частьлары Мерефа – Лозовая – Балаклея өчпочмагында камалышта кала..

Харьков янындагы катастрофа Көньяк һәм Көньяк-Көнбатыш фронтларның бөтен оборона полосасын тәмам көчсезләндерә. Бу исә алманнарга, үзләренең алдан ук Кавказга һәм Иделгә юнәлтелгән стратегик һөҗүмнәрен уңышлы үстерүгә юл ача. Нәтиҗәдә, 28 июньдә Герман Готның 4 нче танк армиясе Курск белән Харьков арасындагы фронтны өзә һәм ташкын булып Донга ташлана. 7 июльдә алманнар Воронеж каласының уң ярдагы өлешенә керә, 23 июльдә кабаттан Ростов каласын басып ала. Моннан соң Кавказга юл ачыла. Бу сугышлар вакытында күп югалтуларга дучар булган Көньяк фронтның киләчәк язмышы турында фикер аерымлыклары очрый. Бер авторлар фронтның июль аенда таратылуы турында язса, икенчеләре исә, Кавказ өчен сугышлар башлангач, 28 июльдә Төньяк Кавказ һәм Көньяк фронтларның берләштерелүен раслый. Хәер, биредә әллә ни хата юк. Чынында, 1942 елның 28 июлендә Югары Башкомандование Ставкасы карары белән, таратылган Көньяк фронт гаскәрләре берләшмәләрен һәм частьларын, әле 1942 елның май аенда ук оеша башлаган һәм командующий вазифасына маршал Семен Буденный билгеләнгән Төньяк Кавказ фронтына кушалар. 29 июльдән фронтның Хәрби совет әгъзасы – Дәүләт оборона комитеты әгъзасы Лазарь Моисеевич Каганович, штаб башлыгы – генерал-лейтенант А.Антонов. Бер җәһәттән, Алексей Иннокентьевичның 1941 елның 30 августыннан 1942 елның 28 июленә чаклы, ил язмышы өчен гаять катлаулы чорда, Көньяк фронт штабы башлыгы булып торуын ассызыклау урынлы.

Төньяк Кавказ фронты гаскәрләре белән идарә итүне җиңеләйтү максатыннан, фронт көчләре ике төркемгә бүленә: Дон төркеме командующие – генерал-лейтенант Родион Яковлевич Малиновский, ә Диңгез буе төркеменеке – генерал-полковник Яков Тимофеевич Черевиченко. 4 сентябрь көнне Югары Башкомандование Ставкасы директивасы белән фронт Кавказ арты фронты гаскәрләре составындагы Кара диңгез төркеме итеп үзгәртелә. Аның командующие вазифасына генерал-полковник Я.Т.Черевиченко раслана, штаб башлыгы итеп генерал-лейтенант А.И.Антонов билгеләнә. Аңарчы, Кавказ арты фронты командующие армия генералы Тюленев үзенең штаб башлыгын фәкать яхшы яктан гына бәяли. Шуңа да, ноябрь аенда Антоновны Кавказ арты фронты штабы башлыгы итеп куюлары көтелмәгән хәл түгел.

Кавказ өчен сугышларның совет ягы өчен уңышлы тәмамлануы Төньяк Кавказны дошманнан азат итүгә уңай шартлар тудыра. Фронт штабы озакламый башланырга торган һөҗүмнәрне планлаштыру белән мәшгуль. Шул җитди мәшәкатьләрдән тыш, генерал Антонов «милли» дивизияләр оештыру белән ныклап шөгыльләнергә дә вакыт таба. Кыска гына вакыт эчендә шундый 19 дивизия һәм 211 юк итү батальоны оешуда аның да өлеше зур. Гел яу кырында, кырыс шартларда тәмам оператив идарә остасына әйләнгән генералның уңышлары Югары Башкомандование, шул исәптән Генштаб башлыгы генерал-полковник А.М.Василевский игътибарыннан да читтә калмый. Декабрь башында Александр Михайлович генерал-лейтенант Антоновка мөрәҗәгать итә һәм аны үзенең урынбасары һәм Оператив идарә башлыгы вазифаларына кую тәкъдиме белән чыга. Әлбәттә, кандидатурасының Сталин тарафыннан хупланган булуын искәртергә дә онытмый. Үзенең мөмкинлекләренә ышанган Антонов күнә һәм 11 декабрьдә Мәскәүгә кайтып төшүгә үк, Генштабның Оператив идарәсе башлыгы итеп билгеләнә.

Мәгълүм булганча, 1942 елның 24 апрелендә, ул чакта генерал-лейтенант чинындагы Александр Василевский Генштаб башлыгы вазифасын башкаручы итеп билгеләнә. Түгәл ике айдан шул вазифага раслана, әмма Оператив идарәгә, аны алыштырырдай җитәкче табу зур проблемага әйләнә. Чөнки Генераль штаб башлыгы үзе бик еш фронтларга чыгып китәргә мәҗбүр, ә яңа билгеләнгән Оператив идарә башлыгы тиз генә үз вазифасының нечкәлекләренә төшенеп җитә алмый кала һәм аңа тиешенчә эшкә керешүгә чиктән тыш авырлаша. Иң аянычы, ул Ставкага барып доклад ясаганда да үзен ышанычлы тота алмыйча тилмерә, бу исә бөтен эшкә аяк чала. Шунлыктан, Александр Михайлович Оператив идарә башлыгына лаеклы кандидатураны ярты ел дәвамында эзли. Шул җәһәттән, генерал Штеменко истәлекләреннән өземтә: «Василевскийның китүе Генераль штабның әйдәп баручы идарәсе эшчәнлегенә ифрат зур зыян салды. Нәтиҗәдә башлыклар алмашыну чоры башланды. Ярты ел чамасы вакыт эчендә берничә башлык алмашынды. Бу вазифаны А.И.Бодин (дөресе – генерал-лейтенант Павел Иванович Бодин. 1942 елның март – август айларында Генштаб башлыгының икенче урынбасары һәм май аеннан, бер үк вакытта – Оператив идарә башлыгы вазифасында. Шул елның августыннан – Кавказ арты фронтының штаб башлыгы), ике тапкыр А.Н.Боголюбов, В.Д.Иванов башкарды, ә алар арасында вакытлыча П.Г.Тихомиров, П.П.Вечный, Ш.Н.Гыйниятуллин эшләп алды» (1 нче китап, 106 бит).

Гаять җаваплы вазифа. Оператив идарә башлыгы көн саен Югары Башкомандование Ставкасында оператив докладлар ясарга тиеш. Тик, ни сәбәптәндер, Антоновны баштагы мәлләрдә Ставкага чакырмыйлар, ул Сталин янында да бер генә мәртәбә була. Мондый шартларда Антоновның кабат фронтка китәргә ашкынып торуы табигый. Василевский чираттагы бер доклады вакытында янә, Антоновның Генштаб һәм Ставка өчен бик кирәкле хезмәткәр булуын, аңа шушы ике органны оператив яктан мәгълүматлар белән тәэмин итеп тору мөмкинлеге бирүнең мөһимлеген дәлилли. Аңа каршы Сталин: «Сезнең характеристика буенча, Антонов безнең канцелярия эшләренә караганда, фронтта күпкә файдалырак булачак», – дип белдерә.

1943 елның гыйнвар башларында генерал-лейтенант А.Антоновны Ставка вәкиле сыйфатында Брянск фронтының 18 нче аерым укчы корпусына җибәрәләр. Ул биредә фронт берләшмәләре тарафыннан үткәрелгән Острогожск-Россошь һәм Воронеж-Касторное операцияләренә юнәлеш бирә. 10 гыйнвардан 28 мартка чаклы Воронеж, Брянск һәм Үзәк фронтларда булып, Мәскәүгә әйләнеп кайткан Антоновның турыдан-туры яу кырындагы эшчәнлеге һәм Генштаб, һәм Ста-

лин тарафыннан югары бәяләнә. Чөнки Кызыл Армиянең әлеге фронтлар көчләре белән үткәргән кышкы һөҗүмнәре уңышлы тәмамлана. Ставкада ясаган беренче докладыннан соң ук, Антонов көненә берничә тапкыр Сталин янында була башлый. Алгарак китеп өстисе килә: 1943–1945 елларда ул фәкать Сталинның Кремльдәге кабинетында, ким дигәндә, 238 тапкыр булган.

ХӘРБИ КИҢӘШЧЕСЕ

Бу – СССР Кораллы көчләренең җитәкчелек составын тәшкил итүчеләрнең һәркайсы белән чагыштырып караганда да күбрәк. Сугыш вакытында барлык фронт командующийларын Иосиф Виссарионовичның ничә мәртәбә кабул итүен бергә кушып исәпләсәң дә – әлеге санга җитәргә бик ерак.

Үз идарәсенең эшчәнлеген яхшырту һәм камилләштерү өчен генерал-лейтенант А.И.Антонов зур тырышлык куя. Аның боерыгы белән Баш оештыру һәм сугыш тәҗрибәсен файдалану идарәләре оеша. Генштабның Оператив идарәсе карамагында Офицерлар корпусын оештыру да аның эшчәнлегенә турыдан-туры бәйле. Әлбәттә, армиядә аңарчы тыелган «офицер» сүзе белән аталучы корпусның тарихы Ватан сугышы башланган елга ук барып тоташа. Сугышның беренче айларында Кызыл Армия зур җиңелүләргә дучар була. Фаҗигале һәм аяныч хәлләрнең төп сәбәбе бик тиз ачыклана: төп хата – Генштабны Кораллы көчләрнең «баш мие» буларак санамауда һәм санламауда. Нәтиҗәдә туган объектив һәм субъектив авырлыкларны чишү юлларының берсе буларак, фронт һәм армия командующийларының, корпус һәм дивизия командирларының эшчәнлеген контрольдә тоту, аларга даими ярдәм итүне оештыру көн кадагына баса. Нәкъ менә шул проблемаларны чишү максатыннан чыгып, 1941 елның июль аенда Генераль штабның Офицерлар төркеме оеша. 1943 елның июненнән ул Генштабның Офицерлар корпусы дип атала башлый. РФ Кораллы көчләре Генштабы Хәрби академиясенең хәрби-тикшеренү институтында (хәрби тарих) 43 нче бүлек башлыгы булып хезмәт куючы өлкән гыйльми хезмәткәр, медицина фәннәре докторы Эдуард Львович Коршунов үзенең «Кызыл Армиянең Генераль штаб офицерлары Курск сугышында 6 нчы гвардия армиясенең хәрби хәрәкәтләре турында» дигән мәкаләсендә расланганча, «1943 елның июнь ахырларында, Б.М. Шапошниковның тәкъдиме белән Генераль штабның Офицерлар төркеме Офицерлар корпусы итеп үзгәртелә һәм Генераль штаб вәкилләре сыйфатында Оператив идарә штатына күчә» (280-281 б.).

Э.Коршунов бу турыдагы мәгълүматны генерал С.М.Штеменконың 1981 елда басылган истәлекләренең 1 нче китабыннан (198 һәм 199 битләр) алганлыгына сылтама ясый. Әлбәттә, 1942 елның маенда, авыруы сәбәпле Генштаб башлыгы вазифасыннан киткән Борис Михайловичның андый тәкъдиме, беренче карашка, сәеррәк тоелырга мөмкин. Гәрчә монда сәерсенер урын юк: беренчедән, ул карарга килгән чакта Офицерлар төркеме ГКО Ставкасы карамагына күчкән була, икенчедән, 1941 ел июленнән 1945 ел февраленә чаклы маршал Шапошников – Ставка әгъзасы. Бер үк вакытта ул 1941 ел июненнән 1945 ел мартына кадәр, ягъни вафатына чаклы, Генштабның К.Е.Ворошилов исемендәге Югары хәрби академиясе башлыгы булып та тора.

А.Антонов 1942 елның 11 декабреннән 1943 елның 20 маена чаклы Оператив идарә башлыгы вазифасында хәрби бурычын намус белән үти. Шул айда Оператив идарә башлыгы вазифасына билгеләнгән Сергей Штеменко истәлекләреннән янә бер өземтә: «Әмма А.М.Василевкий булмаган чакларда (ул бик еш фронтларга китә) – Алексей Иннокентьевичның иңнәренә Генераль штаб башлыгы вазифаларын башкару йөге дә ята. Сугыш чорында, бер үк вакытта ике авыр вазифа башкару хәтта Антонов өчен дә бик авырга төшә. Мондый вәзгыятьне Ставкада бик яхшы аңлыйлар һәм аны Опертив идарә башлыгы вазифасыннан алырга килешенә. Оператив идарә башлыгы вазифасын биш ай башкарганнан соң А.И.Антоновны Генштаб башлыгының беренче урынбасары итеп куялар. Бу аңа бөтен көчен салып, бер участокта эшләү өчен зур мөмкинлекләр ача. Нигездә, Генштаб белән ул җитәкчелек итә» (172 бит).

Генштаб башлыгы урынбасары һәм Оператив идарә башлыгы булып эшләгәндә генерал Антонов стратегик планнар төзү белән шөгыльләнә. Кызыл Армия тарафыннан 1943 елның язгы-җәйге кампаниясеннән башлап сугыш тәмамланганчы тормышка ашырылган барлык мөһим кампанияләрне һәм стратегик операцияләрне әзерләүдә ул турыдан-туры үзе катнаша. Аларның беренчесе Курск операциясе булуын искәртү аеруча әһәмиятле. Шул нисбәттән, И.И.Гагловның генерал Антонов турында өстәмәләр белән язган чираттагы «Армия генералы А.И.Антонов» дигән хезмәтеннән бер өземтә: «Курск дугасындагы орышны әзерләүнең иң кызган бер мәлендә, йөкләнгән эшләренең чиктән тыш күбәеп китүен исәпкә алып, Антоновны Оператив идарә башлыгы вазифаларыннан азат итәләр, һәм ул бөтен эшчәнлеген Генштаб җитәкчесе вазифасына юнәлдерә. Аның урынына Штеменко билгеләнә» (159 бит).

Гомумән алганда, 1943 елның җәендә Офицерлар корпусы Оператив идарә карамагына күчкәч, аның эше тагын да камилләшә төшә. Бу аеруча Курск дугасындагы орышта ачык чагылыш таба. Янәдән Э.Коршунов хезмәтенә мөрәҗәгать итик: «Моннан соң, Корпус төркеме составындагы офицерлар, Оператив идарә башлыгы тарафыннан алдан расланган планга ярашлы рәвештә фронтларның кыр идарәләренә килеп, турыдан-туры берләшмәләрдә эшли башлый... Курск дугасында сугыш башланыр алдыннан һәм ул орышлар вакытында Генераль штаб офицерларының эше түбәндәгечә оештырылган була: Кызыл Армиянең Генераль штабы башлыгы – Советлар Союзы Маршалы Александр Михайлович Василевский, Оператив идарә башлыгы – генерал-лейтенант Алексей Иннокентьевич Антонов (1943 елның 4 апреленнән – генерал-полковник), Юнәлеш башлыгы (Воронеж фронты) – генерал-майор Яков Афанасьевич Куцев. Воронеж фронтында Генштабның барлыгы 23 офицеры, шул исәптән төркем җитәкчесе полковник Митрофан Никитович Костин эшли» (281 бит).

Хәрби чыганакларда Алексей Иннокентьевичның фәкать август аенда гына да, ике мәртәбә алгы сызыкта булуы теркәлеп калган. Сүз уңаеннан, Антоновның, 1943 елның 27 августында, 46 яшендә, армия генералы чинына үрләтелүен дә искәртеп үтү мөһим. 1943 елның ноябрендә Генераль штабта өченче кышкы хәрби кампаниягә әзерлек чаралары күрелә башлый. Бу юлы һөҗүм операцияләрен бер-ике төп юнәлештә әзерләү белән чикләнмәскә, ә Балтыйк белән Кара диңгезләр арасындагы киң фронтта сугыш максаты куела. Планның детальләре Генштабта Жуков, Антонов һәм Василевский тарафыннан эшләнеп бетә. Совет гаскәрләренең 1943 елның 24 декабрендә башланып киткән һөҗүмнәренә биш фронт көчләре җәлеп ителә. Днепр-Карпат һөҗүм операциясе башланып 20 көн үтүгә, ягъни 1944 елның 14 гыйнварында, Ленинград-Новгород операциясендә катнашучы көчләр хәрәкәткә килә. Кампания 1944 елның май аенда уңышлы тәмамлана, командование куйган бурычлар барысы да тәгәл үтәлә, иң мөһиме безнең гаскәрләр совет-румын чигенә чыга. Шулай итеп, Европаны гитлерчылардан азат итү этабы башлана. Генштабта, СССР территориясен тулысынча дошманнан азат итүне күз уңында тотып эшләнүче җәйге кампаниягә әзерлек чаралары шулай ук Алексей Иннокентьевич җитәкчелегендә тормышка ашырыла. Апрель ахырларында Антонов үзләре тарафыннан әзерләнгән кампаниянең асылын Сталинга ирештерә, ә 1 май көнне аны раслау турындагы боерыкка имза төшә. Белоруссиягә төбәлгән төп удар юнәлешен Генштаб башлыгының беренче урынбасары шәхсән үзе эшли. Шунысы мөһим: Антонов анда «Багратион» Белоруссия һөҗүм операциясе исеме белән тарихка язылачак җәйге кампания вакытындагы хәлиткеч һөҗүмнәрнең нигезләрен сала. Әлеге гаять мөһим операциянең тулы планын эшләү берничә атна дәвам итә, аны әзерләп бетергәдә Антоновтан тыш Жуков, Василевский һәм Штеменко белән аның урынбасары катнаша. Үзара язышулар, телефоннан яисә телеграфтан сөйләшүләр катгый тыела. Ниһаять, 20 майда Антонов планга кул куя.

Аннары, 22 һәм 23 май көннәрендә Ставкада, Жуков, Василевский, Баграмян, Рокоссовский һәм Антонов җитәкчелегендәге Генштаб вәкилләре катнашында план җентекле тикшерү уза. Үтә яшерен шартларда әзерләнгән операциягә нигезләнеп, 24 июньнән 29 августка чаклы дәвам иткән һөҗүмнәр дошманның «Үзәк» армияләр төркемен тулысынча тар-мар итү белән тәмамлана.

1945 елның 18 февралендә 3 нче Белоруссия фронты командующие ике тапкыр Советлар Союзы Герое, армия генералы И.В.Черняховскийның бакыйлыкка күчүе Генштаб эшчәнлегендә җитди үзгәрешләр тууга китерә. Менә-менә, илнең иң яшь Советлар Союзы Маршалы дәрәҗәсенә ирешергә торган мәрхүм Иван Даниловичның урынын Василевский били. Шуңа да карамастан, кайбер авторлар Антоновның Генштаб башлыгы вазифасына 4 февральдән керешүе турында яза. Билгеле, мондый аңлашылмаучанлыкның игътибарсыз калдыру бик үк дөрес булмас. Әлегәчә, фронт командующие Иван Черняховскийның гомерен өзгән бердәнбер снарядның кай тарафтан атылган булуы тәгәл генә билгеле түгел. Ул чакта 3 нче армия командующие вазифасындагы генерал-полковник А.В.Горбатов (1955 елдан – армия генералы) раславына караганда, «Көнчыгыш Пруссиянең әле 17 февраль көнендә үк дошманнан азат ителгән Мельзы каласы читендә (хәзерге Польшаның Пененжо каласы) «виллис» автомобилендә баручы Черняховскийның күкрәгенә снаряд ярчыгы тия». Александр Васильевич ату тавышының дошман тарафыннан ишетелүе һәм фронт командующиенең шул ук көнне, ягъни 18 февральдә медсанбатта җан бирүе турында яза. Димәк, армия генералы А.Антоновның 4 февральдә Генераль штаб башлыгы вазифасына билгеләнүе дөреслеккә туры килеп бетми.

(Дәвамы киләсе санда).

Рәис ЗАРИПОВ.

Атнаның сәяси мизгелләре

ҖЫЕЛЫШЫП АҢЛАШУ

Атна сәяси вакыйгаларга бай булды. Аларның күбесе Украинадагы вөзгыять белән бәйле. Шуларның берсе – дөньяның 40 тан артык иленнән саклану министрларының, Пентагон башлыгы Ллойд Остин кул астында, АКШның Алманиядә урнашкан Рамштайн авиабазасында җыелып, халыкара коалиция төзүе. НАТО илләреннән тыш, анда Австралия, Израиль, Көньяк Корея, Финляндия, Швеция, Япония һ.б. керә икән. Коалиция Украинага хәрби ярдәмне киңәйтү чараларын күрә. Инде сүз авыр сугыш кораллары белән ярдәм итү турында да бара. Ярдәм өзлексез булачак. Пентагон башлыгы әйтүенчә, АКШ хәрби өлкәдә Россиянең мөмкинлекләрен киметү һәм һөҗүм потенциалын түбәнәйтүгә ирешәчәк. Ә Алмания саклану министры Кристина Ламбрехт сүзләренә караганда, Украина өчен иң яхшы иминлек гарантиясе – аның яхшы өйрәтелгән һәм яхшы тәэмин ителгән кораллы көчләре.

Җыелышып аңлашу узган атнада Россиядә дә булды. Россия президенты В.Путин Санкт-Петербургта Закон чыгаручылар Шурасы әгъзалары белән очрашты. Илбашының андагы чыгышына җавап Вашингтоннан озак көттермәде. АКШ президенты Джо Байден, беркем дә атом-төш коралы белән янарга тиеш түгел, дип белдерде. Украинага ярдәм өчен Байден конгресстан тагын 33 миллиард доллар сораган.

Ак йорт юристлары исә Россиянең «туңдырылган» дәүләт активларын (300 миллиард доллардан артык) Украинага ярдәм өчен конфискацияләү мөмкинлеген дә өйрәнә икән.

Ә С.Лавров Россия-Украина сөйләшүләренең тукталып калуында Киевне гаепли. Чөнки ул Украина иминлеге илнең бөтен территориясендә гарантияләнүен таләп итә икән. Мәскәү гарантиянең Кырымга һәм Донбасска да җәелүе белән килешми, чөнки аларның бәйсезлеген инде ул таныган. Ә Украина президенты В.Зеленский, Россия кул астындагы төбәкләрдә референдум үткәрелгән очракта, Киевнең сөйләшүләрдән чыгу мөмкинлеге турында да әйтә. Менә шундый шартларда В.Путин һәм В.Зеленский янә бер җыелышып аңлашу – «Зур егермелек»нең ноябрьдә Индонезиядә узачак саммитына чакыру алганнар.

Фоат УРАЗАЙ.

1945 елгы хат

Әхәт ГАФФАР

«Аңыма килгәч, палатада икәнемә төшендем. Ак түшәмне күрдем дә, әһә, ятам икән, мәйтәм. Яткач, әлегә тере икән бит инде. Әйе, кабердә дә басып тормыйлар, яталардыр, тик аның түшәме ак булмас, мәйтәм.

Шулай итеп, ак түшәм астында ятам икән. Түшәмнең аклыгын күрү күз исән дигән сүз ич инде, әйеме? Һичьюгы, берсе. Хәзер, мәйтәм, тикшерәбез аны. Тикшерүем шул: берсен чытырдатып йомам – түшәм юкка чыкмаса, дөнья яктысы минеке. Сул як кайда да, уң як кайда – әле аңышмаган. Хәер, дөнья яктысына карарга кайсы күз дә ярый, ә солдат өчен уңы кирәгрәк... Мушкадан фашист башын күрергә миңа уң күз кирәк. Ул бит инде күнегелгән: аткан саен сул күз йомыла. Бу юлы да күз элеккечә йомылгандыр. Бүтәнчә күнегелмәгән: разведкада аягүрә генә черем итәсеңме, окопта йокымсырыйсыңмы – фашист килгәне сизелсә, башта уң бәбәк чәчрәп ачыла... Карыйм – түшәм яңа кар кебек ап-ак. Челт бүтән бәбәкне – ак!.. Шул рәвешчә бер кавым челт-мелт күз уйнатып яттым. Унсигез ел яшәп, кызларга да шултиклем күз кысканым юк иде. Кызлар дигәннән, фронтта ул нәрсәгә вакыты да, җае да тимәде, ә аңарчы... Мин сугышка үз теләгем белән унҗидедә чыгып киттем, син озата да белмәдең. Хәер, унҗидедән алынгач, буй-сын кызларга каш сикертмәслек булмагандыр анысы, ә берсеннән дә керфек кагулар тәтемәде, гөнаһына кермим.

Ярый, түшәм ак, күзләр, үзең беләсең, кара инде минем, кызларга күз кыскалау качмас. Үземә керфек кага-кага кайберәүләрнең күз нурлары уңып бетәр әле. Кызларны әйтәм. Сабырлык кирәк. Безнең эти «ир башы үлемнән качарга җай таба, мәгәр Ходай аңа хатын-кыздан котылып калырлык мәдәт бирмәгән» дия торган иде... Әйе, күз исән икән, кызлардан керфек кактырырбыз! Кызлар дигәч тә... Җиңеп кайткач, сайланып йөрер бу дип уйлама тагын...

Ә менә куллар ни хәлдә икән? Кара керфекләр кактырып та, зифа билләр кочарлык әмәлең булмаса, нишләрсең? Кызлар биле кочканчы, сугышны очлап кайтасы бар бит әле. Монда кулсыз хәлләр мөшкел. Сугышта автомат тәтесенә басарга бер генә бармаклы калганы да җитә. Штыковойда мин ул фашистның бугазын кулсыз-нисез дә чәйнәп өзәргә күп сорамыйм.

Башны күтәреп карарга чамаласам, кая ул: муен белән гәүдәне бер итеп урап куйганнар, селкетерлек тә түгел. Туң кәбестә күчәне кук шыкырдатып катырганнар.

Күзләрне кыскалап, кайбер нәрсәне ачыкладым, хәзер иң әүвәл уң кулны барларга кирәк. Дөньяда ашар ризыгың бетмәсә (баш очында ак түшәм торгач, минем моңа законный өметем бар), әйе, дөньяда ашар ризыгың бетмәсә, котелок белән авыз арасында анысы сул кул да адашмас, ачтан үлмәм, шөт. Шуңа күрә бу мәлдә уңын барлау хәерлерәк, ансыз үлем белән бер. Берзаман уң кулны граната томыргандай айкап торып җибәрүем булды – берәүнең чыр итеп кычкыруы бөтен палатаны басып китте, мин сиңайтим!.. Күзне кыегайтып карасам, ак халат кигән шәфкать туташының билдән түбән йомры бер җиренә шапылдатып сукканмын бит, гөнаһ шомлыгы! Оятымнан нишләргә белмичә күзләрне түшәмгә терәдем дә каттым. Шәфкать туташы: «Егет икәнсең, Сәләхетдинов! Ниһаять, аңга килдең, ут борчасы!» – дип, битемнән үбәргә иелде, шунда сул кулым да үз урынында икәнен белеп алдым. Куллар ул, малай, итек балтырыннан кашык чыгарып, итле ботка ашар өчен генә түгел, бүтән эшкә дә ярый икән ич әле.

Күз күрә, колак ишетә; куллар, ялгыш кына булса да, кайбер йомры җирләрнең хәл-әхвәлен белеште, хәзер чират аякка җитте. Миңа, көтүче Җиһангир абыйның өч тракторчы малае шикелле, танк иярләргә туры килмәде. Мин – пехота. Ә пехотаны, үзең беләсең, аяк йөртә. Аяк шәрифләренә ул-бу була калса, миннән ниткән пехота? Пехотаның бөтен дәрәҗәсе аякта. Ә менә аякның уңы-сулы юк. Тикмәгә генә ике чабата бер кием дими торганнардыр инде аны. Аякның аның икесе дә кирәк. Каз гына ул сыңар аякта тора һәм чүгә белә.

Шунда яныма шәфкать туташы борылып килгәнен тоеп алдым. Янәшәмә килеп басты – тулган айдай елмая! Хәлем шулхәтле дә мөшкел микәнни соң? Шуны сиздермәскә тырышып, шултиклем елмая инде бу дип йөрәк әрни. Метр да туксан ике сантиметрлы буем белән стройда барган чагымда кайда иде соң синең бу елмаюларың дип, аяк тибеп, үтерепләр кычкырасы килә бит, каһәр суккыры! Ни тавыш чыкмый, ни аяк типми. Ә бу исә, артка яшергән кулларын сузып, минем аяк очына ике чүәк куймасынмы, чукынчык! Менә шунда ак түшәм эреп күздән югалды. Кулларның егәре китте, аяк оеды.

Мышык-мышык борын тарткалаганмын да балавыз сыга язганмын. Шәфкать туташы: «Ела, ела, иптәш Сәләхетдинов. Ындыр табагы хәтле арканнан ярты котелок снаряд ярчыгы чүпләгәндә бер тапкыр да ыңгырашмаган идең, хәзер инде рәхәтләнеп ела!» – дигәч, язгы ташу шикелле җәелепләр торып елыйсым килеп китте. Елмайдым гына. Ә хәл еларлык, ахрысы: аркам яраланса, ник корсакта ятмыйм соң мин? Шәфкать туташы: «Иң әйбәте, аңга килдең, Сәләхетдинов», – дип юата да бит... Ярар, күз күрер тагын. Беренче генә яралануым түгел. Бусында савыкмыйча калырга һич ярамый, йөзе кара Берлинга җитеп киләбез ич.

Бу хатымдагы шәмәхә карандаш белән язылган юллар урыны-урыны белән чыланып җәелгән икән, аны минем шатлык яшьләре дип уйлый күрмә тагын. Мин әле хат язарлык хәлдә түгел, шәфкать туташына әйтеп торып кына яздырам. Шәмәхә карандаш юлларына аның күз яшьләре тама. Үзе яза, үзе елый, юләр. Ник елый торгандыр – белмим. Ачыкланганча, һәммә җирем бөтен, буем шул ук – бер карыш та кимемәгән килеш.

Ярый, сау булып тор. Сине сагынучы пехота Сәләхетдинов дип белерсең».

* * *

Авыр яраланганнан соң кыска гына вакытка аңына килеп, күңелендә йөрткән кызга үз гомерендә беренче һәм соңгы хатын әйтеп яздырган гвардия рядовое Сәләхетдиновны шул кичне госпиталь урнашкан замок бакчасына күмделәр. Карт юкә төбендәге җепшек кар каплап өлгергән яңа кабер шәфкать туташы учындагы адрессыз хатны хәтерләтә иде.

Бөек Ватан сугышында әсирлеккә төшүчеләр турында матбугатта шактый күп язылды. Әсирләрнең саны турында төрле мәгълүматлар китерелә. Безнең сәяси җитәкчеләр, генераль штаб, аларга ияреп кайбер журналистлар сугышта югалткан кешеләребезнең саны соңгы кешесенә кадәр мәгълүм, дип ышандырырга тырыша.

Халык батырларын онытмый

Әмма сугыш барган җирләрдәге урманнарда, сазлыкларда тауларда һаман да мәетләрнең сөякләре, сугышчыларның шәхси әйберләре табылып тора. Соңгы мәгълүматларга караганда, Ватан сугышы чорында 5,74 миллион совет солдаты һәм офицеры әсирлеккә төшкән. Билгеле, бу санны да төгәл дип раслау авыр. Чөнки «хәбәрсез югалды» категориясенә кертелгән затлар да бар бит әле. Алар арасында да әсирлеккә эләгүчеләр, аннары төрле илләрдә яшәп калучылар булырга мөмкин.

Әсирлекнең иң күп өлеше сугышның башлангыч чорына – 1941 елга туры килә. Совет чыганаклары буенча 2 335 482, немец чыганаклары буенча 3 355 000 кеше. Сугышның беренче көннәреннән үк чик буендагы аэродромнар, авиация юкка чыгарыла, безнең гаскәрләр авиация яклавыннан мәхрүм кала. Дошман бик тиз алга китә. Безнең гаскәрләр чолганышта кала.

Ничек кенә булмасын, әсирләрнең күбесе туган ягын, гаиләсен, туганнарын сагынып яши, алар янына кайтырга тырыша. 1945 елның 8 февралендә тугыз иптәше белән немецларның «Хейнкель-111»-самолетына утырып әсирлектән качкан Михаил Девятаев исеме бөтен дөньяга билгеле. Җитмәсә, бу гади генә лагерь түгел, ә Балтыйк диңгезенең Узедом утравында немецларның ракеталар сынау үзәге дә булы. Бу батырлыкка шушы көннәрдә инде 77 ел тулган булса да, ул һаман сокландыра әле.

М.Девятаев сугышның беренче көннәреннән үк хәрби хәрәкәтләрдә катнаша. Өч ай эчендә фашистлар аның самолетын дүрт тапкыр бәреп төшерә. Ә бишенче тапкыр аның самолеты 1941 елның 21 сентябрендә ватыла. Михаил аны көч-хәл белән аэродромга кайтарып утырта һәм аңын югалта. Озак кына госпитальләрдә дәваланырга туры килә. Аннары дәвалануын төгәлләү өчен, ул Казанга җибәрелә. Бирәдә ул сугышка кадәр елга техникумында укый, бер үк вакытта аэроклубка йөри. Яшьләр кичәсендәге танцыда Михаил 1938 елда булачак тормыш иптәше Фәүзия белән таныша.

1942 елда сәламәтлеге нығый төшкәч, Девятаев кабат фронтка җибәрелә. Китәр алдыннан, алар Фәүзия белән загста язылыша. Михаил Покрышкин дивизиясендә сугыша. 1944 елның июлендә хәл нык катлаулана. Фашистлар белән көн саен берничә мәртәбә бәрелешергә туры килә. Соңгы сугышы 13 июльдә була. «Фоккер» аның самолеты койрыгына баса, самолет яна башлый. Бу хакта Девятаев командиры Боберга хәбәр итә. Ул «Шартлаганчы сикер», – дип әмер бирә. Күрәсең, очкыч канатына нык бәрелгәндер, Михаил аңын югалта. Нәтиҗәдә – әсирлек.

Сорау алу вакытында Девятаев фикерләрен бутый-бутый сөйли. Немецлар өлкән лейтенант булса да, бу адәм бик үк акыллы түгелдер, ахры, дигән фикергә килә, аның часте турында бернинди мәгълүмат ала алмыйлар.

Әмма Кляйнкенигсберг лагеренда аның чын йөзе ачыла башлый. Михаил үзенең иптәшләре белән немецларның җир асты юлына тоташтыручы чокыр казый. Инде качарга да мөмкин булыр иде, юк шул, әсирләр комендатурага казып кереп, аннан корал алып, барлык иптәшләрен азат итәргә телиләр. Девятаевны һәм аның берничә иптәшен тоталар, үлем җәзасы биреп Заксенхаузен лагерена озаталар.

М.Девятаев крематорий мичендә яндырылырга тиеш була. Әмма лагерьда чәчтараш аның номерын инде үлгән тоткын укытучы Степан Никитенко номерына алмаштырып бирә. Эсэсчылар бу хәйләнең асылын сизми кала: «Әсир Девятаев 1944 елның 5 декабрендә Заксенхаузен мичендә яндырылды», – дип язып куялар. Бераздан 1500 әсир белән бергә Девятаевны Балтыйк диңгезенең Узедом утравындагы тыюлыкка җибәрәләр. Анда «Фау» баллистик ракеталар эшләү үзәге була.

Девятаев башта шартламый калган бомбалар җыю төркемендә, аннары аэропортның очып китү, самолетлар кабул итү полосасын тигезләү буенча эшли. Һәрвакыт ничек тә качу турында уйлана. Янәшәдәге самолет белән ычкынырга ниятлиләр. Ике тапкыр качарга омтылган лейтенант Иван Кривоногов, артиллерист Владимир Соколов һ.б. иптәшләрдән команда туплана.

Әсирләр «Густав Антон»-самолетында качарга ниятли. Башкаларга караганда, ул һавага ешрак күтәрелә. Җиргә төшүгә гадәттә аңа заправка ясала. Качарга ниятләнүчеләр планнарын җентекләп әзерли. Һәркем үз бурычын төгәл белә. Немецлар да төгәл халык. Алар көндез ашханәдә бер үк вакытта туклана. Нәкъ менә шул вакытта әсирләр конвоирны үтерә, авырлык белән булса да самолет ишеген ача, аккумулятор да табыла.

Чит ил самолеты бит, төзелеше бөтенләй таныш түгел. Шунлыктан безнең очучылар аны һавага бик авырлык белән күтәрә. Шатлыктан бергәләп «Интернационал»ны җырларга керешәләр.

Урланган "Густав Антон"да «Фау»ны җибәргән вакытта кулланыла торган аппаратура да була. Шуңа күрә яшерен Пенемюндта паника башлана. Һавага «мессершмитт»лар звеносы күтәрелә, әмма алар «Хейнкель»не таба алмый. Девятаев очкычны зур осталык белән болытлар астыннан гына алып бара. Зур авырлык белән булса да, фронт линиясеннән үз ягыбызга чыгып җитә.

«Хейнкель»не безнең зенитчылар каршы ала. Аны берничә урыннан тишкәләп бетерәләр. Машинаны якындагы басуга утыртырга туры килә.

Ачлыктан кечерәеп беткән тоткыннар киемендәге коралсыз кешеләрне күргәч, зенитчылар хәлне тиз аңлый. Аларны үз частьләренә күтәреп алып баралар. Штурвал артындагы Девятаевның авырлыгы ул вакытта 39 килограммнан да кимрәк була инде.

Беренче эш итеп аларны ашханәгә алып киләләр, тавык ите белән сыйлыйлар, чама хисе югалмасын дип табибләр күзәтеп тора. Ракета үзәгеннән качкан икәнен белгәч, Михаилны Ольденбергка 61 нче армия командующие генерал-лейтенант Беловка җибәрәләр. Ул «Фау»ны ничек очырулары турында сөйли, корылмаларның сызымнарын сызып күрсәтә. Шуннан соң безнең авиация утрауны берничә көн бомбага тота. 14 февральдән соң утраудан бер генә «Фау-2» ракетасы да очмый.

Шулай да Совет җирендә Девятаевны һәм офицер званиесе булган ике кешене тикшерү бик озак дәвам итә. Рядовойларны фронтка җибәрәләр. Аларның бары берсе генә Җиңү көнен исән-сау килеш каршылый.

М.Девятаевны Псков өлкәсенә фильтрация лагерена озаталар. Ул декабрьдә генә өенә әйләнеп кайта. Әмма эш бирмиләр: сәбәбе әсирлектә булган.

Гаделлекне таләп итеп, Михаил югары инстанцияләргә дә хатлар язып карый, җаваплар булмый. Хатыны Фәүзияне дә төрле органнарга еш чакыралар, ирең нәрсә сөйли дип кызыксыналар.

Озак вакытлар Девятаев эшсез йөри. 1957 елның 23 мартында «Литературная газета»да журналист Ян Веницкийның батырлык турында очеркы басылгач кына, хәл үзгәрә. Икенче көнне үк Девятаевны Мәскәүгә елга флоты министры белән очрашуга чакыралар.

1957 елның 15 августында М.П.Девятаевка СССР Югары Советы президиумы указы белән Советлар Союзы Герое исеме бирелә. Легендар герой илебез халыклары горурлыгына әверелә.

М.Девятаев авиациягә бүтән әйләнеп кайтмый. Пенсиягә чыкканчы Казанда «Метеор» капитаны була.

Әсирлек Бөек Ватан сугышына гына түгел, башка чорларга да хас, Казан очучыларының исеме 1995 елның 3 августында тагын бөтен дөньяга мәгълүм булды. Ул көнне Әфганстанда рәсми хөкүмәткә каршы көрәш алып баручы «Талибан» хәрәкәтенең хәрби очкычы Ил-76 йөк самолетын Кандагар аэропортына төшерргә мәҗбүр итә. Казанның "Аэростан" компаниясенең әлеге самолеты Гарәп Әмирлекләренең «Трансавиа» компаниясенә эшли. «Айран афган айрлайн» дәүләт компаниясе заказы буенча Тирана-Шарджа-Кабул маршруты белән сугыш кирәк-яраклары ташый торган була. Командир Владимир Шарпатов, икенче очучы Газинур Хәйруллин, штурман Александр Здор, бортинженер Юрий Вшивцев, инженерлар Сергей Бутузов һәм Виктор Рязанов, бортинженер Әсхәт Аббязовтан торган экипаж талибляр әсирлегенә нәк шулай эләгә.

Төрле дәрәҗәдәге дипломатларның әлеге четерекле хәлне сөйләшүләр юлы белән гамәлгә ашыруга тырышулары нәтиҗә бирми. Әсирлеккә төшүләренә 1 ел да 13 көн дигәндә Казан экипажы бөтен дөньяны шаккатырып, үз самолетларын «урлап» әсирлектән кача. Казан очучыларының кыюлыгы, тәвәккәллеге, фидакярлеге турында хәбәр Җир шарын урап чыкты.

Әгъзам ФӘЙЗРАХМАНОВ.

АНА ҺӘЙКӘЛЕ

Талантлы татар скульпторы Артур Давыдовка – 32 яшь, әмма ул инде күп кенә саллы хезмәтләре белән горурлана ала.

«Без белдек: шәһәр булачак!» дип аталган скульптура композициям Түбән Кама төзелә башлауның юбилеена туры китереп, 2021 елның сентябрендә урнаштырылды, – дип сөйли Артур. – Бөтенсоюз комсомол төзелеше дип игълан ителгәч, бирегә шәһәрнең беренче төзүчеләре юл алган. Буш кырга башта геофизик комсомоллар килеп кала урынын билгеләгән. Димәк ки, скульптура композициядәге тугыз бронза сын арасында аларның һөнәре беренчеләрдән булып сурәтләнергә тиеш, дип фикер йөрттем. Сын концепциясе буенча, Түбән Каманы төзүдә катнашкан төп һөнәр ияләрен күрсәтеп чыгу таләп ителде. Шуңа күрә композиция чишелеше һөнәр ияләрен тасвирлауга барып тоташты. Хатын-кызлар да хөрмәтләп искә алынды. Композициядә тагын бер элементны, архив документы ягъни калада урнашачак объектлар схемасы, каланың һәм сәнәгать зонасының генераль планын тасвирларга кирәк иде. Сыннарымның нигезен 1957 елдан башлап тупланган фотосурәтләр архивына таянып төзедем, шул тарихи сурәтләрдәге хезмәт кешеләре минем өчен җыелма образ мисаллары булып торды. Әлеге сыннарда очраклык булса да, кайберәүләр үз танышларын, дусларын да «таныды». Патриотизм, хезмәт каһарманлыгы хакындагы китапларны күп укыдым бу вакытта. Беренче төзүчеләр белән очрашулар да оештырылды. Һәр образ концепциясен хезмәт ветераннары белән берлектә кабул иттек. Гомуми эскизны ветераннар да күреп сөенде».

А.Давыдовның әлеге күләмле хезмәте Түбән Камадагы беренче иҗади эше генә түгел. 2019 елны ул шәһәрнең Җиңү паркындагы биш Советлар Союзы Герое һәм биш Дан ордены тулы кавалерларының бюстларын реконструкцияләгән иде. Аннары А.Давыдов белән Түбән Каманың Т.Миңнуллин исемендәге Татар драма театры алдына яңа скульптура композициясен урнаштыру мөһимлеге хакында сөйләшү башлаганнар. 2020 елда аның милли колоритлы хезмәте – «Әлдермештән Әлмәндәр» комедиясендәге эпизод сурәтләнгән скульптура композициясе театр алдындагы мәйданга куелды. «Проект өчен спектакльдән авыл агасы һәм аның оныгы арасындагы әңгәмә эпизоды сайлап алынды: эскизларны ясый башлауга ук, мин бу идеянең уңышлы композициясе булачагын күзалладым. Такта шомарту җайланмасына (верстакка) утырган ир-ат образын драматург Т.Миңнуллин йөзе чалымланырлык итеп үк ясадым. Ике метрдан артык биеклектәге әлеге хезмәтем бронзадан коелды», – ди сынчы. «Гомумән, совет чоры күңелемә бик якын. 1960 елларда төшерелгән йөзләрчә фотолар, тарихи фильмнар карап, иҗат итәм», – дип сөйли ул.

Артурга еш кына әлмә такталар иҗат итәргә дә туры килә. Әйтик, Кукмарадагы мәшһүр киез басу фабрикасы җитәкчеләренә багышланган мемориаль комплекс өчен әлеге фабриканы озак еллар буе җитәкләгән Ш.М.Әхмәтшин бюстын, башка директорларга багышланган мемориаль тактаны да ул әзерләгән. Фабрика алдына урнаштырылган бизәкле, 2,5 метрлык «Кукмара киез итекләре» дә – аның иҗаты! Туган як тарихын кадерләп саклау, гади хезмәтне хөрмәтләү максатына юнәлдерелгән башка эшләре дә җитәрлек. Әмма әүвәл аның ничек скульптор булып китүен аныклыйк.

«Мин, – ди Артур, – Мамадышта, дүрт балалы гаиләдә туып-үстем. Әүвәл сынлы сәнгать мәктәбен тәмамладым. Урта мәктәптән соң, декоратив-гамәли сәнгатькә өйрәнәсем килеп, Казан сынлы сәнгать училищесының керамика бүлегендә укыдым. Аннары Мәскәүнең В.И.Суриков исемендәге дәүләт академик сынлы сәнгать институтының Казандагы филиалы ачылды, мин шунда скульптура бүлеген тәмамладым. Укытучыбыз, сынчы-остазыбыз Асия Миңнуллина алты ел бар тәҗрибәсе белән уртаклашты, без аның һәрбер сүзен йотлыгып тыңладык, гел янында бөтерелеп йөрдек. Асия ханым белән без, аның барлык студентлары, әле дә бик дус, әле дә аның белән тыгыз хезмәттәшлектә. Казанда хәзер дистәдән артык яшь скульптор бар, барыбыз да – сынчы Асия Миңнуллина укучылары»

2014 елда рәссам-скульптор дипломын алган А.Давыдов бер ел узгач Россия Рәссамнар берлегенең Татарстан бүлегенә кабул ителә, бүлек оештырган һәр күргәзмәдә катнаша. Ул иҗат иткән, милләтебез тарихына бәйле шәхесләргә багышланган җитди хезмәтләр дә шактый.

1941 ел җәендә Брест крепосте оборонасы җитәкчеләренең берсе, майор П.М.Гаврилов бюсты да нәкъ аның эскизы буенча иҗат ителә. Бюстны быел 22 июнь көнне тантаналы рәвештә ачу планлаштырылган. Керәшен каһарманы, 1900 елда Лаеш өязенең Әлбәдән авылында (хәзер Питрәч районына керә) дөньяга килгән Петр Гаврилов полкы 1941 елның маенда Брест крепостена күчерелә. Илбасарлар дивизиясе белән сугышканда, аның җитәкчелегендәге дүрт йөз хәрбидән нибары унике кеше, дүрт пулемет кына исән кала. Ә аннары... төркем форт эченнән чыгып, һәрберсе төрле җиргә таркалгач, ул берүзе генә кала. 23 июльдә әсирлеккә эләгә. Яралы, ач, талчыккан. Фашистлар аның каһарманлыгына гаҗәпләнеп, аны хәтта атып үтерергә дә теләмәгән... 1945 елның маена кадәр татар каһарманы концлагерьларда... Ә менә фильтрацион лагерьдан соң инде аны «партбилетын югалткан» дип партиядән чыгаралар, хәрби званиесеннән мәхрүм итәләр,

ҮЗ СӘГАТЕН КӨТӘ

һәм хәтта Гражданнар сугышында ук кыю сугышкан бу батыр «XX лет РККА» медаленә дә лаек түгел дип, медален дә кире алалар. Туган авылына кайткан П.Гаврилов колхоз эшенә дә кабул ителми. Ул авылдашларының аңа сатлыкҗан итеп караулары, үзен кимсетүләрен, аркасына бәрәңге томыруларын онытмый. Бераздан ул Краснодарга чыгып китә. Анда да башта нибары кара эшче булып эшли, аннары гына заводка экспедитор булып урнаша. 1950 елларда язучы С.Смирнов Брест крепосте геройларын табып, алар хакында яза, китап нәшер итә, радиотапшырулар эшли. Шушы хезмәтләрдән соң П.Гаврилов халык каһарманына әйләнә, хәрби званиесе дә, медале дә иясенә кире кайтарыла. 1957 елда аңа Советлар Союзы Герое исеме бирелә. 1979 елны, 78 яшендә җан тәслим кылгач, васыяте буенча, Бресттагы гарнизон мемориаль зиратында, үз хәрби иптәшләре янына җирләнә.

Яшь скульптор, иҗат төркеме составында, төрле сыннарны төзекләндерү, кайберләрен яңадан торгызу эшчәнлегендә дә актив катнаша. Мәсәлән, Казанның Лядов паркындагы XIX гасыр ахырында урнаштырылган, күп фигуралы борынгы фонтанны бары тик фотосурәтләргә карап кына яңадан торгызуга үз өлешен кертә. 2019 елны Казандагы С.Орджоникидзе исемендәге скверда шушы шәхеснең сынын яңадан торгызу төркеме составында эшли. Дәрвишләр бистәсенең Сәид-Галиев исемендәге мәдәният йорты янындагы берничә совет чоры парк скульптураларын төзекләндерү белән шөгыльләнгән иҗат төркемендә дә була. «Совет эпохасы сыннарының күбесе Казанда кадерләп саклана», – дип ассызыклый Артур. Безнең илдә Бөек Ватан сугышындагы каһарманлыкларга багышланган мемориаллар, сыннар – сан буенча иң күбедер...

А.Давыдов иҗатында аның гаять югары дәрәҗәдәге иҗади идеясе, яңа эскизы да бар. Мамадыш районының Урта Кирмән авылында яшәгән, сугыш кырларында сигез ир баласын югалткан гаилә белән бәйле эскиз ул. Фатыйха белән Фәттах Әхмәдиевлар гаиләсендә сигез ир бала һәм бер кыз бала үскән. Әлеге каһарманнарны үстергән, әмма сугыштан соң аларның берсе белән дә күрешергә насыйп булмаган шушы Анага һәм уллары сугыштан кайтмаган барлык аналарга да багышланган Ана һәйкәлен күпләр белә. Ул Мамадышта 1997 елда ук ачылган иде. «Минә соңгы вакытларда шушы тарихи темага янә игътибар артты, бу гаилә – яу кырларында сигез улы һәлак булган бердәнбер Татарстан гаиләсе санала. Әхмәдиевлар гаиләсе тарихы туган якны өйрәнү музеенда һәрчак сөйләнә. Мин бу тарихны бик күптәннән бирле беләм. Әнием Гөләндәм Давыдова да – шушы музейның фәнни хезмәткәре бит. Гаиләдәге Исмәгыйль Фәттахов (ир балаларның фамилияләре әтиләре исеме буенча барган) Гражданнар сугышында һәлак булган... Минә Фатыйха апа Бөек Ватан сугышында өчесе һәлак булган һәм тагын өчесе хәбәрсез югалган улларын истә тотып еласа да, төпчек улы Әгъмәлетдинне өзелеп көтеп яши башлаган. Төпчек улы әнисенә һәрдаим диярлек хатлар язган. 1945 елның маенда да исән булган. Ләкин 1945 елның августында, Япония белән сугышта, бер биеклекне алганда, күкрәге белән дошман амбразурасын каплап, батырларча һәлак булган, – ди Артур. – Соңгы вакытларда нәкъ менә Фатыйха Әхмәдиевага багышлап яңа һәйкәл – Ана һәйкәле урнаштыру максат итеп куелды. Әлеге һәйкәл бәйгесендә теләп катнаштым. Әлеге сигез бертуган татар каһарманнарының фаҗигале язмышларын Мамадышның төбәкне өйрәнү музеендагы аларга багышланган махсус экспозиция аша тагын бер кат барладым, андагы гаилә ядкарьләренә янә бер кат күз салдым, Ана тукыган сигез бизәкле сөлгене дә, Анага улы Ибраһим тарафыннан һәлак булган абыйсы Исмәгыйльнең төсе итеп тапшырылган, 1904 елны ук нәшер ителгән Коръән китабын да күрдем, Фатыйха ханымның оныгы Мәрзия апа Бикмурзина белән дә күрешеп сөйләштем. Фатыйха апаның сурәте сакланып калган бердәнбер фотога бар игътибарымны тупладым... Озак уйландым. Нәтиҗәдә, шушы психологик портретка таянып та иҗат иткән һәйкәл эскизым, аналарның бар түземлеген, тырышлыгын, миһербанлыгын, игелеген данлаучы символ буларак ясалды. Аның Мамадышта урнаштырылуын күрергә насыйп булсын иде дип телим. Мамадышта бит гомумән өр-яңа музей – Әниләр музее ачу планлаштырылды. Һәм әлеге музей алдындагы мәйданда эскәмиягә утырган хәлдә, бер кулын үзе җыйган болын чәчәкләренә һәм бизәкле сөлгегә куйган, икенче кулына Коръән китабын тоткан Фатыйха Әхмәдиева сыны, аңа багышланган шундый һәйкәлем куелса, бик яхшы булыр иде! Иҗади конкурска тәгаен йомгак ясалмады әле. Аның нәтиҗәләрен көтәм».

Йөрәккә үтәрлек әлеге хезмәтне тасвирлаганда шул хакта да әйтик: скульптор тарафыннан әлеге Ананың үз куллары белән тукыган сигез бизәкле сөлгесе дә өстәлгән бу һәйкәл эскизыннан җылылык бөркелә! Фатыйха Әхмәдиева турында белмәүчеләр дә һәйкәлгә бер карауда ук анда кулына Коръән китабын кысып тоткан татар хатын-кызы, татар әбисе – Ана сурәтләнүен аңларлык булачак. Эскизның гомуми энергетикасы куәтле! Әлеге нәсел дәвамчыларының берсе, Урта Кирмән авылында гомер итүче, унынчы дистәне ваклаучы Мәрзия Бикмурзина да шушы һәйкәл эскизын күреп: «Әйе, бу нәкъ безнең дәү әниебез!» дигән икән, димәк, тулы охшашлык бар! Әлеге Ана сыны эскизына Мамадышка эш сәфәре белән килгән Татарстан илбашы да күз салган инде... Шунысын да ассызыклыйк: сугыш кырларында улларын югалткан мондый аналар күп милләтләрдә бар. Һәр халык диярлек, шундый зур кайгы кичергән аналарга багышлап, һәйкәлләр урнаштырды. Аларны игътибарсыз калдырган милләтләр, гомумән, бар микән инде? Шуңа күрә татар җирендә дә, мондый татар Анасына багышланган һәйкәл кую бик вакытлы... Сынчы Артур Давыдовның әлеге идеясе, милли рухлы, мәгънәле эскизы чын һәйкәл булып тормышка ашар көн дә килеп җитсен!

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.

Мәдәни җомга
6 май
№17, 2022

Кырымдагы партизаннар хәрәкәтендә төрле милләт кешеләре катнашкан, әмма алар арасында кырымтатарлар язмышы тарихчылар өчен дистәләрчә еллар буе тыелган тема булган. Тарих фәннәре докторы Владимир Поляков Кырым Республикасы Дәүләт архивларына таянып, ул чактагы барлык бүләкләү документларын, партизаннар исемлекләрен өйрәнеп, Кырым татарларының үз ватаннарындагы партизаннар хәрәкәтендә катнашуы хакында хакыйкатьне торгызырга омтыла. Кырымдагы вакыйгаларны теркәгән беренче рәсми документ – «Кырым партизаннар хәрәкәте штабы хисабы». Ул 1944 елның язынннан 1946 елның февраленә кадәр алып барылган. Хисапны язучы ВКП(б) ның Кырым өлкә комитеты хезмәткәрләре ике максат куеп эшләгән: «эчке» бурыч – партиянең Кырым өлкә комитеты ролен күпертеп, «хәрби»ләрнең йогынтысын киметеп күрсәтү; «тышкы» бурыч – Кырым халыкларын депортацияләүне аклау.



КЫРЫМ

Сталин вафатыннан соң әрмән, болгар, грекларга карата әлеге сәясәт туктатылса, кырымтатарларны дискредитацияләү Кырым телевидениесендә дә, матбугатында да хәзергә кадәр дәвам итә.

Җитди фәнни тикшеренүләр булмау әлеге вакыйгаларда турыдан-туры катнашучыларның «истәлекләре» белән компенсацияләнә. Шундый тәүге хатирәләр Ленинградтагы «Звезда» журналында 1966 елда бастырыла. Әлеге материал көтмәгәндә Кырым хакимиятенең ачуын чыгара. Партиянең Кырым өлкә комитеты секретаре А.Н.Макухин редакциягә һәм КПССның Ленинград өлкә комитетына ярсулы хат юллый: анда ул язма авторы Илья Вергасовны партизаннар хәрәкәтен партархив документларына таянып түгел, бәлки үзенчә тасвирлауда, Кырым татарларын нигезсез аклауда гаепли. Мондый гаепләүдән соң Вергасов та, башка авторлар да инде партия күрсәткән «фарватердан» гына бара. Шуннан соңгы дистәләрчә ел буе бер клише буенча язылган «дөрес» китаплар гына чыга: бөтен командир акыллы, разведчиклар – куркусыз, комиссарлар – сизгер һ.б. Партизаннар арасында кырымтатар фамилиясе телгә алына икән, берничә җөмләдән соң ук ул йә качкын, йә хыянәтчегә әйләнә. Әлеге «хатирәләрдәге» бер генә вакыйгага да башка чыганаклар буенча тикшермичә ышанырга ярамый.

Әйтик, авторлардан берсе болай искә ала: *«Безнең берләшмәнең комиссары Василий Ильич Черный тыныч вакытта да идеология фронтында алга бара...»*

Эш шунда ки, Василий Черный беркайчан да берләшмә комиссары булмый. Үз халкы белән бергә Кырымнан куылган, Көньяк берләшмәнең чын комиссары Мостафа Сәлимов язмышы исә укучылардан аңлы рәвештә яшерелә, аның исеме башка кешенекенә алыштырыла.

Инде XXI гасырда бастырылган хатирәләр арасында да игътибарга лаеклары бар. Автор элек язу тыелган каннибаллык темасына туктала. Үзе катнашкан вакыйгаларны гадел тасвирларга тырыша. Шул истәлекләрдән бер гыйбарә нигәдер таныш төсле тоелды: *«Хатын-кызлар диверсия төркемендә Надя Комарова, Вера Яковенко, Шура Рыболовова һәм Мария (фамилиясен хәтерләмим) кергә иде. »*

Бик таныш җөмлә, кайчандыр укыганым бар кебек. Үземнең партизаннар почтасында актарынып, таптым бит барыбер: *«Отрядта хатын-кызлар диверсия төркеме оештырылды, алар юл һәм күперләргә мина куярга тиеш. Төркемдә без дүртәү: Лена, Шура Рыболовова һәм соңрак Колпаковка кияүгә чыккан тагын бер кыз идек.»*

Бу – Маминә Бәкерова хатирәләреннән алынган юллар. Ихтимал, авторның «эчке цензоры» уянгандыр. Тексттан партизан кырымтатар кызының фамилиясе юкка чыккан. Таныш хәл! Әгәр сатлыкҗан, дезертир икән – кырымтатар исем-фамилиясе куела. Ә диверсант кыз икән, «Мария (фамилиясен хәтерләмим)» булып чыга. Кырымтатар кызларының партизан булуын беркем дә белергә тиеш түгел, янәсе.



Акт
О злодеяниях немцев в деревне Стиля, 20го 21го декабря 1943г.
Мы нижеподписавшиеся командир 9го партизанского отряда Пармонов Михаил Федорович, комиссар отряда Мамутов Мустафа, Сельский врач Халилев Вели, уполномоченный села Бекиров Эбазер, жители села Пароли Сеит Мемет и Курт-Шерфе Элмир Усеин составили настоящий акт о нижеследующем:
После двухдневных упорных боев бойцы 9го отряда бригады крымских партизан оставили дер. Стиля. Противник ворвался в деревню танками, бронемашинами и значительной силой пехоты. Заняв село немцы начали грабить дома, избивать и расстреливать мужчин, изнасиловать и убивать женщин. На следующий день немцы силой увели население, угнали скот, вывезли продукты, сожгли амбары и всю деревню. Ниже приводим

сгорели в своем доме, когда подожгли дом. Но, [illegible] дом поджег, а старуха спаслась.
Перед занятием деревни большая часть населения ушла в лес. Немцы оцепили деревню и собрали всех оставшихся в селе жителей. Затем, они вышли из деревни и собрали всех остановившихся в [illegible] крестьян привели в деревню и всех вместе увели в направлении г. Бахчисарай.
Сожжение деревни. Основной целью прихода немецких бандитов, хотя они прикрывались вывеской «борьба с партизанами», был сожжение деревни. Это видно из того что после сожжения села они поспешно ушли обратно, не думая о партизанах.
После насильного увода населения немцы сожгли всю деревню. Из 217 домов сожжено 196, не сгоревшими остались 21 дом. Сожжены так же все сараи, конюшни, амбары с зерном и другими с-х продуктами. Перед сожжением они входили в дома и забирали ценные вещи.

Тәүге отрядлар

ВКП(б) ҮК һәм СССР Халык комиссарлары советының 1941 елның 18 июлендә кабул ителгән «Германия гаскәрләре тылында көрәшне оештыру турында» карарын партизаннар хәрәкәтен формалаштыру буенча беренче норматив документ дип санарга була.

Ярымутраудагы вәзгыятьне дөрес бәяли алмаган Кырым җитәкчелеге партизаннар хәрәкәтен оештыруга нык соң тотына. ВКП(б)ның өлкә комитеты Кырымдагы партизаннар хәрәкәтенең командующиен Кызыл Армиянең Симферопольдән чигенүенә бер атна кала гына билгели. Партизан районнарының җитәкчелек-сәяси составы турында карар оккупациягә 2 тәүлек кала гына кабул ителә.

Отрядлар формалаштыруда иң җайсыз «номенклатура» принцибы сайлана. Партиянең һәр район комитеты үз активыннан отряд оештырырга тиеш була. Оккупацияләнгән территорияләрдә партизан отрядларының нинди срокка каласы да төгәл билгеләнми. 1942 елның июнендә үк А.В.Мокроусов: «Немецләр Кырымда май аеннан да артыкка калмас, дип фаразланды, шунлыктан алты айга исәпләнгән чаралар гына планлаштырылды», - дип яза.

Азык-төлек китерәләр, әмма аны яшерергә вакыт та, теләк тә булмый. Әзерлек чорын нәтиҗәле үткәргән санаулы отрядлардан берсе – партиянең Зуя районы комитеты беренче секретаре Н.Д.Луговой үзе комиссар булган берләшмә генә. Башка районнар мактана алмый. Партизан отрядлары челтәрен төзү вакыты тиешенчә файдаланылмаганга, анда җанкыяр (истребительный) батальоннар сугышчыларын җибәрә башлыйлар.

А.А. Сермуль болай искә ала: *«Северский җанкыяр батальонны тезде һәм аның 3 нче Симферополь партизан отрядына әйләнәчәген белдерде. Ризалар бер адым алга атларга тиеш иде. Йөздән артык кеше партизан булырга ризалашмады, коралын җиргә куеп, китеп барды»*, – ди.

Өлкән яшьтә булу, женес, зәгыйфьлек кебек факторлар исә партизан отрядын оештырганда бөтенләй исәпкә алынмый...

Котәргә ... фәрман бирелә

Кырымда партизан хәрәкәтен оештырырга тиешле, әмма үзләре Кавказга качкан кешеләр 29 берләшмә формалаштырырга тиеш була, тик 1941 елның 1 ноябренә урманга 24 отряд кына килә. Беренче көннәрдә үк икесе таркала, әмма 15 ноябрьгә урмандагы Кызыл Армия сугышчылары һәм командирларыннан торган 6 отряд пәйда була.

Хәрбиләрне барлык башка отрядларга тигезләп бүлү урынына А.В.Мокроусов алардан аерым отрядлар оештырырга фәрман бирә, беренче көннән үк азык-төлек запасыннан мәхрүм берләшмәләр җирле халыктан таларга мәҗбүр була, бу исә тиз арада партизаннар белән җирле халык арасында кискен каршылык тудыра.

Кырым тауларында коралды кешеләр туплану хәбәре шундук оккупантлар колагына да барып ирешә. Тиз генә Севастопольне яулау планы барып чыкмагач, фронттан алынган гаскәрләр урманнарны «чистарта» башлый, җәзалаучылар барып җитмәгән бер генә партизан отряды да калмый.

Кырымда урманнар зур түгел, әмма андагы рельеф партизаннарга чолганышка эләкмәү мөмкинлеге бирә. Югалтуларга карамастан, партизан отрядларының сугышчан үзәге саклап кала.

Немец документларында 11 азык-төлек базасын юк итү теркәлгән. Ә совет мемуарларында базаларның «кырымтатарлар тарафыннан талануы» сурәтләнә.

Ачлык Кырым партизаннарының иң аяусыз дошманына әйләнә. Бу авыр вакытта партизаннар хәрәкәтендә Кырым татарларының әһәмияте искиткеч зур була, чөнки җирле тауларны, урман сукмакларын, мәгарәләр-

ПАРТИЗАННАРЫ


более подробные данные о зверствах немецких фашистов в селе.

1. Сразу после занятия деревни немцы начали грабить, избивать, расстреливать мирных жителей и изнасиловать женщин. Так, например, они изнасиловали, а затем придушили и пристрелили [illegible] Хатидже Сеит Умер. После ухода немцев она была найдена мертвая, в лежачем положении, голая с разорванной одеждой. На шее у нее были следы пальцев, а в области живота пулевая рана.

Кроме того немцы демонстративно, у всех на глазах, изнасиловали молодых девушек и женщин в помещении школы. Немцами расстреляны, также, [illegible] Бекир и [illegible] Шевки. Несколько человек из деревни [illegible] сожжены в своих домах, [illegible] 70 лет, [illegible] 85 лет, [illegible] 80 л., [illegible] 38 лет. Предположение о том, что указанные лица сожжены подтверждается тем, что гражданка Курт-Шерфе Эмир [illegible] была

Вышеприведенные злодеяния кратким описанием злодеяний фашистских палачей в деревне [illegible]

Подписи: 1) [illegible] 2) [illegible] 3) [illegible] 4) [illegible] 5) [illegible]

не, чишмәләрне алардан да яхшырак белүче юк бит. Шунлыктан алар отрядны немец эзәрлекләүчеләренең борын төбеннән үк алып китеп коткара алган. Кырымтатар милләтле юл күрсәтүче партизаннар «алтын бәясенә» йөргән: Әмәтов Әбибулла, Әмәтов Ибраһим, Аппазов Мәмәт, Әширов Абдулла, Бинсәетов Умәр, Бережной Андрей, Вәлиев Смаил, Исламов Сәет, Мәмүтов Әсән, Мурадосилов Абдрахман, Хәлилов Әмир.

3 нче партизан районының штаб башлыгы Илья Вергасов шулардан берсе турында тәэсирләрен болай сурәтләгән: «Алда – юл күрсәтүче Арыслан. Бу кешене эзләп табарга теләүчеләр бик күп, шунлыктан ул үзенең фамилиясен яшерә. Аңа 25 яшь тирәсе, сыны коеп куйган кебек, чыдам, андыйны көндез чыра яндырып эзләсәң дә тапмыйсың. Җирлекне искиткеч шәп белә, тылсымчы кебек. Нечкә борын канатларын киереп, иснәнә дә, төп-төгәл юнәлешне ачыклый. Юл күрсәтүче артыннан командир үзе бара...»

Сүз Алушта, Бакчасарай, аннары 2 нче секторның 2 нче отрядында юл күрсәтүче булган Ибраһим Әмәтов хакында бара. Гестапочылар аның хатыны белән ике баласын кулга төшерә һәм җәзалап үтерә.

А.В.Мокроусов фәрманы буенча отрядлар тау авылларына даими һөҗүм итә. Мондый «партизаннар талавыннан» соң халык ихтыярсыздан кулына корал алып үз йортын сакларга мәҗбүр була. Архив документларыннан күренгәнчә, 1941 елның 8 декабрендә 3 нче һәм 4 нче партизан районнары отрядлары Мокроусов боерыгы буенча Куыш авылында старшина йортын яндыра, 250 сарыкны, Акшәех отрядыннан яңәсе җирле халык талап алган азык-төлекне алып китә, андагы 120 кеше дезертирлыкка чыгарыла.

Шул ук вакыйга турында икенче фаразны исә партиянең Кырым өлкә комитеты бюросы карары текстыннан табып була: *«Куыш авылында, кайда – дошман, кайда дус икәнен дә карап тормыйча, элеккеге 4 нче район партизаннары исерек килеш погром оештыра».*

Керчь янында җиңелүдән соң совет җитәкчелеге Кырымдагы партизаннар хәрәкәтен туктату, алардан бер өлешен эвакуацияләү, «артыкларын» өйләренә кайтарып җибәрү, урманда исә килачәктә отрядлар өчен нигез булырлык нык үзәкне генә калдыру турында карар кабул итә.

Кырымдагы партизаннар сугышының беренче елында аяусыз «табигый сайланыш» була. Отрядларда Гражданнар сугышында катнашучылар, яше 45 тән артканнар калмый, 329 хатын-кыздан нибары өчесе генә калдырыла. Партизаннар хәрәкәте башланганда анда барлыгы 3733 кеше теркәлсә, бер елдан соң, 1942 елның ноябренә 480 кеше генә исәпләнә. Ачлыктан 450 кеше үлә, сугышларда 1000 кеше һәлак була, 600 кеше хәбәрсез югала һәм кача, «Зур җиргә» 770 кеше чыгарыла, 500 кеше яшерен эшкә җибәрелә.

Автор төзегән исемлекләргә таянып, әйдәгез 1941 елның 1 ноябреннән 1942 елның 25 октябренә кадәр партизаннар хәрәкәтендә катнашкан Кырым татарларының күмәк портретын күз алдына китереп карыйк.

1.Партия-совет номенклатурасы, НКВД, прокуратура – 125 кеше.

Шәһәр, район комитетлары аппараты, башкарма комитет җитәкчеләре – 31.

Колхоз һәм авыл советлары рәисләре, предприятие һәм оешмалар җитәкчеләре – 56 кеше.

НКВД, суд һәм прокуратура хезмәткәрләре – 32 кеше.

2. Хезмәткәрләр, эшчеләр, колхозчылар – 60 кеше. Шулардан ВКП(б) әгъзасы – 18 кеше.

3. РККА һәм Хәрби-Диңгез Флоты командирлары – 17 кеше.

4. Социаль хәле күрсәтелмәгәннәр – 105 кеше. Шулардан ВКП(б) әгъзалары – 35 кеше.

Барлыгы 307 кеше. Шулардан ВКП(б) кандидатлары һәм әгъзалары 63,5% тәшкил иткән. Тик шушы тәүге партизаннар арасыннан 165 кеше яуда һәлак булган, 35 е Зур җиргә эвакуацияләнгән, 29 сугышчы «махсус задание» белән җибәрелгән, 9 кеше урманда яшеренеп калган, ә 52 кеше дезертирлык кылган, ягъни яу кырын ташлап качкан. Соңыннан аларның 8 ен атып үтергәннәр.

Партизаннар хәрәкәтен җитәкләгән А.Мокроусов яңа сугыш таләпләрен аңламый һәм, Гражданнар сугышының искергән тәҗрибәсенә таянып, партизаннарның авылларны яулавын һәм анда хуҗа булып калуын таләп итә.

Партизаннар хәрәкәтенең югары җитәкчелегендә дә кискен каршылык туа, бу Кырым штабы командующие Алексей Мокроусовны һәм комиссар Серафим Мартыновны урыннарыннан алу белән тәгәлләнә. Кырым партизаннары Кара диңгез гаскәрләре җитәкчелегенә буйсындырыла, ул партизаннар хәрәкәтен бетерергә һәм артык составны эвакуацияләргә карар кыла. Урманда нибары 9 Кырым татары кала һәм көрәшне дәвам итә.

Беренче этапта ярымутраудагы партизаннар хәрәкәтендә катнашучыларның автор төзегән исемлегендә 308 кырымтатар бар, бу барлык сугышчыларның 8,1 процентына тәңгәл. Күпме бу, әллә азмы?

Әгәр Кырымдагы партизаннар хәрәкәтендә ярымутрау халкы гына катнашса, без бирәдәге барлык кырымтатарның процент составы белән чагыштырыр идек, әмма әлеге хәрәкәт элитар буларак күзаллана һәм бары тик Кырымның партия-совет активы вәкилләре генә партизан була ала. Сугыш алдыннан үткән соңгы партия конференциясендә кырымтатар активы өлеше 11,4 процент тәшкил итүен исәпкә алсак, партизаннар арасындагы нисбәт тә шул чама булырга тиеш булган, әмма урманнарга таралган РККА һәм Хәрби-Диңгез Флоты командир һәм сугышчылары партизан хәрәкәтенең милли нисбәтен кискен үзгәрткән. Иң беренче этапта – 1941 елның 10-20 ноябрендә партия-совет активы вәкилләре, махсус истребительный батальон сугышчылары, ЭККА һәм ХДФ командир һәм сугышчылары 3511 кеше тәшкил иткән, соңрак аларга парашютчылар, Судак һәм Феодосия десантчылары өстәлгән. 1942 елның ноябренә исә Кырым урманнарында нибары 480 кеше калган.

Ничек тә исән калырга!
(1942 елның 25 октябре – 1943 елның октябре)

Кырым фронтындагы фаҗигадән соң партия өлкә комитетының карары пәйда була, анда А.В.Мокроусов кырымтатарларга хыянәтче дип яла ягуда гаепләнә.

1942 елның июленнән 1942 елның сентябрь уртасына кадәр арада партизаннарга каршы җәза операциясендә 20 меңләк немец һәм румын гаскәрләре, шулай ук коллаборационистларның полиция батальоннары катнаша. Иң әүвәл партизаннарның аэродромы кулга төшерелә, шул рәвешле алар яралыларны Зур җиргә җибәрүдән мәхрүм ителә.

ВКП(б)ның Кырым өлкә комитеты секретаре Рефат Мостафаевны фронттан чакыртып, яшерен обком секретаре сыйфатында урманга җибәрәләр. 1942 елның 2 октябрендә яшерен обкомның яңа составы раслана: Р.Мостафаев – рәис, И.Генов һәм Н.Луговой – әгъзалар. Бу комитетка партизан хәрәкәте белән Кырымның үзендә торып җитәкчелек итү йөкләнә. 1943 елның июнендә ярымутрауга төрле фронтлардан чакыртылган кырымтатарлар кайта: Мостафа Мәмүтов (сугышка кадәр Симферопольдә укытучы булып эшләгән); июльдә – Рамазан Моратов (сугышка кадәр шофер, фронтта – гвардия минометлары җайланмасын йөртүче); медицина хезмәте майоры Ваһап Җәлилев, Рамазан Күртүмәров; августта – элек райком секретарьлары булган капитан Таләт Тынчеров һәм Җаббар Колесников; әмма элегрәк эвакуацияләнгән «карт партизаннар» төп резерв булып кала.

Партизанлык хәрәкәте җитәкчеләре арасында 9 кеше – Кырымның үзеннән чыккан, ә 17 се Зур җирдән китерелгән командирлар була. Әлбәттә, яңа килгәннәр барысы да коммунист. Бер генә кеше өеннән килгән. Андыйлар күбрәк тә булыр иде, әмма, Нури Хәлилов искә төшерүенчә, бик теләсә дә, аны отрядка алмаганнар, чөнки партизаннарга азык-төлек табу элеккечә үк кыен булган. Һәм сугыш барышында шушы җитәкчеләрнең 15 е генә урманда, партизан отрядларында калган, 6 сы исә һәлак булган, 6 сы кабат Зур җиргә эвакуацияләнгән.

Күрүебезчә, эвакуация дәвам итә, әмма авырулар һәм яралылар гына күчерелә. Элеккечә үк, партизаннар сугышта һәлак була. Урманда иң яхшылар гына калганга, качкыннар юк, бер генә кырымтатар да атылмаган. Хәер, бу әлеге милләт вәкилләренә генә хас мәгълүмат: әгәр янәшәдә руслар һәм украиннарның да исемлеге булса, анда дезертирлар да, атылганнар да булыр иде.

Кырык өченче ел партизаннары
(1943 елның 25 октябре – 1944 елның 20 апреле)

1943 елның 31 октябрендә 51 нче армия Сивашның төньяк ярына һәм Перекоп муентыгына чыга. 2 ноябрьдә совет гаскәрләре Армянск янына килеп җитә. Кырымдагы аз санлы немец-румын гаскәрләренең хәле хөртиләнә. «Кырым капчыгы» бәйләнә. Румыния диктаторы Антонеску үз гаскәрләрен тиз арада диңгез юлы белән эвакуацияләргә маташа. Немец җитәкчелеге дә эвакуацияне кайгыртба башлый. Барлык хәрби һәм гражданлык учреждениеләрендә эвакуация алдыннан башлана торган ыгы-зыгы күзәтелә.

(Дәвамы киләсе санда).

Владимир ПОЛЯКОВ,
тарих фәннәре докторы.
Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА
тәрҗемәсе.

Гасырлар кичкән Бакый

(Ахыры. Башы 16 нчы санда).

Ул Соловкида күңеленә тынычлык табу өчен инглиз телен өйрәнә башлый. Соңрак ул инглиз телен үзенең ана теле, рус теле белән бер дәрәҗәдә белерлек үзләштерә. Ни гаҗәп: Американың күренекле әдибе Генри Лонгфеллоның "Һаявати турында җыр" әсәрен инглиз теленнән тәрҗемә итә башлый. Кызганыч, әсәрнең тәрҗемәсен ахырына җиткерә алмаган. Урманче өстенә кайгы-хәсрәтләр өелеп төшкәндә үзенә күңел тынычлыгын менә шулай тапкан. 1931 елда атасы газаплар күреп, чит кешенең сараенда вафат була. Бакый бу хәбәрне шактый соң ишетсә дә, бик авыр кичерә, һәм эш, һәм шөгыль белән үзен кулга ала. Бу урында Б.Урманченың Бутырка, Соловки газапларын туктатам. Аның шәхси архивында "Бутырка", "Соловки" һәм сөргеннән соң Казанга кайтуы, һәм Казан аны ничек каршы алуы хакында язылган хатирәләр сакланган...

Соловкидан кайткан Урманчега Казанның мөнәсәбәте мактанырлык булмау сәбәпле, аңа 1934 елның гыйнварында Мәскәүгә кабат китәргә туры килә. Шәкертлек елларыннан калган дуслары, нинди генә куркыныч вакытлар булуга карамастан, Урманчега ярдәм кулын суза. Ул сөргеннән кайтканда якын дусларының берсе Дмитрий Лопатниковта туктала. Казаннан Мәскәүгә киткәч тә, аның квартирасына барып керә. Ачык йөзле, киң күңелле Митрий Бакыйны ярдәменнән ташламый, квартира табарга булышлык күрсәтә, шактый вакыт бергә эшлиләр. Ул эшләр, лозунглар, аерым шәхси заказлардан гыйбарәт. Аякка басу өчен бу да ярап куя. Урманченың тырышлыгы бушка китми, тора-бара зур заказлар кабул итә. Мәскәүдә Татарстан павильонын эшләүдә катнаша. 1935 елда Мәскәү рәссамнар берлегенең эше буенча Башкортстанга, Ишембай нефть сәнагатен өйрәнергә чыгып китә. 1936 елда Мәскәүдә яшәгән зыялы морзалар нәселеннән булган Сара Баишевага өйләнә. 1937 елда улы Илдар туа, Мәскәү рәссамнар берлегенә әгъзалыкка кабул ителә. Урманче сөргеннән кайткач, кача-поса гына, вак-төяк каршылыклар белән булса да нииндидер уңышларга ирешә. Шәхси тормышындагы үзгәрешләр илһамланып эшләргә этәргеч бирә. 1941 елның язында Казахстан хөкүмәте визасы буенча, казах халкының бөек шагыйре Абайның 100 еллык юбилеена әзерлеккә чакырыла. Аның бу командировкасы 1946 елга кадәр сузыла. Сугыш чоры... Гаиләсен Алма-Атыга алдыру... Сугыш Урманченың тормышына, хыялларына төзәтмәләр кертмичә калмый. Беренчедән, озак еллар гаиләсеннән аерым яшәргә мәҗбүр, икенчедән, Абай һәйкәленең проектларын берничә вариантта эшләп тә, үзендә канәгатьлек хисе тапмый, карарга тиешле комиссия дә үз төзәтмәләрен кертеп, кабат эшләүне талап итә. Дөрес, рәссам, Казахстанда Абай һәйкәле белән генә шөгыльләнми. Казах далаларын иңли, казахның күренекле шәхесләренең портретларын ясый, казах чичәне Жумбул Җабаевның рәсемен ясау өчен ул яшәгән Җамбул тауларына юл ала. Кызганыч, чичәннең сурәте ул вафат булганнан соң гына ясала. Шул рәвешле кагылу-сугылулар белән Б.Урманченың Казахстан дәверенең беренчесе 1946 елда төгәлләнә. Әмма күпкә түгел...

Сугыштан соң илдә Сталин репрессиясенең икенче дулкыны башлана. Элек Сталин төрмәләре һәм сөргеннәре аша узганнар да бу дулкыннан котылып кала алмый. Кайда да шул бер кара сакал, дигәндәй, Урманчены "Минус 39" карары белән 24 сәгать эчендә Мәскәүдән куып чыгаралар. Кая барырга белмәгән рәссам элек яшәгән җирләре, белгән урыннары, кешеләре булган Казахстанны сайлый, анда электән калган заказларын эшләү мөмкинчелеге туа. Ул Мәскәү вокзалында бер кич кунганнан соң, поезд белән озакмы-күпкәме икәнен белмичә, Алма-Аты шәһәренә кузгала. Шуны искәртү кирәктер: бу карар нигезендә сөрелгән кеше СССРның 39 зур шәһәрләрендә яши алмый. Урманче дә НКВД күзәтүеннән качып Алма-Атыда бер кич куну белән "органнар" хезмәткәрләре озатуында, Талас даласына танылган чабан, Социалистик хезмәт батыры Картабай Атчабаров сурәтен ясарга китә. Заказын уңышлы башкарганнан соң, матди яктан шактый авыр хәлдә калган Урманчега дуслары Балхаш бакыр эретү заводының Мәдәният сарае төзелешенә барырга тәкъдим итә. Мәдәният сарае үзе кебек кимсетелүгә дучар ителгән, репрессияләнгән кешеләр, япон әсирләре белән берлектә төзелә. Б.Урманчены җирле җитәкчелек кочак җәеп каршыларга ашыкмый, кирәк вакытта таяк тыгарга да онытмый. Шунысы ачык: рәссам мәдәният сарае төзелешендә бик тә кирәкле белгечләрнең берсе санала. Ул сарайның архитекторы да, скульпторы, бизәүчесе, төзү материалларының чыдамлыгын ныгытырлык измәләр ясаучы рационализаторы да була. Әлбәттә, төзелештә эшләү рәссамның матди ягын яхшырта, яшәргә өмет уята. Ләкин бу төзелеш рәссамның иҗади сәләтен шактый тоткарлый. Эшлисе килгән эшләрне эшли алмау, зур мәйданга чыгарга мөмкинчелек булмау аны психологик яктан изә. Ул Балхаш төзелешендә 1950 – 1952 елларда эшли. 1952 елда Үзбәкстанның Сәмәрканд шәһәренә күчә. Бу шәһәрдә аның бертуган апасы Бибимөхсинә гаиләсе белән яши. Азмы-күпме монда үзен кеше итеп сизә. Хокуксызлык үзенекен эшли, әлләни сикерә алмый. Ул бу елларда Сәмәрканд өлкәсенең Сачәк-Бола авылында колхозчылар темасына рәсемнәр ясау өчен командировкага җибәрелә. Рәссамның Үзбәкстан дәверен, иң беренче чиратта, шул авылда ясалган сурәтләр искә төшерәдер. Ул монда бик тә үзенчәлекле шәхес – заманында аклар ягында торып сугышкан, Зәки Вәлиди армиясендә хезмәт иткән, Төркиядән кайтышлый кулган алынып

● Җәмәгате Флора Әхмәтова белән.

Сталин төрмәләре аша узган Казанның зыялы нәселеннән булган Галибәк Юнысов белән таныша. Ике гыйбрәтле язмыш, ике типкәләнгән шәхес, икесе дә хокуксыз... Шул уртаклык гомерлек дуслыкка әвереләдерә. Озак еллар хатлар алышып, хәбәрләшеп яшиләр.

Сталин вафатыннан соң, 1954 елда, үзе язганча, "чын паспорт" бирәләр. Бу инде рәссамның хокукларын торгызыла дигән сүз. Ул Ташкентка китәргә карар кыла. 1956–1958 елларда Ташкент театр-сәнгать институтына эшкә чакырыла. Беренче елда ярты ставка белән генә эшли. Институтта эшләгәндә скульптура факультеты ача, уйма сәнгатьнең серләрен шәкертләренә өйрәтә. Төрле конкурсларда, бәйгеләрдә катнаша. 1954–1955 елларда Абайның һәйкәлен салу буенча кабат конкурс игълан ителә. Урманче бу юнәлештә шактый эшләгән, уңышлары да бар. Ул конкурска Абай һәйкәленең камиллләштерелгән вариантын җибәрә. Б.Урманченың эшен уздырмаучыларның берсе – вакытында якын дусты саналган Мохтар Әүэзов була. Ул: "Урманче Абайны белми", – дип, аны бәйгегә керттерми. Әүэзовның тырышлыгы белән җиңүче итеп яшь скульптор, казах милләтеннән Х.Наурызбаев табыла. Әлеге вакыйга рәссам өчен көтелмәгән хәл санала. Монда Урманченың татар милләтеннән, икенчедән, репрессияләр корбаны булуы да үз ролен уйнагандыр. Үзбәкстан хөкүмәте оештырган Ибне Сина һәйкәле проекты комиссиягә ошаса да, шактый чыгымнар соравын сылтау итеп, проект икенче урынга калдырыла. Шул рәвешле скульптура өлкәсендә эшчәнлеге Урта Азиядә, төрле каршылыклар нәтиҗәсендә, уңышларга ирешә алмый.

Б.Урманченың бәхетенә, 1956 елда Татарстан хөкүмәте Мәскәүдә узачак Татарстан көннәрендә катнашу өчен Татар җыр һәм бию ансамбленә кием эскизлары әзерләүдә катнашуын сорап, аңа мөрәҗәгать итә. Туган төбәгеннән мондый тәкъдим ясалу рәссамны сөендерә, ул теләп эшкә керешә. Мәскәүдә Татарстан көннәре узган вакытта аңа Татарстан хөкүмәте тарафыннан, аерым алганда, Салих Батыев тарафыннан Казанга кайтырга чакыру тәкъдиме ясала. Көтелмәгән чакыру Бакыйда утыз елга сузылган "сөрген" чорына нокта куюга зур этәргеч ясый. Әлбәттә, бар тормышын эшкә багышлаган, инде Ташкентта ирекле рәвештә яши башлап, төпле эш урыны тапкан рәссамга бу тәкъдимне кабул итү дә, алтмыш яшьлек кешегә күченүне күз алдына китерү дә җиңелләрдән саналмый. Шуңа карамастан, утыз елдан туган туфрагыннан ихтыяри-мәҗбүри аерылып яшәгән Урманче, 1958 елда барлык мөлкәтен, әсәрләрен җыеп Казанга кузгала. Б.Урманче иҗатының иң югары үрләргә ирешкән, бөтен җанын-тәнен биреп иҗатка багышлаган өченче утыз еллыгы башлана...

Әмма Казан ул заманда да талантларны иләк аша үткәргән, бүген дә кимен куймый... Урманчены җитәкчелек теләп кайтарса да, чагыштырмача яшь буын сынлы сәнгать әһелләре аңа ачык йөз күрсәтергә ашыкмый. Рәссамның һәрбер эшенә киртә куярга, аяк чалырга тырыша. Рәссамнар берлегенең ул вакыттагы җитәкчеләре Урманче ясаган скульптура әсәрләрен хәтта караңгы почмаклар, урамнарга чыгарып куюдан да тарсынмый. Әсәр начар булганнан түгел, гади генә көнләшү, үзләренә өстенлек бирергә теләүдән... Бәлкем, мондый күренешкә яшь буын рәссамнарның һәм Б.Урманченың ике юнәлештә, ике төрле мәктәп узуы сәбәп биргәндер... Урманче XX гасырның 20 елларындагы сәнгать юнәлешендә иҗат итсә, 50–60 нчы елларда сынлы сәнгатькә килүче яшь рәссамнар ул заманда төп иҗат методы – социалистик реализм методында, иҗатчы өчен шактый чикләнгәнрәк юл белән эшләүләре дә киртә куйгандыр.

Гомере буенча күпне күргән, күпне кичергән, үзенең халкыгы өчен көрәшергә өйрәнгән Б.Урманче нинди генә каршылыкларга, аяк чалуларга карамастан, кыйблаcына тугры кала, тормыштагы интрига уеннарыннан өстен чыгып, ул Казан дәверендә югары дәрәҗәдәге скульптура әсәрләре белән тамашачысын сөендерә. Аның агачка уеп ясалган "Сагыш", "Сөембикә" уймалары гына да татар сынлы сәнгате тарихында Урманчены бөек рәссам-скульптор дәрәҗәсенә күтәрерлек.

Уңышлары, даны-шөһрәте күп булса да, ирешелгәннәргә киртә куючылар 70нче елларда да табыла. Бер генә мисал: Урманчены 1973 елда СССР Рәссамнар академиясе мөхбир-әгъзалыкка кандидат итеп документлар тутырыла, хәтта теркәлә дә. Татарстан рәссамнар берлеге, скульптура секторы яхшы бәяләмәләр яза, иҗатчыларның башка юнәлешләре дә бу тәкъдимгә кушыла, Мәскәүгә Урманченың иҗатын хуплап хатлар җибәрелә. Яшерен-батырын түгел: Бакый үзе дә Мәскәүдәге дусларыннан ярдәм сорап хатлар юллый. Кызганыч, никадәр тырышсалар да, Бакый СССР Рәссамнар академиясенең мөхбир-әгъзасы дәрәҗәсен ала алмый кала. Беренче сәбәп, әлбәттә, рәссамның репрессияләр корбаны булуы, икенчедән, рәссамнар берлегенең кайбер әгъзалары белән каршылыгы. Шуны искәртик: Б.Урманче 1990 елның июнь аенда гына үзен репрессиядән аклаган беркетмәне кулына алу бәхетенә ирешә. Вафатына 2 ай калгач... Ул 60 ел дәвамында репрессияләр корбаны йөген ташый. Шуңа карамастан, табигатьтән бирелгән зур таланты, эшли алу сәләте, үҗәтлелек, алдына куйган максатларына ирешүдә, авырлыкларны җиңәргә, каршылыклар каршында сыгылып төшмәскә өйрәнүе, һәм әлбәттә, Аллаһының ярдәме белән бөек шәхес, Рәссам булып кала. Бакый Идрис улы татар сынлы сәнгатенең нигез ташын салучы беренче профессиональ рәссамы, татар сынлы сәнгате тарихында тәүге татар рәссамнары тәрбияләүче, сәнгатьтә яңа юнәлешләр барлыкка китерүче бөек зат.

Зөфәр МӨХӘММӘТШИН.

Татар океанында аның өлеше...

Сүзем каләмдәш дустым Габделәхәт Габделхәй улы Хәбибуллин турында. Габделәхәт абый белән танышу Түбән Кама районында Кызыл Чапчак авылы янәшәсендә урнашкан борынгы Болгар чоры шәһәрен казып тикшерү эшләре вакытында булды. Ул да әлеге шәһәрлек – Калатауның итәгендә урнашкан Түбән Чаллы авылында туып-үскән икән.

Казу эшләре барышы белән танышырга теләүчеләр күп иде. Килүчеләрнең күбесен Калатау итәгендә яшерелгән хәзинәнең табылу-табылмавы кызыксындырды. Араларында Габделәхәт абыйны беренче тапкыр күргәч, бу әле яңа гына киемен алыштырган генералдыр, дип уйлаган идем. Адымнары нык, сүзләре кыска, фикер йөреше саллы. Нәкъ армиядәге кебек беренче безнең яшәү: ашау, тору, эш шартлары белән танышты. Буш кул белән килмәгән иде, күчтәнәчләре белән сыйлады. Ярдәм кирәк булса, шалтыратыгыз, барысын да эшлибез дип, телефон номерын да калдырды. Шул ук вакытта: "Егетләр, болай булгач, мин дә авыл тарихын язам, сезнең ярдәмгә дә өмет тотам", – дип, безне үзе белән дә бәйләп тә куйды. Аннан качып котылып та булмады. Аның ярдәмендә беренче тапкыр Уфадагы архивны "сөреп" кайттык, аннан Мәскәүнекен. Габделәхәт абыйның тормыш тәҗрибәсе зур, сүзе үткен, сөйләшә белә. Кемгә бүләге, кемгә тәмле сүзе, кемгә кырыс, таләпчән кыяфәте белән тәэсир итә. Бар документларны китереп кенә торалар. Көне буе документларны күчереп утыручыларны көнләштереп, барын да сурәткә генә төшереп барабыз... Аның "Чал Калатаулы Түбән Чаллы" дип аталган туган авылының һәм аның тирә-ягын тәфсилләп бәян итүче документаль тарихы шулай туды...

Габделәхәт абый 1952 елның 9 маенда туган. Габделхәй абый белән Мөнирә апайның 12 нче баласы ул. Әмма төпчеге булса да, иркә-назда үсмәгән. Әле киресенчә, туганнары арасында бары аңа гына иң ерак илләрне гизеп, бар чит-ятларны күреп, дөньяның бар кырысларын татырга туры килмәде микән? Шул сәбәпле характеры да үзенчәлекле, нык аның. Яшьтән үк гаделлекне ярата, матурлыкка, иҗатка омтыла. Техникумда укый, аннан институтны тәмамлый. Алган белемнәренә таянып, үзен сынап карау рәвешендә, дөнья гизәсе килә. Шул сәбәпле, Находка шәһәрендәге балык тоту корабына эшкә урнашып, иксез-чиксез океанга чыга... Габделәхәт абыйның 8 елы диңгездә уза.

Ялтышар елга сузылган бу рейсларда узган тормыш, балык тотуга караганда аның өчен, үз дигәнчә яшәү өчен көрәш була. Җирдәге кебек монда да, башыңны исәң сыртыңа менәләр, сарык булсаң, тирә-якта бүреләр пәйда була. СССР дигән илдәге кебек, аның бер кыйпылчыгы булган бу корабта да телсез, динсез калдырып, кем икәнлегеңне оныттыру өчен бары да каралган. Бар җирдәге кебек монда да партия секретарьлары, телен оныткан милләттәшләр, кулыннан эш килмәсә дә үзен әллә кемгә куярга тырышучы "старший брат" вәкилләре, инде телсез булса да рухын саклап калырга тырышучылар бар... Ул да яшәү, кеше булып калыр өчен көрәшкә кузгала...

Габделәхәт абый Җир шарының ике котыбында да булып, дөньясының читен дә барып караган. Сингапуры, Америкасы, Канадасы да калмаган. Яңа Зеландия, Фиджи, Япун утрауларында да татарның эзен калдырган. Эзен генәме, ул анда күргән-белгәннәрен, бар кичерешләрен дә милли телдә, милли калыпка салган. Шулардан безләргә гыйбрәт булырлык итеп "Ялгыш язмышлар" дигән 336 битле роман-хатирә язып бүләк иткән. Роман-хатирәсе "Ялгыш язмышлар" дип аталса да, аның төп герое Булатны мин ялгыш яшәгән, димәс идем. Әйе, ул коммунизм хыялы белән агулаган чорда яши. Әмма бүгенгеләрдән күпкә аңлырак, үз заманына күрә күпкә акыллырак, алгы карашлы зат буларак кабул ителә. Ничек яшәсәң генә кеше булып калырга мөмкин булу юлын күрсәтә. Булатның тормышы, яшәеш гамәлләре бүген дә күпләргә сабак та, мәнә дигән үрнәк тә булырлык. Бу роман герое Булатның – Габделәхәт абыйның үзе икәнлеген күрү кыен түгел. Булатның бар сыйфатлары Габделәхәт абыйның яшәешендә чагыла. Милли җанлы, гаделсезлеккә аяусыз, горур ул. Бүгенге көндә "Ялгыш язмышлар"-ның дәвамы "Миһербанлы юл" дигән хезмәте дә әзер. Китапның урыс телендәге тәрҗемәсе дә дөньяга чыгарга үз чиратын көтеп ята... Бу китапларда татарлык, милли рух язманың башыннан ахырынача тантана итә. Шушы юнәлештәге "Бөтен дөньяга бер юл" дип аталган фәлсәфи-уйлану юнәлешендәге китабы да 2021 елда дөнья күрде. Ул шигърият өлкәсендә дә уңышлы иҗат итә. Аның: "Дөнья халкы уян, уйла" (2018); "Ул океаннарны берләштергән" (2021); "Әдрән диңгез" (2022) исемле китаплары шундыйлардан. Габделәхәт абый әлеге хезмәтләре өчен Р.Төхфәтуллин, С. Сөләйманова исемендәге бүләкләргә лаек булды.

Габделәхәт абый кешеләр күңелендә әсәрләре белән генә түгел, тормышта кылган игелекле эшләре белән дә кереп калды. Ярдәм кирәк кешене тоемлап, һәрчак булышырга ашыга. Аның саваплы эшләре күп, шулай да аның кешелеклеген күрсәтүче бер гамәлен искә алып узуны кирәк. Барыбызга да таныш Шамил абый Бикчуринның кабере, вафатыннан соң, бер еллап ташсыз ята. Ул еш кына кабеpенә барып, аны искә ала. Аннан үз акчасына истәлек ташы куйдыра. Дәвамлы дуслык, хөрмәт белән караган кешегә мөнәсәбәт, үзе үлгәннән соң да шундый була ул.

Габделәхәт абый бүгенге көндә Әлмәт шәһәрендә яши. Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы буларак шәһәр тормышында да актив эшчәнлек алып бара. Аңа 9 майда 70 яшь тула. Габделәхәт абыйның үткәннәре үкенерлек түгел. Бу заманда татар булып туып, яшәп, татар булып кала алу да зур батырлык.

Нурулла ГАРИФ,
язучы, тарих фәннәре кандидаты.

Дөньяга бер юл

(Өзек)

Күпме кеше җир йөзендә,
Җир-әнкәне уртак өй, диләр.
Уртак өйдә, уртак һава сулап,
Бер туфракка басып йөриләр.

Адәм белән Һава тарафыннан
Яратылган җаннар инде без.
Бер Аллага юкса табынабыз,
Ә нигә соң төрле динебез?

Ә нигә соң төрле динебез дә,
Төрле-төрле сөйләр телебез!
Уртак өйдә уртак тел дә булса,
Тату яшәр идек үзебез.

Бер үк телдә дөрес уйлар белән
Гомер итсәк уртак фикердә,
Сугышларсыз, ызгышларсыз яшәү
Мөмкин булыр иде бу җирдә.

Ул вакытта кирәк булмас иде
Солдатлар да, генераллар да,
Күпме байлык янга калыр иде
Эш коралы гына булганда.

Фани дөнья җәннәт булыр иде
Бер үк дингә халык табынса.
Акыллылар гадел сайлап куйган
Хак хаким дөньяга баш булса.

Г. ХӘБИБУЛЛИН.

Айга кырын карама

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

7 май (шимбә). ***Шәүвәл аеның 6 нчы көне. 8 нче Ай тәүлеге. Ай Арыслан йолдызлыгында, 7.43 сәгатьтә калка, 1.58 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 15.46 сәгать.***

Бүген бигрәк тә ут белән эш иткәндә саклык сорала. Ризык җиңел үзләштерелүчән булырга тиеш. Ашказаны, бизләр системасы зәгыйфь, невралгия һәм стенокардияне кисәтү чаралары уңай нәтиҗә бирә. Колак авыртырга мөмкин. Бу атнада күзне саклау мөһим.

Прополис сихәте

Кан тамырларын "начар" холестериннан чистарту өчен, көненә 3 тапкыр, ашарга 30 минут кала, 30 мл суга 7 тамчы 4 процентлы прополис төнәтмәсе салып эчәргә кирәк. Дәва курсы – 4 ай.

8 май (якшәмбе). ***Шәүвәл аеның 7 нче көне. 9 нчы Ай тәүлеге. Ай Арыслан йолдызлыгында,8.57 сәгатьтә калка, 2.17 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 15.50 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн, алдашу, ялганга бай. Хәтта сыйфатлы ризык белән дә агулану ихтималы бар. Күп аралашу хупланмый. Фикерләрне тупларга, үзегезне үпкәләткән кешеләрне кичерергә кирәк. Үпкә, ашказаны зәгыйфь. Кан басымы күтәрелергә, йөрәк, арка яки баш авыртырга мөмкин. Мунча керү файдалы.

Йөрәккә дәва

200 әр г йөзем, кара җимеш, курәгә, әстерхан чикләвеген һәм 3лимонны иттарткычтан чыгаралар, 250 г бал, даруханәдән алынган 1 әр шешә гөлҗимеш ширбәте һәм дүләнә төнәтмәсе кушып, яхшылап болгаталар да, карасу төстәге пыяла банкага салып, 10 тәүлеккә суыткычка куялар. Аннары көн саен ач карынга 1 әр аш кашыгы кабалар. Елына 2 тапкыр шулай дәвалану гипертония, ишемия, атеросклероз кебек авырулардан саклый.

9 май (дүшәмбе). ***Шәүвәл аеның 8 нче көне. 10 нчы Ай тәүлеге. Ай Арыслан йолдызлыгында,10.17 сәгатьтә калка, 2.30 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 15.54 сәгать.***

Нәсел, гаилә, гореф-гадәтләр белән бәйле көн. Ял итү, йокы туйдыру, гаиләне ныгыту өчен иң шәп вакыт. Әйләнә-тирәдәгеләргә игътибарлырак булу сорала. Сизү әгъзалары, йөрәк-кан тамырлары системасы, сөякләр зәгыйфь. Ач тору файдалы.

Арка авыртканда

Буыннар, бил, арка авыртканда, яртышар чәй кашыгы каен һәм нарат җиләкләре яфрагын 1 стакан суда 2-3 минут кайнаталар, 30 минут төнәткәч, сөзәләр, көн буена әкренләп эчеп бетерәләр.

10 май (сишәмбе). ***Шәүвәл аеның 9 нчы көне. 11 нче Ай тәүлеге. Ай Кыз йолдызлыгында,11.38 сәгатьтә калка, 2.41 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 15.58 сәгать.***

Үзгәрү, сафлык, катгыйлык көне. Һәр эштә дә сак һәм игътибарлы булу сорала. Башланган эшне ахырына җиткерергә кирәк. Бу көннең энергетик куәте бик

(Дәвамы 18 нче биттә).

зур, кешедә искиткеч табигый көч уянырга мөмкин. Арып-талганчы эшләргә ярамый. Сизү әгъзалары, йөрәк, умырткалык, үпкә зәгыйфь.

11 май (чәршәмбе). ***Шәүвәл аеның 10 нчы көне. 12 нче Ай тәүлеге. Ай Кыз йолдызлыгында,13.00 сәгатьтә калка, 2.49 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 16.02 сәгать.***

Шәфкать, сабырлык, мәхәббәт энергиясенә бай көн. Сәламәтлеккә игътибарлы булырга, йөрәккә киеренкелек китермәскә кирәк. Ашкайнату әгъзалары, кан әйләнеше системасы зәгыйфь. Дарулар яхшы үзләштерелә.

Канны чистарту

Канны агулы матдәләрдән чистарту өчен, 3 атна буе мүк җиләге согы эчәргә кирәк. Беренче атнада – көненә 3 тапкыр, ашаганда, яртышар стакан; икенче атнада – көненә 2 тапкыр, өченче атнада – көненә 1 тапкыр яртышар стакан эчәләр. Яисә 400 г сарымсакны иттарткычтан чыгаралар, 800 мл лимон согы кушалар да, суыткычта саклыйлар. Көненә 1 тапкыр, ашаганда, 1 чәй кашыгы төнәтмәне 1 стакан суга кушып эчәләр. Әмма ашкайнату һәм бәвел бүлеп чыгару системалары авыруларыннан интеккән кешегә болай дәваланырга ярамый.

12 май (пәнҗешәмбе). ***Шәүвәл аеның 11 нче көне. 13 нче Ай тәүлеге. Ай Үлчәү йолдызлыгында, 14.24 сәгатьтә калка, 2.58 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 16.06 сәгать.***

Үзгәрешләр көне. Үткәннәр турында уйланып, нәтиҗәләр ясау яхшы. Ач торырга ярамый – теләсә нәрсә ашарга була. Аралашу, белем алу өчен уңай вакыт. Йөрәк, тире, кан тамырлары зәгыйфь. Чикләвек ашау файдалы.

Варикоздан – алма

Кан тамырлары варикоз киңәйгәндә, уртача зурлыктагы өч алманы эмальләнгән кәстрүлдәге 1 литр кайнар суга салып, яхшылап томалап, жылы урында дүрт сәгать төнәтәләр. Аннары алмаларны суда килеш төяләр дә, сөзәләр. Иртән ач карынга һәм кичке аштан соң ике сәгать үткәч, 50 мл алма төнәтмәсен 1 чәй кашыгы бал белән эчәләр.

13 май (җомга). ***Шәүвәл аеның 12 нче көне. 14 нче Ай тәүлеге. Ай Үлчәү йолдызлыгында,15.50 сәгатьтә калка, 3.06 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 16.10 сәгать.***

Иң әһәмиятле эшкә тотыну өчен уңайлы көн. Бүген башланган эш бик яхшы тәмамланачак. Теләсә нинди вак-төяккә игътибарлы булу сорала. Эчәклек һәм тирене чистарту уңай нәтиҗә бирә. Ашказаны асты бизе зәгыйфь. Балан, фасоль, борчак, арпа ашау файдалы.

Алма бәлеше

1 әр стакан он, манный, шикәр, 1300 г алма, 100 г атланмай, 1 чәй кашыгы камыркопшәкләндергеч, ванилин кирәк. Он, шикәр, манный, камыркөпшәкләндергечне кушып болгаталар, алмаларның кабыгын чистартып, эре угычтан уалар. Табаны майлап, 1 стакан коры камырны, өстенә алманың өчтән берен җәяләр. Аннары тагын 1 стакан камырны, өстенә алманы, аннары тагын камыр, тагын алма җәяләр дә, ванилин сибеп, өстенә туңган атланмайны эре угычтан уалар.180 градуслы газ мичендә 45 минут пешерәләр. Суынгач кына кисәргә кирәк.

«Кайбыч колхозчысы» Берлин өстендә

Бөек Ватан сугышы чорында илдә заем системасы кертелә. Акчаң бармы-юкмы дип сорап тормыйлар. Бик күп кешенең акчасы булмый, билгеле. Аларга хәтта йорт кирәк-яракларын сатарга туры килә.

Кайбыч районы колхозчылары заем акчасына конструктор Владимир Петляковның Пе-8 бомбардировщигы төзелә. Кирәкле күләмдә акча җыелгач, аны ничек тәзү турында баш ваталар. Эшне җиңеләйтү өчен, Сталинга хат язарга булалар. 1944 елның 24 февралендә СССР Оборонасы дәүләт комитеты рәисенә андый хат җибәрелә дә.

"Хөрмәтлебез Иосиф Виссарионович! Кызыл Армиянең гүзәл җиңүләре белән рухланып, немец илбасарларын тизрәк тар-мар итү өчен, фронтка барлык көчләре белән ярдәм итү максатыннан, Татарстан АССРның Кайбыч районы колхозчылары Кызыл Армиянең җиңү фонды өчен 1 миллион 300 мең сум акча җыйдылар.

Сездән җыелган акчага "Кайбыч колхозчысы" исемле авыр бомбардировщик төзүне һәм аны гвардия частена тапшыруыгызны сорыйбыз.

ВКП(б) Кайбыч райкомы секретаре Гатин, район башкарма комитеты рәисе Закиров".

Тиздән Мәскәүдән җавап та килә. Сталин телеграммасында Кайбыч районы колхозчыларына Кызыл Армиянең сәламе һәм рәхмәте җиткерелә. Акчаның максатчан файдаланачагына бернинди шик калмый.

Казанның 22 нче заводы заказны өч ай дәвамында үти. Куәтле хәрби самолет 20 миллиметрлы пушкалар һәм 12,7 миллиметрлы авыр пулеметлар белән җиһазландырыла, иң авыр бомбаларны да йөртә ала. Дүрт моторлы "Кайбыч колхозчысы" авыр бомбардировщигының завод номеры 42212 була, ул 2 нче һава армиясе 8 нче авиация корпусы 45 нче авиадивизиясенең 25 нче полкына тапшырыла. Машинаны эскадрилья командиры урынбасары, гвардия майоры Василий Обухов кабул итеп ала. Казан заводында самолетны тантаналы төстә тапшыру 1944 елның маенда башкарыла. Кайбыч районыннан тантанада өч кеше – Яковлев, Фәизов һәм Хәйруллин катнаша.

Василий Обухов Кайбыч колхозчыларына хат яза. Аның тексты мондый була:

"Кадерле иптәшләр!

Авыр сугыш чорында сез үзегез җыйган акчага куәтле канатлы машина төзедегез.

Сезнең патриотизм, бөтен көчегезне куйган хезмәтегез, Кызыл Армияне чын күңелдән яратуыгыз безне хәрби җиңүләргә рухландыра.

Бүгенге көн безнең гвардия часте өчен бигрәк тә шатлыклы. Сезнең вәкилләрегез белән бергә командирыбыз Татарстан Республикасы Кайбыч районы колхозчылары бүләгән – куәтле бомбардировщикны тапшырды.

Әлеге гүзәл бүләкне кабул итеп, гвардия экипажы Кайбыч районы колхозчыларына аларның хәрби самолет төзүгә акчаларын сарыф итүләре өчен чын күңелдән рәхмәтен белдерә. Экипаж гвардия частенең башка оешмалары белән бергә, намусын, осталыгын, батырлыгын эшкә җигеп, ерткыч фашистларны, безнең илгә ташланган талаучыларны һич тә кызганмыйча юк итәчәк. Фашистлар җил туздырдылар, давылны үзләре җыярлар..."

Василий Обухов "Кайбыч колхозчысы" бомбардировщигында 156 хәрби очыш ясый, Варшаваны, Бухарестны, Берлинны штурмлауда катнаша. Советлар Союзы Герое исеменә лаек була. Җиңү көненә кадәр бары өч көнә көн яши алмый, автомобиль дә юл һәлакәтендә гомере өзелә.

Кайбыч районында Бөек Ватан сугышына багышланган сугыш даны мемориалын яңартырга, бөек урынга Пе-8 "Кайбыч колхозчысы" самолеты макетын урнаштырырга булалар. Легендар очкыч макетын җиңел һәм озакка чыдам материаллардан Казанның бер предприятиесе эшләргә алына. Макет самолетка максималь туры килсен өчен, архив фотолары, сакланып калган техник документлар кулланыла.

Сугыш елларында Казан предприятиеләрендә хатын-кызлар һәм үсмерләр аена 350 гә кадәр төнге бомбардировщиклар җыя. Бүген ул самолетларның бары берсе генә Татарстан Милли музее складында сакланып калган. У-2 (Пе-8) бомбардировщигын реставрацияләүгә акча таба алмыйлар икән. Бу очкычлар Бөек Ватан сугышы турында калын-калын китапларга караганда да күбрәк мәгълүматлар бирә ала югыйсә. Уникаль самолетны бөтенләй югалтырга хакыбыз юк.

Әгъзам ФӘЙЗРАХМАНОВ.

Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

6 май – «Килә ява, килә ява...» (З.Хәким).
7 май – «Җанкисәккәем» (Т.Миңнуллин).
8 май – «Килмешәк» (С.Гаффарова).
12 май – М.Ю.Лермонтов исемендәге дәүләт Рус драма театрының «Волки» спектакле (М.Әхмәдов).
13 май – «Мәхәббәт FM» (И.Зәйниев).

М.ҖӘЛИЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ҺӘМ БАЛЕТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

13-31 май – Р.Нуриев исемендәге XXXV халыкара классик балет фестивале
13 май – «Щелкунчик» (П.Чайковский).

К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ

6 май – «Алай түгел, болай ул» (Т.Миңнуллин).
7 май – «Кияү урлау» (С.Юзеев әсәре, Х.Ибраһим тәрҗемәсе).
8 май – «Хыялый» (С.Әбүзәров).

Г.КАРИЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ЯШЬ ТАМАШАЧЫ ТЕАТРЫ

6 май – 13.00 – «Минем бәхетле көнем» (Е. Гороховская). 18.30 – «Корт» (Ф.Галиев).
7 май – «Мәхәббәт күгәрченнәре» (В.Гуркин).
8 май – Язгы концерт. Хәтер...
11 май – «Хикмәт әкиятләре» (Н.Хикмәт, В.Тулякова),
12 май – «Ак чәчәкләр кебек...» (В.Мухина).
13 май – «Камыр батыр» (А.Житковский инсценировкасы).

«ӘКИЯТ» ТАТАР ДӘҮЛӘТ КУРЧАК ТЕАТРЫ

6 май – 11.00 – «Страна чудес Алисы» (Л.Кэрролл әсәренә нигезләнеп куелган). 19.00 – «Shurale: яңа фантазия» (Ф.Яруллин).
7 май – зур залда – «Волк и семеро козлят» (Э.Гыйлемханова инсценировкасы). Кече залда – «Әрә белмәгән көчек» (Р.Мөхәммәтша).
8 май – Зур залда – «Волшебник Изумрудного города» (А.Волков). Кече залда – «Самовары» (Р.Таһиров).
9 май – Зур залда – «Приключения Барона Мюнхгаузена» (Р.Э.Распе). Фойеда – «Не хочу, не буду» (П.Геннадьева).
10 май – Фойеда – «Один день из жизни улитки» (Ольга һәм Юрий Устюговлар). Зур залда – «Сказка о царе Салтане» (А.Пушкин, Л.Кожевников инсценировкасы). Кече залда – «И, кызык Шүрәле!...» (Г.Зәйнашева).
12 май – Түбән Новгород дәүләт курчак театрының «Иван Царевич и серый волк» спектакле (В.Маслов).
13 май – Түбән Новгород дәүләт курчак театрының «Конек-горбунок» спектакле (П.Ершов).

Г.ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ФИЛАРМОНИЯСЕНЕҢ КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

12 май – Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты А.Фәйзрахманов җитәкчелегендәге фольклор музыкасы дәүләт ансамбле башкаруында «Хәрәкәттә-бәрәкәт» дип исемләнгән концерт. Программада – дәртле татар биюләре, моңлы халык җырлары, инструменталь әсәрләр.

С.СӘЙДӘШЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ЗУР КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

11 май – «Звезды из завтра» концерт марафонының йомгагы. Республикабыз музыка һәм сәнгать мәктәпләрендә белем алучы елның иң шәп скрипкачы, пианистлары, җырчылар, халык музыка уен коралларында көй башкаручылар маэстро Рөстәм Абязов җитәкчелегендәге «La Primavera» камера оркестрына кушылып чыгыш ясый.

«БӘКЕР» – сугыш чорында

Сугыш чорында «Бәкер» шифаханәсе базасында оештырылган 49-14 нче эвакуация госпиталендә бер генә авыру да үлми. Гаҗәп, әмма факт! Моны коллективның тырышлыгы, һөнәри осталыгы дип бәяләргә кирәк. Яралануччыларның 70 проценты биредә дәваланганнан соң, кабат фронтка китә.

Бөек Ватан сугышы чорында Бәкердә 14 меңнән артык хәрби хезмәткәр яраларын дәвалый. Аларның яралары җиңел булмый. Билләре, тезләре имгәнүчеләр күп. Яралыларның күпчелеге биргә турыдан-туры санитар авиация белән китерелә. Яралыларның кайберләрен санитария поездларында Шонтала, Бөгелмә станцияләренә алып киләләр. Аларны Бәкергә атларда ташыйлар.

Шифаханә базасында эвакуация госпитале 1942 елның җәендә эшли башлый. Бер елга якын санаторий корпуслары, дәвалау базасы кулланылмый. 1941 елның 26 июнендә үк биредә эшләүче табибләрне һәм шәфкать туташларын Казанга чакырып алалар. Күбесе турыдан-туры фронтка җибәрелә.

Сугыш башланып бер атна үтүгә, санаторийны ябу турында приказ бирелә. Бәкердә бары каравылчылар, ярдәмче хуҗалык, кухня хезмәткәрләре генә кала. Алар утын, печән әзерли, терлекләрне карый һәм берәм-берәм фронтка җибәрелә.

Беренче булып сугышка каравылчы Я.Плотников озатыла. Аннан соң хуҗалык бүлеге мөдире Вәли Борһанов китә. 30 августта ватанны сакларга директор Старковны да җибәрәләр. Ул биредәге вазифаларын урынбасары Фазыл Әхмәровка тапшыра. Тиздән аны да һәм йөк ташучы З.Җаббаровны да сугышка алалар. Вакытлыча директор итеп билгеләнгән Зарипов та тиздән китеп бара.

1942 елның маенда санаторий базасында 49-14 нче эвакуация госпитале оештырыла. Моңа кадәр бөтен биналар ремонтлана, территориядә газоннар булдырыла, чәчәкләр утыртыла. Җәй көне биргә каты яралыларны китерә башлыйлар, күбесен носилкаларда алып киләләр. Башта авыруларны санитар егетләр карый, аннары алар да фронтка китә. Егетләрне 14-15 яшьлек кызлар алмаштыра. Яралыларга шифалы су, измә (грязь) белән ярдәм күрсәтәләр.

Эвакуация госпитале директоры вазифасын башта К.Җиһангиров башкара. Аны сәламәтлек саклау комиссариаты эшкә җибәргән була. 1943 елның августында аны Е.Бельтер алмаштыра. Кырыс, бик таләпчән җитәкче була ул. Яңа директор килгәч, госпиталь азык-төлек белән өзлексез тәэмин ителә. Бәкергә 2-3 табиб гадәттә 10-15 көнгә килеп эшли.

1944 елның 22 мартында эвакуация госпитале белән Павел Комендантский җитәкчелек итә башлый. Ул таләпчән генә түгел, бик гадел дә җитәкче була. Комендантский эшләгәндә, коллектив күрше-тирә авыл халкына да даими ярдәм итеп тора.

Биредә тагын бер бик күренекле шәхес – табиб-хирург Н.Земляницин була. Ул берүзе еш кына алтмышлап яралыны дәвалый. Аның белән шәфкать туташлары В.Юртаева һәм Ф.Нерух даими эшлиләр. Бу вакытта госпитальдә эшләүчеләрнең күпчелеге илнең башка төбәкләреннән эвакуацияләнеп килгән кешеләр була.

Сугыш еллары дәвамында санаторий хуҗалыгы нык искерә. Ремонт өчен вакыт җитми, төзү материаллары да булмый. Атлар да калмый диярлек. Һәрнәрсәне җилкәләргә салып ташырга туры килә. Гадәттән тыш киеренкелек хезмәт ветераны Павел Комендантский сәламәтлегенә дә йогынты ясый. Ул каты авырый башлый. Аның урынына Хаҗип Фәсхетдинов билгеләнә. 1928 елда ул Бәкер шифаханәсенә гади эшче булырак кабул ителгән була.

1945 елда госпитальнең баш табибе булып күренекле татар язучысы Гадел Кутуйның хатыны А.Кутуева да эшләп ала. Әмма иренең фронтта һәлак булуы турында хәбәр алгач, ул Казанга кайтып китә. Аны табиб хирург Фәридә Килмәтова алмаштыра. Ул институтның соңгы курсы имтиханнарын вакытыннан алда тапшырып, 1941 елда сугышка киткән була. Дүрт ел дәвамында Фәридә операция өстәле янында хезмәт куеп, бик күп сугышчыларның гомерен саклап кала.

Бәкердә Килмәтова үзен яхшы табиб итеп кенә түгел, талантлы оештыручы буларак та таныта. Санаторий музеенда Фәридә Килмәтова турында истәлекләрне кадерләп саклыйлар. Коллективның ничек яшәве, эшләве турында аның истәлекләрен язып калган булганнар. Музей мөдире Гөлсия Сәримова шифаханә хезмәткәрләренең биографияләрен, бүләкләрен, шәхси әйберләрен, фронт хатларын туплаган.

Бер-бер артлы исән калган хезмәткәрләр сугыштан кайта башлый. Фазыл Әхмәров, биргә кайтып, озак еллар хуҗалык бүлеге мөдире булып эшли. Икътисадчы Әхмәтов, сугыштан кайткач, үз участогында тәртип урнаштыра.

Җиңүнең 65 еллыгына биредә мемориаль такталар ачыла. Аларның берсе – шифаханәнең сугыштан кайтмаган хезмәткәрләренә, икенчесе меңнәрчә яралы сугышчыларны тормышка кайтарган 49-14 нче эвакуация госпиталендә эшләүчеләргә багышланган. Бөек Җиңүнең 70 еллыгы уңаеннан биредә һәйкәл ачыла. Ул халык азатлыгы өчен гомерләрен корбан итүчеләр һәм Бәкердә яралыларны дәвалап аякка бастыручылар хөрмәтенә торгызылган.

Әгъзам ФӘЙЗРАХМАНОВ.

Сугыш михнәте кичкән Казан әдипләре

● Күргәзмәне оештыручы Галина Зәйнуллина.



● Тихон Журавлев. ● Мәҗит Рәфыйков. ● Геннадий Паушкин. ● Риза Ишморат. ● Аркадий Мельников.

Татарстан Язучылар берлеге фронтовик язучыларның әсәрләрен цифрлы форматка күчерү өчен грант откан иде һәм бүген бу эшне президент каршындагы Мәдәни башлангычлар фондының ярдәме белән тормышка ашырып килә. Уналты язучының ун мең бит әсәре цифрга күчерелергә тиеш булса, бүген бу эшнең яртысы башкарылган. Моның өчен сканер, бүтән кирәк-яраклар сатып алынган. Язучылар берлеге китапханәсеннән фронтовик әдипләрнең әсәрләрен эзләгәндә бүтән кызыклы китаплар барлыгы ачыкланган. Бүген Язучылар берлеге бинасында оештырылган күргәзмәдә фронтовик язучыларның әдәби мирасы һәм 1930-1950 елларда нәшер ителгән китаплар белән танышырга мөмкин.

Сирәк китаплар күргәзмәсендә беренчеләрдән булып каһарман шагыйрь Муса Җәлилнең 1944 елда Татар китап нәшриятында бастырылган шигырь китабы җәлеп итә. Китапта Җәлилнең икенче удар армиядә әсирлеккә эләккәнчегә кадәр язып өлгергән шигырьләре тупланган. Аларны туплаучы һәм кереш мәкалә авторы – үзебезнең Бруно Зернит. Безнең илдә хәбәрсез югалганнарга һәм бигрәк тә әсирлеккә эләккәннәргә карата дәүләт сәясәте яхшы билгеле. Җәлил 1942 елда әсирлеккә төшә. Ике елдан соң шигырьләренең басылып чыгуы могҗиза түгелмени?

Җәлилгә кагылышлы тагын бер китап кызыклы. Анда 1939 елда Виктор Тарбеев исемле шагыйрьнең шигырьләре басылган. Урал якларындагы сәүдәгәрләр нәселеннән чыккан Виктор ата-бабасы турында мәгълүматны яшерергә мәҗбүр була, әнисенең фамилиясен алып, бер шәһәрдән икенчесенә күченеп йөри. Шулай итеп, ул Казаныбызга да килеп чыккан, бу Җәлилнең Язучылар берлеген җитәкләгән кыска гына вакытка туры килгән, күрәсең. Китапның Җәлил ярдәме белән нәшер ителүе язылган. Язучылар берлегенең рус секциясе җитәкчесе Г.Зәйнуллина Тарбеевнең фронт тормышын да ачыклаган. Баксаң, Тарбеев фронтта үз-үзен аямыйча сугышып кына калмаган, сугышчыларны җиңүгә илһамландырырлык шигырьләр дә иҗат иткән. Җәлилнең сизгер күңеле сәүдәгәр нәселле Викторның батырлыгын гүя алдан тойган. Юкса китабын бастыру өчен тырышып йөрер идемени?

● Дөрҗия Аппакова һәм татар язучыларының тәрҗемә китаплары.

Сирәк китапларның шактый өлешендә язучыларыбызның култамгалары сакланган. Шундый китапларның берсендә шагыйрь Хәсән Туфан кулы. Ул үзенең 1958 елда русчага тәрҗемә ителеп нәшер ителгән шигырьләр китабына «Туганымдай сөекле Геннадийга», дип язган. Ул вакытта Геннадий Паушкин Язучылар берлегендә рус секциясен җитәкли. Туфанның сөргеннән кайтып, реабилитацияләнгән генә чагы. Шул вакытта Мәскәүдә шигырьләрен русчага тәрҗемә итеп бастырсыннан өчен шактый тырышырга кирәк булган, әлбәттә. Паушкин бу эшне үз өстенә алган. Шагыйрьнең Г.Паушкинны ни өчен туганнардай газиз, сөекле күрүе аңлашыла хәзер.

Г.Паушкинның «Возвращение» дип исемләнгән шигырьләр китабы онытылмаслык тәэсирләр калдыра. Бу шигырьләрне ул Севастопольне яклап сугышканда окопта иҗат итә, әмма югалта. Берничә дистә елдан соң сугыш чорын өйрәнүче эзтабарлар шигырь дәфтәрен таба. Авторны эзли башлый һәм Казаныбызда табып, шигырьләрне үзенә юллый. Алар китап булып 2004 елда Татарстан китап нәшриятында басылып чыга.

Г.Паушкин белән бергә 1950-1960 елларда рус секциясен җитәкләгән Тихон Журавлев үз әсәрләрендә гап-гади солдатларны сурәтли. Аның «Рядовой Антипов» китабында да нәкъ шундый гап-гади сугышчының үз-үзен аямыйча көрәшүе тасвирлана. Әмма Журавлевны Лев Толстойның героен, тәгаенрәк әйтсәк, Платон Каратаевны кабатлап язуда гаепләпиләр. Язучыны Шолохов яклап чыга.

Мәҗит Рәфыйковның язмышы тетрәнерлек. Ул татар язучыларының әсәрләрен русчага тәрҗемә итүче буларак танылa. Бигрәк тә олуг шагыйребез Г.Тукайның прозасын тәрҗемә итеп яхшы ат ала. Әмма аңа кадәр язмыш аны шактый кыйный. 18 яшендә Бөек Ватан сугышына киткәч, анда ике тапкыр яраланып, инвалид булып кайтуы гына җитмәгән, көннәрдән бер көнне фронтовикка «халык дошманы» дигән нахак сүзне күтәрергә туры килә. Сугыштан кайткач, ул дәүләт университетының рус филологиясе факультетына укырга керә. Туган ягы Башкортстанда үткән балалык елларыннан алып авыл мәктәбендә укыткан әтисе Мәҗиткә рус телендә белем алуның кирәклеген сеңдергән була. Университетта укыган вакытта әдәби түгәрәк утырышларының берсендә берәр ярамаган сүз әйткән булса кирәк, М.Рәфыйковны сорау алуларга йөртеп интектергәннән соң, ахыр чиктә сөргенгә җибәрәләр. Сугыш батыры, гарипләнгән фронтовик булуына да карамастан, ул 1956 елга кадәр читтә интегеп гомер кичерергә мәҗбүр була. Кайткач исә, университетны читтән торып тәмамлый, татар теле буенча диссертация яклый һәм җиң сызганып тәрҗемә эшенә керешә. Шундый зур михнәтләр кичкән Мәҗит Рәфыйков нибары 61 яшендә бакыйлыкка күчә.

Рус язучыларына багышланган бүлектә Ян Винецкий исеме кадерле. Ул сугыш, Татарстан нефтьчеләре, Пушкин, Горький, Владимир Ульянов, Мәгубә Сыртланова турында әсәрләр калдырган. Әмма Винецкийның иң зур хезмәте – Михаил Девятаевның каһарманлыгын мәңгеләштерү. 1950 еллар уртасына кадәр Девятаев берәүгә дә билгеле булмыйча, авыр шартларда гомер кичерә. Берәү белән дә очрашмый диярлек. Винецкийны да очучы булганы өчен генә үзендә кабул итәргә ризалаша. Шуннан Ян Винецкий матбугатта зур мәкалә бастырып чыгара. Девятаевны шуннан соң гына таный башлыйлар.

Рәмзи Илялов – үзе бер гыйбрәт. Ул да Бөек Ватан сугышында катнаша, очучы була. Әмма иң зур батырлыгын сугыш тәмамлангач кыла. 1968 елда укытучылар газетасында мәкаләләр язып, матур гына яшәп ятканда, совет гаскәрләренең Чехословакиягә бәреп керүенә каршы чыкканы өчен, аны Язучылар берлегеннән чыгаралар. 1980 елларда гына тормышы бераз җайлана. Рәмзи Илялов безгә нәселле атлар үрчетүче Җәүдәт Ибраһимов һәм Россиядә беренче бокс буенча чемпион Нури Алимов турында документаль повестьлар язып калдыра.

Штрафбат турындагы «Люди в кирасах» әсәре 1960 еллардагы җепшеклек вакытында нәшер ителергә тиеш булса да, сәяси вәзгыять үзгәрү сәбәпле, китабын 1990 елда гына кулына алу бәхетенә ирешкән язучы Игорь Толстой тарихы гыйбрәт түгелмени?

Сергей Ефремов Казаныбызда тумаса да, язмышы Татарстаныбыз белән тыгыз бәйләнгән, чөнки Бөек Ватан сугышы елларында әсирлеккә эләгеп, ике концлагерьда, шул исәптән Бухенвальдта интегеп исән калганнан соң, эре шәһәрләрдә гомер кичерү хокукыннан мәхрүм ителгән кеше буларак, ул Алабугага яшәргә килә, биредә туку фабрикасында электрик булып эшләгән язучыны Г.Паушкин күреп, үз канаты астына ала. Аны Язучылар берлегенә кабул итәләр. «Колокол Бухенвальда» һәм «Севастопольская тетрадь» исемле китаплары басылып чыга. Концлагерьлар үтеп исән калган язучының 1965 елда юлны кыскартырга теләп тирән чокыр аша үткәндә суда батып үлүе бигрәк аяныч.

Сугыш еллары булса да, союздаш республика шагыйрь-язучыларының рус теленә күпләп тәрҗемә ителгәне шушы күргәзмәдә дә яхшы күренә. Төркмән, әзәрбайҗан, кыргыз, казах, яһүд һәм иң күп тәрҗемә ителгән грузин авторларының китаплары арасында безнең Ә.Ерикәй белән Ә.Фәйзи дә бар.

Сирәк китаплар арасында бер киштәдә исә Язучылар берлеге каршында 1947-1958 елларда чыгып килгән «Литературный Татарстан» альманахы игътибарга лаек. Анда татар язучыларының русчага тәрҗемә ителгән әсәрләре, рус әдипләренең әсәрләре, әдәби тәнкыйть, туган якны өйрәнеп язылган материаллардан тыш, фольклор язмалар да күп. Элек Язучылар берлегендә фольклор бүлегенең эшләвен күпләр белмидер дә әле. «Литературный Татарстан»ны «Литературная Казань» альманахы алмаштыра.

Галимә Галина Зәйнуллинаның, күргәзмәне эшләгәндә, Казанның фронтовик язучылары, 1930-1950 еллардагы әдәби тормыш турында бай мәгълүмат туплавы мактауга лаек. Татарстаннан сугышта катнашкан әдипләрнең әсәрләрен интернеттан республиканың язучылар берлеге сайтында «Үлемсез әдәби полк» бүлегендә укырга мөмкин.

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

Дүшәмбе

9 май

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
6.00 «Без - кырык беренче ел балалары». 12+
7.00, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
7.10 «Сугыш чоры җырлары». 6+
8.00, 14.30, 19.01, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «В ДВУХ ШАГАХ ОТ «РАЯ».
9.45 Торжественное шествие войск Казанского гарнизона, посвящённое 77-ой годовщине Великой Победы.
11.00, 17.00 «Батырларга хат». 6+
12.00 «Габдрахман». 12+
13.00, 16.00 «Йөрәкләрдә һаман ут яна...» 6+
14.45, 22.05 «Бессмертный полк -2022».
16.30 «Татарлар». 12+
18.00, 0.30, 0.55 «Соотечественники». 12+
18.55 «Светлой памяти павших в борьбе против фашизма. Минута молчания».
19.30, 21.00 Праздничный концерт.
22.00 Праздничный салют.
23.00 «ТЕНЬ ВРАГА». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.00 «Йөрәктән-йөрәккә». Мирсәй Әмир турында телеочерк. 6+
6.00 Спектакль «Күзләреңнән үбеп». 12+
7.30 Муса Гәрәев турында телеочерк. 6+
8.30, 16.00 «Йөрәкләрдә һаман ут яна». 6+
9.45 Казан гарнизонының Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 77 еллыгына багышланган тантаналы йөреше. 6+
11.00, 18.00, 20.30, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 19.01, 0.15 «Ватандашлар». 6+
12.05 «Батырларга хат. Письма героям». 6+
14.45 «Үлемсез полк-2022». 6+
17.00 «Габдрахман». 12+
18.25, 0.40 «Татарлар». 12+
18.55 Фашизмга каршы сугышта һәлак булганнарның якты истәлегенә... Бер минутлык тынлык. 6+
19.30, 21.00 Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 77 еллыгына багышланган Бәйрәм концерты. 6+
21.30 Спектакль «Яратылмый калган ярлар». 12+
23.15 «Без - 41 ел балалары». 6+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 9.30, 11.30 «КОМИСАРША». 12+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 20.00 «СПУТНИКИ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
23.00 «КРАЙ». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00, 9.50 Новости.
5.10, 11.00, 23.50 «День Победы».
10.00 Москва. Красная площадь. Парад, посвященный Дню Победы.
18.55 Светлой памяти павших в борьбе против фашизма. Минута молчания.
19.00, 22.10 «ДИВЕРСАНТ. ИДЕАЛЬНЫЙ ШТУРМ». 16+
21.00 «Время».

«РОССИЯ»

4.00 «НИ ШАГУ НАЗАД!» 12+
8.00, 11.00 «День Победы».
10.00 Москва. Красная площадь. Парад, посвящённый Дню Победы.
12.00, 14.00, 20.00 Вести.
12.30 Большой праздничный концерт, посвящённый Дню Победы.
14.30 Бессмертный полк.
16.20, 19.00 «ЧЕРЕЗ ПРИЦЕЛ». 12+
18.55 Светлой памяти павших в борьбе против фашизма. Минута молчания.
21.05 Вести. Местное время.
21.20 «ДЕВЯТАЕВ». 12+
23.15 «Т-34». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.00 «НЕИЗВЕСТНЫЙ СОЛДАТ».
9.30 «НА ВСЮ ОСТАВШУЮСЯ ЖИЗНЬ...»
13.55 «ЗАСТАВА ИЛЬИЧА».
17.05 «БЫЛ МЕСЯЦ МАЙ».
18.55 «Светлой памяти павших в борьбе против фашизма».
19.00 «ПОСЛЕСЛОВИЕ».
20.40 «Романтика романса».
22.25 «ТИШИНА».

«НТВ»

4.10 «Великая Отечественная».
5.40, 8.15 «ПОСЛЕДНИЙ ДЕНЬ ВОЙНЫ». 16+
8.00, 11.00, 16.00, 19.00 Сегодня.
10.00 Москва. Красная площадь. Парад, посвященный Дню Победы.
11.30 «ДЕД МОРОЗОВ». 16+
15.00, 16.30 «ТОПОР». 16+
17.00 «ТОПОР. 1943». 16+
18.55 Светлой памяти павших в борьбе против фашизма. Минута молчания.
19.35 «В АВГУСТЕ 44-ГО...» 16+
21.25 «ТОПОР. 1944». 16+

Сишәмбе

10 май

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
6.00 «Манзара». 6+
8.00 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «СИНЕҢ КҮЗЛӘР». 12+
10.00, 23.00 «УСЛОВИЯ КОНТРАКТА». 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте». 12+
11.15 «Память сердца». 12+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
13.00 «Туган җир». 12+
13.30 Спектакль «41 нең арбалы хатыннары». 12+
18.00 «Казаннан - казанга». 12+
18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Күчтәнәч».
21.00 «Ватандашлар». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.05 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
8.40, 23.05 «Җырлыйк әле!» 6+
9.40, 0.15 «Туган җир». 12+
10.30, 20.30 «Халкым минем». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 22.00 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ-2». 12+
15.30 «Тамчы-шоу». 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+
21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 9.30, 11.30 «КОМИСАРША». 12+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00 «ЖАЖДА». 16+
16.00 «День Победы». 12+
17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
20.00 «ГОСПОДА-ТОВАРИЩИ». 16+
21.00 «СЫН ОТЦА НАРОДОВ». 12+
23.00 «И БЫЛА ВОЙНА». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

6.00, 10.00, 12.00, 15.00 Новости.
6.10 «Россия от края до края». 12+
6.30 «ВРЕМЯ СОБИРАТЬ КАМНИ». 12+
8.10 «ЛЕТЯТ ЖУРАВЛИ». 12+
10.15 «Вольф Мессинг. «Я вижу мысли людей». 16+
11.10, 12.15 «Видели видео?»
13.35 «Наркотики Третьего рейха». 16+
14.30, 15.15 «ВОДИТЕЛЬ ДЛЯ ВЕРЫ». 16+
16.55, 18.20 «ПО ТУ СТОРОНУ ВОЛКОВ». 16+
18.00 Вечерние новости.
21.00 «Время».
21.45 «МОЛЧАНИЕ». 16+
22.40 «Большая игра». 16+
23.40 «АнтиФейк». 16+

«РОССИЯ»

4.50 «СОЛДАТИК». 6+
4.51 Перерыв в вещании.
6.25, 9.30 «ЧЕРЕЗ ПРИЦЕЛ». 12+
9.00, 11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
12.05 «ДЕВЯТАЕВ». 12+
15.15, 18.15 «НИ К СЕЛУ, НИ К ГОРОДУ...» 12+
21.05 Вести. Местное время.
21.20 «НИ К СЕЛУ, НИ К ГОРОДУ...-2». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30 Мультфильмы.
7.50 «ПРИЕХАЛИ НА КОНКУРС ПОВАРА...»
9.05 «Обыкновенный концерт с Эдуардом Эфировым».
9.35 «ЧАЙКОВСКИЙ».
12.05 «Лесные стражники. Дятлы».
12.45 «Добровидение - 2021». VI Международный фестиваль народной песни.
14.15 «ПОРТРЕТ С ДОЖДЕМ».
15.50 Концерт Красноярского государственного академического ансамбля танца Сибири имени М.С. Годенко.
17.30 «Пешком...»
18.00 «Последние свидетели».
18.55 «Романтика романса».
19.50 «Дело №36. Рождение детектива».
20.30 «ДЕЛО №306».
21.50 П.И. Чайковский. «Спящая красавица». Приморская сцена Мариинского театра.

«НТВ»

5.15 «Великая Отечественная».
6.00, 8.15 «ОДИН В ПОЛЕ ВОИН». 12+
8.00, 10.00, 16.00, 19.00 Сегодня.
9.30, 10.20 «ТОПОР». 16+
11.35 «ТОПОР. 1943». 16+
13.30 «ТОПОР. 1944». 16+
15.00, 16.15 «МАМКИНА ЗВЕЗДОЧКА». 16+
19.35 «АЛЕКС ЛЮТЫЙ. ДЕЛО ШУЛЬЦА». 16+
23.10 «У АНГЕЛА АНГИНА». 16+

Чәршәмбе

11 май

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «СИНЕҢ КҮЗЛӘР». 12+
10.00, 23.00 «УСЛОВИЯ КОНТРАКТА». 16+
11.00, 0.25 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
13.00, 0.50 «Җырлыйк әле!» 6+
14.00 «Азбука долголетия». 6+
15.15 «Шома бас» һәм «Сәйлән».
16.00 «Переведи!» 6+
18.00 «Халкым минем...» 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Кучтәнәч».
21.00 «Древний город Болгар». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05, 8.40, 23.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.05 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
9.40 «Ачыктан - ачык». 12+
10.30, 20.30 «Юлчы». 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ-2». 12+
15.30 «Яшьләр тукталышы». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
19.20, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+
22.05 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ». 12+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30 «Волынь-43. Геноцид во «Славу Украине». 12+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ГОСПОДА-ТОВАРИЩИ». 16+
10.30, 21.00 «СЫН ОТЦА НАРОДОВ». 12+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «1943». 12+
15.00 «Непокоренные. Они сражались за «Родину». 12+
15.40 Великая война.
16.35 «Фиксики».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
23.00 «ГОРОД ОСОБОГО НАЗНАЧЕНИЯ». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00 Новости.
9.20, 23.45 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.40, 12.15, 15.15, 18.20, 0.25 Информационный канал. 16+
18.00 Вечерние новости.
21.00 «Время».
21.45 «МОЛЧАНИЕ». 16+
22.45 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «ЕЛИЗАВЕТА». 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35, 18.35 «Первый алфавит».
8.35 Цвет времени. Михаил Врубель.
8.50, 16.35 «ГОНКИ ПО ВЕРТИКАЛИ».
10.15 «Наблюдатель».
11.10, 23.50 «Владимир Высоцкий. Выступление на телевидении в Грозном». 1978 г. «Город Грозный».
12.00 «ПОСЛЕСЛОВИЕ».
13.35 95 лет со дня рождения Майи Меркель. Острова.
14.20 «Куда ведут железные дороги».
15.05 Новости. Подробно. Кино.
15.20 «Библейский сюжет».
15.50 «Белая студия».
17.40 Александр Скрябин. Избранные произведения. Александр Сладковский и Российский национальный оркестр.
19.45 Главная роль.
20.05 «Любовь Мироновна Вовси: «Жизнь была хорошая, но немилосердная».
21.05 Абсолютный слух.
21.50 Власть факта. «Бельгия в Европе».
22.35 «ДЕ ГОЛЛЬ. ВЕЛИКОЕ И СОКРОВЕННОЕ».

«НТВ»

4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.30 Сегодня.
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ». 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие.
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «АЛЕКС ЛЮТЫЙ. ДЕЛО ШУЛЬЦА». 16+

Пәнҗешәмбе

12 май

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «СИНЕҢ КҮЗЛӘР». 12+
10.00, 23.00 «УСЛОВИЯ КОНТРАКТА». 16+
11.00, 0.50 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
13.00 «Кәмит Җәвит». 16+
14.00 «Здоровая семья: мама, папа и я». 6+
14.15 «Фолиант в столетнем переплёте». 12+
15.15 «Бергәләп өйрәник» һәм «Сәйлән».
16.00 «Казаннан - казанга». 12+
18.00 «Юлчы». 6+
19.00, 20.00 «Точка опоры». 16+
21.00 «Ватандашлар». 12+
22.00 «Вызов 112». 16+
0.00 «Видеоспорт». 12+
0.25 «Соотечественники». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
8.40, 23.05 «Кәмит Җәвит». 16+
9.40, 20.00 «Йөрәктән-йөрәккә». Хатыйп Миңнегулов турында телеочерк. 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 22.30 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ-2». 12+
15.30 «Халкым минем». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
19.00 «Древний город Болгар». 6+
21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ГОРОД ОСОБОГО НАЗНАЧЕНИЯ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ГОСПОДА-ТОВАРИЩИ». 16+
10.30, 21.00 «СЫН ОТЦА НАРОДОВ». 12+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «1943». 12+
15.00 «Степан Бандера. Следы на Майдане». 12+
15.45 Великая война.
16.40 «Фиксики».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00 Новости.
9.20, 23.45 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.40, 12.15, 15.15, 18.20, 0.25 Информационный канал. 16+
18.00 Вечерние новости.
21.00 «Время».
21.45 «МОЛЧАНИЕ». 16+
22.45 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «ЕЛИЗАВЕТА». 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35, 18.35 «Как письменность изменила мир».
8.35 «Первые в мире».
8.50, 16.30 «ГОНКИ ПО ВЕРТИКАЛИ».
10.15 «Наблюдатель».
11.10, 23.50 «За строкой сообщения ТАСС».
12.10 «Екатеринбург. Особняк Тупиковых».
12.40, 22.35 «ДЕ ГОЛЛЬ. ВЕЛИКОЕ И СОКРОВЕННОЕ».
13.35 Абсолютный слух.
14.15 «Власть над климатом».
15.05 Новости. Подробно. Театр.
15.20 Моя любовь - Россия! «Байкал - колыбель бурят».
15.45 «2 Верник 2».
17.40 Александр Скрябин. Избранные произведения. Андрей Гугнин.
19.45 Главная роль.
20.05 «Любовь Мироновна Вовси: «Жизнь была хорошая, но немилосердная».
21.05 «Белое солнце пустыни». Для кого ты добрая, госпожа удача?»
21.50 «Энигма. Юстус Франц».
23.20 Цвет времени. Карандаш.

«НТВ»
5.05 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.30 Сегодня.
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ». 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие.
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «АЛЕКС ЛЮТЫЙ. ДЕЛО ШУЛЬЦА». 16+

Җомга

13 май

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35, 14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «СИНЕҢ КҮЗЛӘР». 12+
10.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 6+
11.00 «Нәсыйхәт». 6+
11.30 «Татарлар». 12+
12.00, 23.10 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
13.00 «Башваткыч». 12+
14.00 «Актуальный ислам». 6+
14.15 «Рыцари вечности». 12+
15.15 «Төймә һәм «Сәйлән».
16.00 «Мин». 12+
16.30 «Әдәби хәзинә». 6+
18.00 «Туган җир». 12+
19.00, 20.00 Концерт. 6+
21.00 «Юлчы». 12+
22.00 «Вызов 112». 16+
22.10 «КВН РТ-2022». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
8.40, 23.05 «Ком сәгате». 12+
9.40, 15.30 «Нәсыйхәт». 6+
10.30 «Казаннан казанга». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 22.30 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ-2». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.30 «Калеб». 6+
19.10 «Туган җир». 12+
19.35 «Яралы язмышлар». 12+
20.00 «Татар халык җырлары». 6+
21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+

«ЭФИР»
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ГОРОД ОСОБОГО НАЗНАЧЕНИЯ». 16+
9.25, 11.25, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ГОСПОДА-ТОВАРИЩИ». 16+
10.30, 21.00 «СЫН ОТЦА НАРОДОВ». 12+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00, 23.50 «В ПЛЕНУ У САКУРЫ». 16+
15.00 «Волынь-43. Геноцид во «Славу Украине». 12+
15.50 Великая война.
16.45 «Фиксики».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.30 «Fam TV». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.40, 12.15, 15.15 Информационный канал. 16+
18.00 Вечерние новости.
18.40 «Человек и закон». 16+
19.40 «Поле чудес».
21.00 «Время».
21.45 «МОЛЧАНИЕ». 16+
22.45 «Один вдох». 12+

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30, 7.00, 7.30, 8.15, 10.00, 15.00, 19.30, 23.45 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35 «Возрождение дирижабля».
8.20 «Шри-Ланка. Маунт Лавиния».
8.50, 16.30 «ГОНКИ ПО ВЕРТИКАЛИ».
10.20 Спектакль «Мнимый больной».
12.40 «ДЕ ГОЛЛЬ. ВЕЛИКОЕ И СОКРОВЕННОЕ».
13.25 Цвет времени. Николай Ге.
13.35 Власть факта. «Бельгия в Европе».
14.15 «Говорящие коты и другие химеры».
15.05 Письма из провинции.
15.35 «Энигма. Юстус Франц».
16.15 Цвет времени. Леонардо да Винчи. «Джоконда».
17.40 Александр Скрябин. Избранные произведения. Андрей Коробейников.
18.45 «Царская ложа».
19.45 Искатели. «В поисках «Русской красавицы».
20.30 Линия жизни. Анатолий Ким.
21.25 «ПРОСТАЯ ИСТОРИЯ».
22.55 «2 Верник 2».

«НТВ»
5.05 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 Сегодня.
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ». 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие.
14.00 «Место встречи».
16.45 «ДНК». 16+
20.00 «Жди меня». 12+
20.50 «Страна талантов». 12+
23.05 «Своя правда». 16+

Шимбә

14 май

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
6.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 6+
7.00 «Sиңа Миннән Sәлам». 6+
9.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
10.00 «Кайнар хит». 12+
11.00 «Мин». 12+
11.30 «Казаннан - казанга». 12+
12.00, 0.50 «Каравай». 6+
12.30 «Видеоспорт». 12+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
13.30 «Созвездие - Йолдызлык-2022». 6+
14.35 «Яшәү яме». Сиринә Зәйнетдинованың юбилей концерты. 6+
16.00 «Галиҗәнап шагыйрь». 6+
17.10 «СТЕНДАПхана». 16+
18.00 «Кәмит Җәвит». 16+
19.00 «Халкым минем...» 12+
19.30, 21.30 Новости в субботу. 12+
20.00 «Адымнар». 12+
20.30 «Җырлыйк әле!» 6+
22.00 «КунакБит- шоу». 12+
23.00 «НЕВЕСТА МОЕГО ДРУГА». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00 «Йөрәктән-йөрәккә». Фуад Вәлиев турында телеочерк. 6+
7.00, 15.00 «Sиңа Миннән Sәлам». 6+
9.00 «Кәмит Җәвит». 16+
10.00 «Кайнар хит». 12+
11.00, 18.15 «Башваткыч». 12+
12.05, 19.05 «Җырлыйк әле!» 6+
13.05 «Гомернең онытылмас кичләре». 6+
17.10 «Казаннан казанга». 12+
17.45 «Халкым минем». 12+
20.00 «Адымнар». 12+
20.30 «Яратам». Гөлнара Габидуллина концерты. 6+
21.35 Спектакль «Гөлҗамал». 12+
23.55 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ-2». 12+

«ЭФИР»
5.00 «Мировой рынок». 12+
6.00 «Просто физика с Алексеем Иванченко». 12+
6.30 «Биосфера. Законы жизни». 12+
7.00 «Три кота. Сезон 3».
7.30 «Лео и Тиг».
8.00 «Планета лошадей». 12+
8.30 «ИДЕАЛЬНАЯ ЖЕНА». 16+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «МОЙ СОЗДАТЕЛЬ». 16+
15.00 «Все, кроме обычного». 16+
16.00 «ВЫ ВСЕ МЕНЯ БЕСИТЕ». 16+
19.00 «Город». 16+
21.00 «АТЛАНТИДА». 16+
23.00 «Человек - невидимка». 16+
23.50 «ПОД ПОДОЗРЕНИЕМ». 18+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
6.00 «Доброе утро. Суббота».
9.00 «Умницы и умники». 12+
9.45 «Слово пастыря».
10.00, 12.00, 15.00 Новости.
10.15 «Вера Алентова. «Как долго я тебя искала...» 12+
11.25, 12.15 «Видели видео?»
13.50 «ШИРЛИ-МЫРЛИ». 16+
15.15 «Ширли-мырли». 16+
16.40 «Кто хочет стать миллионером?»
18.00 Вечерние новости.
18.20, 21.35 «БЕЗ ПАМЯТИ». 12+
21.00 «Время».
23.00 «КАК БЫТЬ ХОРОШЕЙ ЖЕНОЙ». 16+

«РОССИЯ»
5.00 «Утро России. Суббота».
8.00 Вести. Местное время.
8.20 Местное время. Суббота.
8.35 «По секрету всему свету».
9.00 «Формула еды». 12+
9.25 «Пятеро на одного».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00, 20.00 Вести.
12.15 «Доктор Мясников». 12+
13.20 «ТОЧКА КИПЕНИЯ». 16+
18.00 «Привет, Андрей!» 12+
21.00 «ВИКТОРИЯ». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 «Библейский сюжет».
7.05 Мультфильмы.
7.35 «ПРОСТАЯ ИСТОРИЯ».
9.00 «Обыкновенный концерт с Эдуардом Эфировым».
9.30 Неизвестные маршруты России. «Коми. От Инты до национального парка Югыд ва».
10.10 «ПОСЛЕДНИЙ ДЮЙМ».
11.40 Черные дыры. Белые пятна.
12.20 «Беспокойное лето в Гранкином лесу».
13.00 «Музеи без границ». Музей истории Екатеринбурга.
13.30 «Рассказы из русской истории». Владимир Мединский.
14.20 «ЖИВЕТ ТАКОЙ ПАРЕНЬ».
16.00 «Необъятный Рязанов». Посвящение Мастеру». Вечер в Концертном зале им. П.И. Чайковского.
17.45 «ВОКЗАЛ ДЛЯ ДВОИХ».
20.00 Большой джаз.
22.00 «Агора».
23.05 «ПУТЕШЕСТВИЕ».

«НТВ»
5.15 «Хорошо там, где мы есть!»
5.30 «ВЗРЫВНАЯ ВОЛНА». 16+
7.30 Смотр.
8.00, 10.00, 16.00 Сегодня.
8.20 «Поедем, поедим!»
9.20 «Едим дома».
10.20 «Главная дорога». 16+
11.00 «Живая еда с Сергеем Малозёмовым». 12+
12.00 «Квартирный вопрос».
13.05 «Однажды...» 16+
14.00 «Своя игра».
15.00 «Новые документы об НЛО». 12+
16.20 «Следствие вели...» 16+
18.00 «По следу монстра». 16+
19.00 «Центральное телевидение».
20.20 «Ты не поверишь!» 16+
21.20 «Секрет на миллион». 16+
23.15 «Международная пилорама». 16+
23.50 «Квартирник НТВ у Маргулиса». 16+

Якшәмбе

15 май

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35, 11.00 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
6.00 «Синең өчен». Зәйнәб Фәрхетдинова һәм Зөфәр Билалов концерты. 6+
7.00 «Sиңа Миннән Sәлам». 6+
8.00, 13.00 «Адымнар». 12+
8.30 Мультфильмы. 6+
8.45 «Полосатая зебра».
9.00 «Әти һәм мин».
9.15 «Тамчы- шоу».
9.45 «Яшьләр тукталышы». 12+
10.15 «Ачыктан - ачык». 12+
11.30 «Тархан». 6+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Закон. Парламент. Общество». 12+
13.30 «Созвездие - Йолдызлык-2022». 6+
14.35 «Яшәү яме». Сиринә Зәйнетдинованың юбилей концерты. 6+
16.00 «Ком сәгате». 12+
17.00 «Видеоспорт». 12+
17.30 «Ватандашлар». 12+
18.00 «Башваткыч». 12+
19.00, 22.00 «Семь дней». 12+
20.00 «Соотечественники». 12+
20.30 «Болгар радиосы» концерты. 6+
21.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
23.00 «АФЕРА ПОД ПРИКРЫТИЕМ». 18+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05, 12.35 «Халкым минем». 12+
5.30, 13.00 «Нәсыйхәт». 6+
6.00 «Ватандашлар». 6+
6.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
7.00, 16.00 «Sиңа Миннән Sәлам». 6+
8.00 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
9.00 «Йөрәктән-йөрәккә». 6+
10.00 «Юлчы». 6+
10.30 «Калеб». 6+
11.10 «Тамчы-шоу». 6+
11.45 «Бергәләп өйрәник». 6+
12.05, 0.40 «Яшьләр тукталышы». 12+
13.30 «Яратып яшик». Раяз Фасихов концерты. 12+
17.15 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
18.10 «Кәмит Җәвит». 16+
19.05, 23.45 «Ком сәгате». 12+
20.00 «Семь дней». 12+
21.10 «СТЕНДАПхана». 16+
21.40 «Казан» бию ансамбле концерты. 6+

«ЭФИР»
5.00 «Мировой рынок». 12+
6.00 «Тайны анатомии». 12+
6.30 «Клятва Гиппократа». 12+
7.00 «Три кота. Сезон 3».
7.30 «Лео и Тиг».
8.00 «Чужие в городе с Дмитрием Губерниевым». 12+
9.00 «ВЫ ВСЕ МЕНЯ БЕСИТЕ». 16+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «АТЛАНТИДА». 16+
15.00 «Планета лошадей». 12+
15.30 «ИДЕАЛЬНАЯ ЖЕНА». 16+
19.00 «Город». 16+
21.00 «МОЙ СОЗДАТЕЛЬ». 16+
23.00 «Человек - невидимка». 16+
23.50 «ДОСТУЧАТЬСЯ ДО НЕБЕС». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
6.00, 10.00, 12.00, 15.00 Новости.
6.10 «Россия от края до края». 12+
6.35 «ПЕРЕКРЕСТОК». 16+
8.25 «Часовой». 12+
8.55 «Здоровье». 16+
10.15 Ко дню рождения Михаила Булгакова. «Полет Маргариты». 16+
11.10, 12.15, 15.15, 18.20 «МОСГАЗ». 16+
18.00 Вечерние новости.
21.00 «Время».
22.35 «ТРОЕ». 16+

«РОССИЯ»
5.20 «ВО ИМЯ ЛЮБВИ». 12+
7.15 «Устами младенца».
8.00 Местное время. Воскресенье.
8.35 «Когда все дома с Тимуром Кизяковым».
9.25 «Утренняя почта с Николаем Басковым».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00 Вести.
12.15 «Доктор Мясников». 12+
13.20 «ТОЧКА КИПЕНИЯ». 16+
18.00 «Песни от всей души». 12+
20.00 Вести недели.
22.00 Москва. Кремль. Путин.
22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 Мультфильмы.
7.05 «ВОКЗАЛ ДЛЯ ДВОИХ».
9.20 «Мы - грамотеи!»
10.00 «ЛИВЕНЬ».
11.15 Невский ковчег. Теория невозможного. Иосиф Бродский.
11.40 Диалоги о животных.
12.20 «Игра в бисер» «Поэзия Афанасия Фета».
13.00 «Музеи без границ». Музеи «Альтес Хаус» и «Дом китобоя» в Калининграде.
13.30 «Рассказы из русской истории». Владимир Мединский.
14.20 «Первые в мире».
14.35 «ПУТЕШЕСТВИЕ».
16.30 «Картина мира с Михаилом Ковальчуком».
17.10 Цвет времени. Ван Дейк.
17.25 «Пешком...»
17.55 «Дуга Струве без границ и политики».
18.35 «Романтика романса».
19.30 Новости культуры.
20.10 «ПОСЛЕДНИЙ ДЮЙМ».
21.35 «Кинескоп». «После Тарковского».
22.40 Angelina. Friends. Гала-концерт звёзд балета в Михайловском театре.
23.55 «ЖИВЕТ ТАКОЙ ПАРЕНЬ».

«НТВ»
5.10 «ДЕНЬГИ». 16+
6.35 «Центральное телевидение». 16+
8.00, 10.00, 16.00 Сегодня.
8.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача». 16+
11.00 «Чудо техники». 12+
11.55 «Дачный ответ».
13.00 «НашПотребНадзор». 16+
14.00 «Своя игра».
15.00, 16.20 «Следствие вели...» 16+
18.00 «Новые русские сенсации». 16+
19.00 Итоги недели.
20.30 «Ты супер! 60+». 6+
23.00 «Звезды сошлись». 16+

Сугыштан дүрт бармагын өздереп кайткан атаклы гармунчы Кирам турында Мамадыш районының Кече Сон авылында сөйләгәннәр иде. Шушы хикәятне тыңлаганнан соң аның гыйбрәтле язмышы, җанлы образы күз алдына килеп басты...

ӨЗЕЛМӘС МОҢНАР

Кирам абыйның үзенә каратырлык, магнит сыман тартып китерә торган бер хикмәте булган. Фашистларга каршы сугышта ул уң кулының – нәкъ менә гармун телләрендә уйный торган кул бармакларын өздереп кайта. Солдат биштәрен жилкәсеннән төшереп, аның хөрмәтенә сакланып калган «чикүшкә»не бушатып алгач, күңеле нечкәрүдән елап җибәргән. Нишләргә, сугышка киткәнче авыл кичләрен яңгыратып уйный торган гармуныма ни дип әйтергә тиеш ул хәзер? Аның бит кышлатып суйган сарык акчасына алынган тальян гармуны мировой иде! Яшьләрне кич саен җырлатты-биетте, аулак өйләрнең ишеген ачтырды, моңы белән кызлар толымына кагыла-кагыла табын түрендә утырыр иде...

Сугыш хәлләрен сорашкан авылдашларына берчакны болай дип сөйләгән ул:

– Курск дугасындагы тирән окопта яткан чак иде. Свастикалы танкларның берсен безнекеләр снаряды чәнчелдереп ташлады. Ә менә икенчесе көтмәгәндә ажгырып өстемә килеп чыкты. Килеп тә җитте, күмерле үтүк белән бастыргандай итеп, окопны айкарга керешә. Чәчләргә, муенга кайнар балчык кереп тулды. «Бетүем бугай», дип уйладым шул чакта һәм, куркуымны җиңеп, туфрак астыннан тальяным тавышын ишеттем... Табаннарны пешереп, колагыма хәтле ургылган шушы моң исән калдырды бугай мине. Әмма башымның урта бер җирендә әстерхан чикләвеге кадәрле ак тап уелып калган иде. Курку ак төстә була микәнни дип, әле дә булса гаҗәпләнеп куям...

Уң кулның дүрт бармагын югалтсам да, сул кулымның исән бармаклары «бакалар» өстеннән йөгереп уза-узуын, бичара уң кулым, ни хәрәкәт кылырга белмичә, һавада асылынып кала... Теге чактагы нимес снарядының кыйпылчыгы минем тальянга килеп тигән һәм ул аны телсез-моңсыз калдырырга тели гүя...

Утны-суны кичкән Кирам моның белән килешергә теләми. Көннәрнең берендә – йөрәгенең әллә кай төшләрендә посып яткан татар үҗәтлеге белән гармунын берничә кат уңга-сулга әйләндергәли дә берәүнең дә уена килмәстәй чишелешне уйлап таба!

...Берничә көннән соң ишегалдыннан тальянда уйнаган тавыш ишетелмәсенме! Авылдашлары бу хәлгә шакката: тальянының уң ягын – сул кулга, сул ягын уң кулга көйләп-үзгәртеп куйган икән лабаса! Дошман танкларын йөз сиксән градуска әйләндереп салган егет буларак, гармунының баш-башларын кирегә әйләндергән дә исән калган сул бармакларын унике тел өстендә биетә башлаган. Уң кулының исән бармагы исә иң кирәкле вазифаны башкару – ягъни каеш элмәкле планканы тартып-сузып йөртү өчен исән калган, күрәсең.

Кирамның сугыш аркасында өзелеп, әмма хәзер аерата бер моң, ачыну белән өретелгән уйнавы авыл өстендә яңадан яңгырый башлый. Югалту һәм сугыш җәрәхәтләренә карамастан, салам түбәле авылның күпмедер дәрәҗәдә өр-яңадан яши һәм килер көнгә өмет белән карый башлавы була бу...

Кирам абый күптәннән юк инде. Ул калдырган моңнар, татарның үҗәтлеге һәм батырлыгы – мәңгелек...

СНАРЯД ҺӘМ ЧҮМӘЛӘ

Әтием Мияссәрнең сугыш хәлләре турында җәелеп сөйләгәне булмады. Сугышка кадәр аны Кызыл Армия сафына алалар. Солдат шинеле кигәч тә, алты ай чамасы бронетанковый училищеда укый. Аннары Баку шәһәре. Күпмедер вакыттан соң Украинаның Сума өлкәсенә (бүгенге көндә анда Россия--Украина бәрелешләре бара) урнаштыралар. Бередәге полигоннарның берсендә аларны тягач, ягъни 77 миллиметрлы зенит тупларын тартып йөрү һөнәренә өйрәтәләр.

Кинәт... сугыш! Немецлар юлында очраган һәр шәһәрне диярлек мототехника белән 15-20 чакрым читтән уратып ала икән. Каты бәрелешләр һәм чигенүләр башлана. Әти тягач-трактор белән зенит тупларын тарттырып йөри. Еш кына немец самолетларын бәреп төшерәләр...

Алдагы еллар сугышының берсендә дошман снаряды аның сул кулын беләзектән үк өзеп ташлый. Әти ничектер аңын югалта, калганын юньләп хәтерләми. Кыр госпиталендә аңына килсә, аның тирәсендә ак халатлы санитаркалар кайнаша...

Яралары төзәлгәч, 1942 елның җәендә Низаметдин бабам (Тукай яшьтәше – 1986 елда туган) йортына 22 яшьлек солдат-фронтовик кайтып төшә. Газиз уллары кайткан! Менә шул хөрмәткә идән асты туфраксасыннан адарынып куелган «чикүшкә»не табып алалар да өстәлгә чыгаралар...

Чирәмле ишегалдына чыккач, кинәттән күңеле тулып, әти янбакча рәшәткәләрен сыңар кул белән кочып елый башлый:

– Япь-яшь килеш кулсыз калдым... Чулак Мияссәр дип йөртерләр микәнни мине? Кызлар янына ни йөрәгем белән барырмын?.. Их, шушы Гитлер сугышының әшәкелеге!..

Юкка борчылган, үзен-үзе юкка битәрләгән эти. 1945 елны тота да күршедәге Балык Бистәсе районының Күки авылыннан Асия исемле кызны ярәшеп кайта. Яши торгач, ике малай, өч кыз үстерәләр. (1946 елгы Җәүдәт абыем хәрби очучы иде, 21 яшендә Россия күгендә фаҗигале төстә һәлак булды). Әти озак еллар колхоз завхозы, аннары амбар мөдире булып эшләде. Абруе-дәрәҗәсе бар, аңа «Мияссәр абый» дип кенә эндәшәләр иде.

Еллар узгач, мин әти турында «Яра» дигән шигырь яздым. Анда мондый юллар бар:

Әткәйләрнең кулын кискән фашист,
Илнең кулын кисә алмаган!

Ә хәзер әтигә дә, минем үземә дә шактый бәйле булган печән чүмәләләре турында хикәяләп китәсем килә.

Их, карурман аланында печән чапкан чаклар! Әти – сыңар куллап, ә мин – унөч-ундүрт яшьлек малай – ике куллап чалгы белән уңга-сулга селтәнәбез. Кайдадыр урман ешлыгында күке, моңлы аваз биреп, печәнчеләргә озын гомер юрый. Төклетура тавышы исә шундук җәлеп итә! Колак төбеннән диярлек зур бер нокта выжылдап узып китсен әле – туктамас җиреңнән сәерсенеп-гаҗәпләнеп тукталырсың... Кызу кояш нурлары арфа кылларыдай җиргә тартылган... Янәшәдә, синең каршыңда урман симфониясе башкарыла...

Бер-ике көн дигәндә чапкан печәннәребез җәйге кояшта шылтырап кипте. Аларны тырмалап, пөхтәләп кенә чүмәләгә салдык. Үлән, чәчәк, кыргый клевер исләре аңкып торган хуш исле ун чүмәлә! Бердәнбер сыерыбызны, сарыкларны кышлату өчен бик тә кирәкле яшькелт хәзинә бу. Ләкин бу дөньяда «процент печәне» дигән нәрсә дә бар икән әле. Ягъни, әтинең әйтүенчә, шушы хәләл ун чүмәләнең бишесен (яртысын) «лесник»ка – урман каравылчысына тапшырырга тиеш икәнбез, чөнки өстән аңа шундый әмер бирелгән.

Урман каравылчысы Баһаветдин абый килгәнне көтәбез. Менә, ниһаять, безнең янга тыпырдап торган җигүле ат килеп туктады. Аның артыннан җигүле арба таккан «Беларусь» тракторы да пәйда булды. Баһаветдин абый кычкырып сәлам бирде һәм күрешергә дип этигә кулын сузды. Чү, күземә күренәме дип торам: әтием шикелле, ул да сыңар куллы икән бит ләбаса!.. Икесенең дә сул кулларының җиңе буш...

Менә урманчы абый ун чүмәләнең барысын да җентекләп күздән кичерде. Сыңар кулының тересәген печән өемә батырып-батырып, аларның тыгызлыгын тикшерде бугай. Соклануын да яшереп тормады:

- Вәт печән бу ичмасам! Чәйгә кушып кына тотарлык...

- Ниме соң, кордаш, - диде әти, иплә кенә. – Процент печәне дигәч тә, рәнҗетмә инде... Безгә дигән өлешне мулрак калдыра күр...

– Булмый, Мияссәр абый. Процент печәненең кагыйдәсен яхшы беләсең. Ун чүмәләнең бишесе сиңа кала, калган яртысын лесхоз кибәненә алып китәбез.

Миңа күңелсез булып китте. Нәни күкрәгемә ризасызлык ачысы кереп тулды. Сыңар куллы кеше икенче бер сыңар куллы кешенә аңларга тиеш иде кебек югыйсә. Белмим бит, бәлки, Баһаветдин абый да фронтовик булгандыр? Бәлки, ул да кулын сугышта өздергәндер...

Ул арада сәнәк тоткан ике агай трактор арбасыннан җиргә сикерде. Чүмәләнең иң якындагы беренчесенә таба якынаялар... «Туктагыз!.. – дип кычкырдым да, кулларымны җәеп, аркан капландым. Очлы сәнәкләр ике яктан батып керү белән чүмәлә дер селкенде, кояш ягына таба янтайды. Мин, үзем дә сизмәстән, эти белән үзем чапкан печән астында күмелеп калдым. Печән сабаклары арасыннан миңа, кызганыпмы, чәрдәкләнгән кояш түгәрәге карап тора иде...

Рәшат НИЗАМИ.

Мәдәни җомга

Табынга – МИЛЛИ САВЫТ-САБА

Кайчан да булса Татарстан Мәдәният министрлыгының халык сәнгате һөнәрчелеге буенча экспертлар советы әлеге савыт-сабаны да югары дәрәҗәдәге халык сәнгате һөнәрчелеге исемлегенә кертми калмаячак, минемчә. Чөнки алар моңа лаек!

Кукмара осталары – Диләрә һәм Артур Шакировлар керамика сәнгате өлкәсендә 2017 елдан бирле эшли. “Керамика осталары булып китәрбез дип уйламаган идек. Тик язмышларыбызның нәкъ менә шушы сәнгать белән бәйләнеп китүенә без бик шат”, – ди алар.

Яшьләрнең икесе дә Кукмарада туып-үскән. Казан федераль университетын тәмамлаган: Артур – интерьер дизайны факультетында һәм “Педагогика белеме” магистратурасында, ә Диләрә исә филология факультетында белем ала. Гаилә корып, янә туган якларында төпләнүгә үк, Артур “Галактика” балалар иҗаты үзәгенә йөрүче укучыларны рәсем ясау, компьютер графикасы серләренә төшендерә башлаган. Үзәк директоры С.Исаев балаларга үзле балчыктан әйберләр әвәләргә өйрәтә башларга тәкъдим иткәч, Шакировлар риза булып, Казанда махсус курс та үткәннәр. Аннары күп сәгатьләр интернетта эзләнеп, үзләре бөртекләп җыйган мәгълүматларны анализлый торгач, бу эшнең асылы тагын да яхшырак аңлашыла башлаган. Керамика аларның бар күңелен яулап ала һәм Шакировлар үзәктәге хезмәттән тыш үз остаханәләрен ачып җибәрә.

“Ra cermics – РАссвет кеРАмики” сәнгати керамика остаханәсенең йөзен татар орнаментлары белән бизәлгән, сыйфатлы савыт-саба тәшкил итә. “Без үзенчәлекле әйберләр генә иҗат итәргә булдык һәм шушы максатыбызга бер ел дәвамында килдек. Башка осталарны кабатламау нияте белән, бизәлештә бары тик милли орнаментларга гына тукталдык”, – ди иҗатчылар. Балчыктан ясалгач, эшләнмәләр иң әүвәл 1000 градус кайнарлыктагы махсус мичтә чыныктырыла, аннары аларны сөткә батырып алырга һәм 300 градус кайнарлыктагы мичтә тагын бер кат чыныктырырга кирәк. Шуннан соң керамика әйберләренә су сеңми башлый. Моннан кала әлеге савыт-саба борынгы рецепт буенча, балавыз, зәйтүн мае кебек табигый компонентлардан торган махсус эремә – ганозис белән капланып, тагын бер кат ныгытыла.

Диләрә үзләренең милли темага алынуларын болай аңлата: “Студент чакта дәрәҗәле кунакларга порцияле ризыклар салынган савыт-саба, махсус тәлинкәләре булган ризык йортында официант булып эшләп алган идем. Андагы савытларга милли ризыклар салып бирелә, тик моның өчен гадәти савытлар гына кулланыла иде. Шул искә төште дә, иң әүвәл өчпочмак формасындагы бизәкле тәлинкәләр ясап карадык. Алар матур килеп чыкты, күпләр сатып алды. Татар орнаментлы савыт-саба гына иҗат итсәк, эшебез алга барыр дигән нәтиҗәгә килдек. Бераздан бәлеш өчен уңай савыт, җиләк-җимешләр өчен тәлинкәләр һ.б. ясадык. Икенче төр эшләнмәләребезгә башкорт, удмурт милли орнаментларын да өстәдек. Без гаиләләрнең бердәм булуын һәм аларның балаларына милли-мәдәни тәрбиянең табындагы савыт-саба аша да күчүен телибез”.

Аларның кул эшләнмәләре кеше организмына зарар китерми торган табигый чималдан ясала, савыт-сабаның милли бизәкле булуы бер тараф, алар әле сыйфатлы, гаҗәеп пөхтәлек өлгесе булырлык итеп эшләнә. Осталар үзле балчыкны, Мәскәү аша заказ биреп, башка дәүләттән кайтарта. 2017 елдан башланып киткән иҗат уңай нәтиҗәләр бирә. Диләрә һәм Артур Шакировларның иҗат әсәрләрендәге бизәм ясау технологиясе – үзгә. “Зур төгәллектәге татар орнаментларын баштарак кулдан ясый идек, соңрак Артур иҗатның бу өлешен камилләштерде. Ирем балачакта балалар сынлы сәнгать мәктәбендә белем алган, Нократ Аланы көллиятендә дизайнер һөнәренә дә укыган. Бизәкләрнең һәммәсен дә җиренә җиткереп сыза, тиешле үлчәмнәрен компьютер программалары аша тәгаенли, аларны камилләштерә. Мондый яңа бизәк иҗат итү процессы ике атнага сузылырга мөмкин”, – ди әңгәмәдәшем.

Яшьләр “Печән базары” ярминкәсендә дә катнашкан, әйтик, 2019 елдагы “Печән базары”нда Татарстан Президенты Р.Миңнеханов шушы савыт-сабаларга сокланып, Шакировларны мактап узган.

Аларның шәхси остаханәләренә, өлкәннәр дә, сабыйлар да теләп йөри. Һәммәсе нидер булса да ясап карап, шушы мавыктыргыч шөгыльне дәвам итәргә омтыла.

Артур белән Диләрә товар төрлелеге яклы, үз савыт-сабаларына Идел буенда яшәүче бар милләт орнаментларын өстәргә әзер. Халык исә әлегә татар бизәклеләрен ешрак сорый. Осталарның кул эшләнмәләрен Кукмара, Казанның сувенир кибетләрендә очратып була. Бәяләре дә югары түгел. Аларга өстәлләренә милли бизәкле савыт-саба куелуын теләгән ресторан хуҗалары да еш мөрәҗәгать итә. Хәзерге көндә осталар милли бизәкле салфетка тоткычлар ясый.

Диләрә һәм Артур Шакировлар остаханәсендә ясалган савыт-саба – олуг тырышлык, түземлек салынган хезмәт нәтиҗәсе, киләчәктә дә халыкны сокландырмый калмас!

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ – «ТАТМЕДИА» АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры – баш мөхәррир

Вахит Шәих улы ИМАМОВ

Җаваплы сәркатип Илгизәр ЗӘКИЕВ

Шылтыратыгыз:

222-09-83 (1562) – кабул итү бүлмәсе;

222-05-47 (1560) – җаваплы сәркатип, компьютер үзәге;

222-05-47 (1561) – иҗтимагый-сәяси тормыш, мәгариф һәм фән, сәнгать бүлекләре; хатлар һәм социаль көнкүреш, тәрҗемә бүлекләре;

222-09-84 (1266) – бухгалтерия.

Реклама хезмәте телефоны: (843)222-05-47 (1560)

Газета Элемтә, мәгълумати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләр өлкәсенә күзәтчелек итү федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2019 елның 9 октябрендә ПИ №ФС 77–76961 нче санлы теркәү таныклыгы алды

Индекс П2355

Авторлар фикере редакция фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин

Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк

Хатлар, кульязмалар, фотографияләр, рәсемнәргә бәяләмә бирелми һәм алар кире кайтарылмый

© Газетада чыккан материалларны күчереп бастырганда редакциядән язмача рөхсәт алу мәҗбүри

Реклама һәм белдерүләрнең төгәллеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы

Безгә иганәлек ярдәме күрсәтергә теләүчеләр өчен редакциянең исәп-хисап счеты:

ИНН 1655144950 КПП 165802012
ПАО «АК БАРС» банк,
г. Казань
р/с 40702810600020010312
к/с 30101810000000000805
БИК 049205805 ОГРН 1021600000124

НӘШЕР ИТҮЧЕ – «ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан, Академия урамы, 2

Редакция, гамәлгә куючы һәм басмаханәнең адресы:

420066, Казан, Декабристлар урамы, 2

E-mail: m-jomga@mail.ru

«Мәдәни җомга» газетасы Интернетта: www.madanizhomga.ru

Басмаханә гаебе белән җибәрелгән сыйфат җитешсезлекләре хакында 562-10-61 номерлы телефон буенча шылтыратырга

Газета һәр атнаның җомга көнендә чыга. Бу санның чыгу көне 6.05.2022

График буенча бу санга 15 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 14 сәгать 30 минутта.

«Татмедиа» АҖ филиалы – «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды

Газетаның сатудагы бәясе ирекле

Тираж – 2710 данә

Заказ 2751

16+